# Фәнни Татарстан

ТАТАРСТАН ФӘННӘР АКАДЕМИЯСЕ
Г. ИБРАҺИМОВ ИСЕМЕНДӘГЕ ТЕЛ, ӘДӘБИЯТ ҺӘМ СӘНГАТЬ ИНСТИТУТЫ

2024 2 (42)

ISSN 2499-9741
КАЗАН

***Журнал «2014–2022 елларга Татарстан Республикасында ТР дәүләт телләрен һәм башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү», «Татарстан Республикасында ТР дәүләт телләрен һәм башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» дәүләт программалары кысаларында 2014 елдан кварталга бер сан нәшер ителә***

*Массакүләм мәгълүмат чарасын Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәт тарафыннан регистрацияләү турындагы таныклык ПИ № ФС77-65242 01.04.2016*

► **ЖУРНАЛНЫ ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫ**
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ФӘННӘР АКАДЕМИЯСЕ

► **ИДАРӘ:**
МИҢНУЛЛИН К.М., филология фәннәре докторы, профессор, идарә җитәкчесе (Казан)
АЛИШИНА Х.Ч., филология фәннәре докторы, профессор (Төмән)
АРСЛАНОВ М.Г., сәнгать фәннәре докторы, профессор (Казан)
БАҺАВЕТДИНОВ Ф.Н., хокук фәннәре докторы, профессор (Казан)
ГЫЙЛӘҖЕВ И.А., тарих фәннәре докторы, профессор (Казан)
ЗАҺИДУЛЛИНА Д.Ф., филология фәннәре докторы, профессор (Казан)
ҖАМАЛЕТДИНОВ Р.Р., филология фәннәре докторы, профессор (Казан)
КЕРИМОВ И.А., филология фәннәре докторы, профессор (Симферополь)
МИҢНЕГУЛОВ Х.Й., филология фәннәре докторы, профессор (Казан)
МӨХӘММӘТШИН Р.М., сәяси фәннәр докторы, профессор (Казан)
НАСИПОВ И.С., филология фәннәре докторы, профессор (Уфа)
ӨНӘР МОСТАФА, фән докторы, профессор (Измир)
САЛӘХОВ М.Х., физика-математика фәннәре докторы, профессор (Казан)
САЛИХОВ Р.Р., тарих фәннәре докторы (Казан)
СИБГАТУЛЛИНА Ә.Т., филология фәннәре докторы, профессор (Мәскәү)
СӨЛӘЙМАНОВ Җ.Ш., техник фәннәр докторы, профессор (Казан)
ТӘСИН ҖӘМИЛ, Бабеш-Больяй университетының Тюркология һәм Үзәк Азияне өйрәнү институты директоры (Клуж-Напока, Румыния)
ТИМЕРХАНОВ А.Ә., филология фәннәре докторы (Казан)
ХУҖИН Ф.Ш., тарих фәннәре докторы, профессор (Казан)
ШӘЙДУЛЛИН Р.В., тарих фәннәре докторы, профессор (Казан)
ШАМИЛ-ОГЛЫ ЮЛАЙ, тарих фәннәре докторы, профессор (Астана)

► **БАШ РЕДАКТОР**
Ким Мөгаллим улы МИҢНУЛЛИН

► **БАШ РЕДАКТОР УРЫНБАСАРЛАРЫ:**
МӨХӘММӘТҖАНОВА Л.Х., ШӘРИПОВА А.С. (җаваплы секретарь)

► **РЕДАКТОРЛАР:**
ЗАҺИДУЛЛИН И.К. (тарих), СОЛТАНОВА Р.Р. (сәнгать), МИРХӘЕВ Р.Ф. (тел белеме), ГАРИПОВА Л.Ш. (әдәбият), ЯМАЛТДИНОВ И.И. (фольклор)

► **ЧЫГАРЫЛЫШ РЕДАКТОРЫ:**
ГАЛИУЛЛИНА Д.Р.

► **ГАМӘЛИ ХЕЗМӘТКӘРЛӘР:**
ШӘРИФУЛЛИНА Л.Г., АБДУЛЛИНА Н.Т., СӘЛАХОВА Ә.Ф., ЧУГУНОВ А.С.

**БУ САНДА**

## ТЕЛ БЕЛЕМЕ

*Гыйлемшин Ф.Ф., Гыйлемшина А.Г.* XIX гасыр ахыры – XX гасыр башында татар теленә тәрҗемә ителгән кыйсса жанрындагы әсәрләрдә сакраль лексиканың кулланылыш үзенчәлекләре . . . . 7

*Сабитова И.И.* Татар халык авыз иҗатында фитонимнар *(кыска җырлар мисалында)* . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 15

*Сафина Э.И.* Гарәп һәм фарсы телләреннән кергән орнитологик лексика . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 21

*Куряева Р.И.* Урта Идел Буеның әйләнә-тирә табигатьне тасвирлаучы сүзләрдән ясалган төрки чыгышлы рус ойконимнары . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 29

*Фәттахова Р.Ф.* Татар телендә кешенең яхшы матди хәлен белдерә торган лексик һәм фразеологик берәмлекләр . . . . . . . . 37

*Бәдртдинова А.Ә.* Татар теле кузнецк сөйләшенең фонетик үзенчәлекләре *(Пенза өлкәсенә 2021 елгы экспедиция нәтиҗәләре буенча)* . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 44

## ӘДӘБИЯТ БЕЛЕМЕ

*Заһидуллина Д.Ф.* Әмирхан Еникинең сугыш турындагы әсәрләрендә мөселман дөнья сурәте . . . . . . . . . . . . . . . . . 48

*Макарова В.Ф.* Бөек Ватан сугышыннан соңгы татар прозасы контекстында Хәсән Сарьян иҗаты: милли-дини күзаллауларны тергезү . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 55

*Шәрипова А.С.* 1970–1980 еллар татар драматургиясендә классик романтизм традицияләре яңарышы *(Илдар Юзеев иҗаты мисалында)* . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 61

*Надыршина Л.Р.* Гариф Ахуновның «Идел кызы» дилогиясендә милли-дини кыйммәтләр. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 69

*Ганиева А.Ф., Ганиев И.Ш.* Мирсәй Әмир сәнгати дөньясында герой һәм проблематика . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 75

*Насыйбуллина Н.Ш.* Зәки Зәйнуллин шәхесе һәм татар әдәбияты . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 81

*Мөбарәкшина А.Р.* Татар һәм төрек матбугатында Фатих Котлының тәрҗемә эшчәнлеге. . . . . . . . . . . . . . . . . . . 91

## ХАЛЫК ИҖАТЫ

*Хөсәенова Г.Р.* XIX гасыр басма китабы «Җәүһәр таҗ кыз»: әсәрнең жанр компонентларына кыскача күзәтү . . . . . . . . . . . 97

*Галиуллина Д.Р.* XIX гасырда Уфа губернасында яшәгән төрки халыкларның гореф-гадәтләре турында *(Казан университеты каршындагы Археология, тарих һәм этнография җәмгыяте хәбәрләре материаллары буенча)*. . 103

## ТАРИХ СӘХИФӘЛӘРЕ


*Ибраһимов Р.Р., Габделхакова Г.М.* Татарстан һәм Кыргызстан арасында мәдәни-икътисади элемтәләр. . . . . . . . . . . . . . . . . 111

*Исокбоев А.А.* Мәгърифәтче Шакир Мохтаровның Төркестандагы күпкырлы эшчәнлеге турында . . . . . . . . . . . 117


## СӘНГАТЬ


*Федорова С.С.* Поль Пуаре. «Казан» коллекциясе . . . . . . . . . . 123

*Самсонов М.Н.* «Гөлнәзек» анимацион фильмы мисалында яшьләр арасында мәдәни үзтәңгәллек формалаштыру . . . . . . 127


## ШӘХЕСЛӘРЕБЕЗ


*Ямалтдинов И.И.* Фольклорчы галим Хәмит Ярми . . . . . . . . 131

*Галиева Л.Ш.* Галим һәм остаз *(Хатыйп Миңнегуловка 85 яшь)* . 137

*Сибгатуллина Ә.Т.* Казакъ-татар галимәсе *(Клара Шәйсолтан кызы Хафизовага 85 яшь)* . . . . . . . . . . . 141


## ФӘННИ ЯДКӘРЛӘР


*Сәгъди Г.* Әдәбиятыбызны мәдрәсәләрдә укыту . . . . . . . . . . 146

*Кәрам Г.* «Тигезсезләр» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 160


## ЯҢА КИТАПЛАР


*Сәлахова Э.К.* «Рухи мирас: эзләнүләр һәм табышлар» сериясендә сәяхәтнамәләр *(13, 14, 18 нче чыгарылышларга бәяләмә)*. . . . . 169

*Закиров Р.Ә., Мөхиярова Р.Х.* «Баш хәрефтәнме, юл хәрефеннәнме?» орфографик сүзлегенә (Казан, ТӘһСИ, 2022) рецензия . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 173


## ФӘННИ-ИҖТИМАГЫЙ ТОРМЫШЫБЫЗДАН

## В НОМЕРЕ

### ЯЗЫКОЗНАНИЕ

*Гилемшин Ф.Ф., Гилемшина А.Г.* Особенности использования сакральной лексики в произведениях жанра кысса, переведённых на татарский язык в конце XIX – начале XX века . . . . . . . . . . 7
*Сабитова И.И.* Фитонимы в татарском устном народном творчестве *(на примере коротких песен)* . . . . . . . . . . . . . . . . 15
*Сафина Э.И.* Арабо-персидские заимствования в орнитологической лексике татарского языка . . . . . . . . . . . . 21
*Куряева Р.И.* Русские ойконимы тюркского происхождения Среднего Поволжья, производные от слов, описывающих окружающую природу . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 29
*Фаттахова Р.Ф.* Лексические и фразеологические единицы, обозначающие хорошее материальное положение человека в татарском языке. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 37
*Бадртдинова А.А.* Фонетические особенности кузнецкого говора татарского языка *(по результатам экспедиции в Пензенскую область в 2021 г.)*. . . . . . . . . . . . . . . . . . . 44

### ЛИТЕРАТУРОВЕДЕНИЕ

*Загидуллина Д.Ф.* Мусульманская картина мира в «военной» прозе Амирхана Еники . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 48
*Макарова В.Ф.* Творчество Хасана Сарьяна в контексте послевоенной татарской прозы: возрождение этно-религиозных представлений . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 55
*Шарипова А.С.* Возрождение традиций классического романтизма в драматургии 1970–1980 годов *(на примере творчества Ильдара Юзеева)* . . . . . . . . . . . . . 61
*Надыршина Л.Р.* Национально-религиозные ценности в дилогии «Идел кызы» («Дочь Волги») Гарифа Ахунова . . . . . 69
*Ганиева А.Ф., Ганиев И.Ш.* Герой и проблематика в художественном мире Мирсая Амира. . . . . . . . . . . . . . . . . . 75
*Насибуллина Н.Ш.* Личность Заки Зайнуллина и татарская литература. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 81
*Мубаракшина А.Р.* Переводческая деятельность Фатиха Кутлу в татарско-турецкой периодической печати . . . . . . . . . . . . 91

### НАРОДНОЕ ТВОРЧЕСТВО

*Хусайнова Г.Р.* Печатная книга XIX века «Джаухар тадж кыз»: краткий обзор жанровых компонентов произведения . . . . . . . . 97
*Галиуллина Д.Р.* Об обычаях тюркских народов Уфимской губернии *(по материалам Известий Общества археологии, истории и этнографии при Казанском университете)* . . . . . . 103

## СТРАНИЦЫ ИСТОРИИ

*Ибрагимов Р.Р., Габдулхакова Г.М.* Культурно-экономические связи между Татарстаном и Киргизией . . . . . . . . . . . . . . . 111

*Исокбоев А.А.* О многогранной деятельности Шакира Мухтарова в Туркестане . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 117

## ИСКУССТВО

*Федорова С.С.* Поль Пуаре. Коллекция «Казань» . . . . . . . . . . 123

*Самсонов М.Н.* Формирование культурной самоидентификации в среде молодёжи на примере анимационного фильма «Гульназек» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 127

## ПЕРСОНАЛИИ

*Ямалтдинов И.И.* Учёный-фольклорист Хамит Ярми . . . . . . . 131

*Галиева Л.Ш.* Учёный и наставник *(к 85-летию Хатипа Миннегулова)* . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 137

*Сибгатуллина А.Т.* Известный востоковед с татарскими корнями *(к 85-летию Клары Шайсултановны Хафизовой)* . . . . . . . . . . 141

## НАУЧНОЕ НАСЛЕДИЕ

*Сагди Г.* Преподавание литературы в медресе . . . . . . . . . . 146

*Карам Г.* «Тигезсезләр» («Неравные») . . . . . . . . . . . . . . . . 160

## НОВЫЕ КНИГИ

*Салахова Э.К.* Путевые заметки в серии «Духовное наследие: поиски и открытия» *(рецензия на выпуски 13, 14, 18)* . . . . . . . 169

*Закиров Р.А., Мухиярова Р.Х.* Рецензия на орфографический словарь «Баш хәрефтәнме, юл хәрефеннәнме?» (Казань, ИЯЛИ, 2022) . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 173

## НАУЧНАЯ ЖИЗНЬ

УДК 81'373

***Ф.Ф. Гыйлемшин,***
***А.Г. Гыйлемшина***

# XIX ГАСЫР АХЫРЫ – XX ГАСЫР БАШЫНДА ТАТАР ТЕЛЕНӘ ТӘРҖЕМӘ ИТЕЛГӘН КЫЙССА ЖАНРЫНДАГЫ ӘСӘРЛӘРДӘ САКРАЛЬ ЛЕКСИКАНЫҢ КУЛЛАНЫЛЫШ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ

Данная статья посвящена анализу сакральной лексики, использованной в татарских произведениях кысса, переведённых со староосманского и арабского языков в конце XIX – начале XX века. В текстах для передачи понятия единого и единственного Бога, активно используются лексемы *Allah* 'Аллах' *и Täğalä* 'Всевышний'*,* его эпитеты, а также тюркское слово *Täŋre* 'Бог' и персидское заимствование *Xodaj* 'Бог'. Использование имён Аллаха позволяет усиливать эмоциональное воздействие текста, контекстуально вводит в таинство общения человека со Всевышним.

Из сакральной лексики в текстах кысса наблюдается частое использование лексем *Qor'än* – 'Коран', *sürä* 'сура', *ajät* 'айат', а также слова, связанные с религиозными обрядами: *namaz* – 'намаз', *xac* – 'хадж', *ruza* 'пост', *tahärät* 'омовение', *sadäqa* 'милостыня' и т.д. Лексика, связанная с загробным миром, представлена словами *cännät* и *näğim* 'рай', *cähännäm* 'ад', *qyjämät, xašr* 'судный день', *axirät* 'потусторонний мир'. Слова, обозначающие обитателей рая *xur* 'гурия', *färeštä* 'ангел' употребляются для описания красоты персонажей. Данная категория лексики не несёт дополнительной смысловой нагрузки и по своему происхождению является заимствованной.

**Ключевые слова:** сакральная лексика, «Тутинаме», «Калила и Димна», жанр кысса, литературный язык, рай, ад, загробный мир, судный день.

This article is devoted to the analysis of sacred vocabulary used in the Tatar works of kyss, translated from the Old Ottoman and Arabic languages at the end of the 19th – beginning of the 20th century. In the texts of the works under study, to convey the concept of the One and only God, the creator of the world and the lord of the Day of Judgment, the lexemes Allah 'Allah' and Täğalä 'The Most High', the epithets of Allah – Gafur 'Merciful', Räxim 'Merciful, Merciful', Xaq 'True' are actively used. The use of the names of Allah allows us to enhance the emotional impact of the text, contextually introducing a person into the mystery of communication with the Almighty.

From the sacred vocabulary in the texts of the kyss, there is a frequent use of the lexemes Qor'än 'Koran', sürä 'sura', ajät 'ayat', as well as words associated with religious rituals: namaz 'namaz', khas 'hajj' , ruza 'fasting', tahärät 'ablution', sadäqa 'alms', käfen 'shroud', etc. Vocabulary associated with the afterlife is represented by the words cännät and näğim 'heaven', cähännäm 'hell', qyjämät, xašr 'judgment day', axirät 'other world'. Words denoting the inhabitants of paradise xur 'guria', färeštä 'angel' are used to describe the beauty of the characters. This category of vocabulary does not carry any additional semantic load and is borrowed in origin.

**Keywords:** sacred vocabulary, «Tutiname», «Kalila and Dimna», kyiss genre, literary language, heaven, hell, the afterlife, judgment day.

XIX гасыр ахыры – XX гасыр башы – татар әдәби теле тарихында үзенчәлекле борылыш чоры. Бу вакытта татар милләте формалаша башлый, яңа милли әдәби телгә күчеш күзәтелә. Яңа жанрлар һәм төрле стильләр барлыкка килә, бу исә, үз чиратында, татар теленең кулланылыш даирәсе киңәюгә китерә.

Нәкъ менә гасырлар чигендә, милли әдәбият үсеш алган чорда, Көнчыгыш әдәбияты әсәрләре татар теленә актив тәрҗемә ителә башлый. Шулар арасында Габделгалләм Фәезханов тәрҗемәсендә «Тутыйнамә» (1887) һәм «Кәлилә вә Димнә» (1889–1891); Фатих Халиди тәрҗемәсендә «Мең һәм бер кичә» (1897–1899); Каюм Насыйри тәрҗемәсендә «Кырык вәзир» (1861) һәм «Әбүгалисина кыйссасы» (1872) кебек күркәм әсәрләр аерым урын алып тора.

Безнең максат – кыйсса жанрындагы тәрҗемә әсәрләрдә сакраль лексиканың кулланылыш үзенчәлекләрен анализлау.

Мәгълүм булганча, «сакраль» термины (латинча sakralis), дөньяви күренешләрдән аермалы буларак, илаһи, дини өлкәгә караган, бакый дөнья белән бәйләнешле төшенчәләрне аңлата.

Кыйсса жанрындагы тәрҗемә әсәрләрдә сакраль лексика актив кулланыла. Дөньяның дини картинасы илаһи затның төп исеменә мөнәсәбәтле төзелә. Дөньяны яраткан, кыямәт көне хуҗасы булган илаһи зат текстларда *Allah* ‘Аллаһ’ лексемасы ярдәмендә белдерелә. Анализлана торган әсәрләр телендә Аллаһы Тәгаләнең исем-эпитетлары шактый күләмле актив һәм пассив лексик берәмлекләрне берләштергән синонимик парадигма тәшкил итәләр.

Кыйсса жанрына караган барлык татарча текстларда *Allah* лексемасы туры (дини) мәгънәдә кулланыла. Гадәттә, ул *Allahi Täγalä* (Аллаһы Тәгалә) сүзтезмәсе рәвешендә тәкъдим ителгән, мәсәлән: *bizni Allahi Täγalä ul bozaw selkeneb insan surätenä kerde* [Әлф ләйлә, б. 13] ‘Аллаһы Тәгалә кушуы буенча бу бозау, селкенеп, кеше сурәтенә керде’; *Allahi Täγalä birgän ni qadär γyjlem wä mäγrifät... barlyγn izhar qylmaq öčen* [Кырык вәзир, б. 5] ‘Аллаһы Тәгалә тарафыннан бирелгән белемнәрнең күләмен билгеләү өчен...’*; Üzenä wä bezgä mänfäγatle bulyb Allahy Täγälädän räxmätkä, xalyqdan xäjer doγaγa säbäb bulyr dide* [Кәлилә вә Димнә, б. 12] ‘Үзенә һәм безгә файдалы булып, Аллаһы Тәгаләдән рәхмәткә, халыктан хәер-догага сәбәп булыр, диде’.

Г. Фәезхановның «Тутыйнамә» һәм «Кәлилә вә Димнә» әсәрләре тәрҗемәләрендә ул аеруча актив чагылыш таба: *Allahi Täγalä ämere belän xatyny xämilä bulyb…* [Тутыйнамә, б. 3] ‘Аллаһы Тәгалә боерыгы буенча аның хатыны авырга узды...’; *Allahi Täγalä siŋa ber izge bala ixsan idär...* [Тутыйнамә, б. 3] ‘Аллаһы Тәгалә сиңа бер игелекле бала бирер...’; *Däbšälim Allahi Täγägägä šöker wä sänälär qylyb...* [Кәлилә вә Димнә, б. 6] ‘Дәбшалим Аллаһы Тәгаләгә рәхмәтләр һәм мактаулар укыды...’.

Тикшерелә торган әсәрләр текстларында *Allah* лексемасына параллель рәвештә Аллаһның эпитетын белдерүче *Xaq* сүзе

кулланыла. Әлеге лексема аерым да, шулай ук *Xaq Täγalä* (Хак Тәгалә) сүзтезмәсе составында да очрый.

Бу лексеманың аерым кулланылу очраклары «Мең дә бер кичә», «Кырык вәзир» әсәрләрендә күзәтелә: *Qyzyn xäjätdä küreb Xaqγa xämed wä sänä idäräk üzeneŋ xezmätenä kitmešder* [Әлф ләйлә, б. 16] 'Кызын сау-сәламәт күреп, ул Аллаһы Тәгаләгә рәхмәтләр укыды һәм үзенең вазифаларын үтәргә юнәлде'; *Xaqnyŋ ämere belän sineŋ xäläleŋ buldym* [Кырык вәзир, б. 5] 'Аллаһының әмере белән синең хәләл җефетең булдым'.

Шунысын да билгеләп үтәргә кирәк: әлеге вариантның татар телендә кулланышы киң таралган күренеш түгел, ул, башлыча, югары стильдә язылган әсәрләрдә яки дини текстларда очрый.

Кыйсса жанрына караган текстларда *Xaq Täγalä* (Хак Тәгалә) формасы киң таралган: *Xaq Täγalä aŋa jide qat kükne… kürsätde* [Кырык вәзир, б. 5] 'Хак Тәгалә аңа җиде кат күкне... күрсәтте'; *Xaq Täγalä küreb išeteb tora* [Кәлилә вә Димнә, б. 31] 'Хак Тәгалә күреп, ишетеп тора...', һ.б. Бу вариант телдә ныгып калган һәм хәзерге әдәби телдә шактый актив кулланыла.

Текстларда *Täγalä* (Тәгалә) сүзенең аерым кулланылу очраклары да күзәтелә. Мәсәлән, «Мең дә бер кичә» әсәрендә илаһи зат мәгънәсе шул лексема ярдәмендә белдерелә: *...bitäqdiri Täγalä ul ğarijägä mäxäbbät äjlädem* [Әлф ләйлә, б. 21] '...Аллаһы Тәгалә тәкъдире белән мин бу җариягә гашыйк булдым'.

Аллаһы Тәгаләне белдерү өчен иң актив кулланыла торган вариантлардан – Аллаһның эпитетлары – төрки сүз *Täŋre* (Тәңре) һәм фарсы алынмасы *Xodaj* (Ходай) еш очрый. Мәсәлән: *Täŋre xaqy öčen bändän bundaj ešne sorama...* [Әлф ләйлә, б. 278] 'Тәңре хакына миннән бу турыда сорама...'; *Täŋre ğabbar xäzrätenä tämam ixlas belän mönäğät qylyrγa kerešde* [Кәлилә вә Димнә, б. 10] 'Чын күңелдән ихлас белән Тәңре Җаббар хәзрәтенә мөнәҗәт кылырга кереште'; *Xodajnyŋ barlyγyna wä berlegenä iman kitereb din islam ilä mušrif bulsaŋ... sine bäradär idärem* [Әлҗилдү әс-сәни, б. 240] 'Ходайның барлыгына һәм берлегенә иман китереп, ...ислам динен кабул итсәң, сине ир туганым итәрмен'; *…sin Xodaj rizasy öčen* [Кәлилә вә Димнә, б. 2] '...син Ходай ризалыгы өчен' һ.б.

Мәсәлән, Ходай – «Аллаһ» сүзенең синонимы, барлык төрки телләрдә, галимнәр фикеренчә, исламга кадәрге чорда ук төрки-мәҗүсиләр илаһи затларының берсенең исеме буларак кулланылган [Әхмәтьянов, т. 2, б. 390]. *Täŋre* термины борынгы төрки язма истәлекләрдә теркәлгән. Ул төрки халыкларның мәҗүси күзаллауларына бәйле, төрки-монгол телләрендә күктәге рухны, политеистик пантеонда төп Алланы белдерә [Древнетюркский словарь, б. 132].

«Мең дә бер кичә» әсәрендә илаһи зат мәгънәсен белдерү өчен Аллаһның *Gafur* (Гафур), *Räxim* (Рәхим), *Gyjzzät* (Гыйззәт), *Räzzaq* (Раззак), *Xaliq* (Халик), *Cäläl* (Җәләл), *Cällä* (Җәллә), *Mäwlä* (Мәүлә) *кебек* эпитетлары да еш кулланыла. Мәсәлән: *Täwbä ideŋez Allahy Tăğalä*

*Gafur Räximder* [Әлҗилдү рәбигу, б. 209] ‘Тәүбә итегез, Аллаһы Тәгалә Гафур Рәхимдер’; *Cänäbe Rabbil-ğyjzzätkä padišahnyŋ hidajäte xaqynda mönäcät äjtde* [Кәлилә вә Димнә, б. 3] ‘Җәнәбе Раббил-Гыйззәткә падишаһның һидайәте хакында мөнәҗәт әйтте’; *Cällä wä Gallä xäzrätläre sezne xösed idüče küzdän saqlasyn* [Әлҗилдү әс-сәни, б. 69] ‘Җәллә вә Галлә хәзрәтләре сезне хөсед итүче күздән сакласын’.

Дини лексикадан әсәрләр текстларында шулай ук *Qor’än* ‘Коръән’ лексемасы еш очрый. Әлеге сүз мөстәкыйль рәвештә дә, шулай ук *kärim* ’изге’, *šärif* ‘изге’, *γazyjm* ‘бөек’ аергычлары белән берлектә дә кулланыла: *Xuš awaz ilä Qor’än uqydylar* [Тутыйнамә, б. 16] ‘Матур тавыш белән Коръән укыдылар’; *Xatynlarnyŋ xäjläse Qor’än γazyjmda bäjan ulynmyš* [Әлҗилдү рәбигу, б. 159] ‘Хатыннарның хәйләсе бөек Коръәндә тасвирланган’.

Әсәрләрдә шулай ук Коръән тексты белән бәйле булган *sürä* ‘*сүрә’* һәм *ajät* ‘аять’ сүзләре дә урын ала. Бу сүзләр тәрҗемәләрдә үзләренең туры мәгънәләрендә кулланыла: *Qor’än kärimneŋ süräläre ničäder?* [Әлҗилдү сәлисү, б. 272] ‘Коръән Кәримнең сүрәсе ничәдер?’; *Ägär insan bulsaŋ ajät uqy!* [Әлҗилдү рәбигу, б. 164] ‘Әгәр кеше булсаң, аять укы!; *Qoš xäbesdä waqytda... säcdä ajäten uqysa...* [Тутыйнамә, б. 2] ‘Кош хәбесдә вакытта... сәҗдә аятен укыса...’.

«Дини лексика» тематик төркемен кыйсса текстларында шулай ук әсәрләрнең лексик составында тулы бер катлам тәшкил иткән дини йола атамалары да тулыландыра. Алар башлыча номинатив күрсәткечләрдә тәкъдим ителәләр һәм чынбарлык объектларын белдерүдә актив катнашалар.

Бу төркемдәге иң еш кулланыла торган сүз – фарсы теленнән кергән *namaz* ‘намаз’ алынмасы. Намаз – ислам тарафыннан мәҗбүри язылган биш багананың берсе. Көндәлек цикл биш вакыт намаздан тора, аларның һәрберсенең үз исеме бар.

Татар телендә *namaz* лексемасы тәүлек вакытын билгеләү өчен дә кулланылган. Бу үзенчәлек өйрәнелә торган әсәрләрдә дә очрый, шулай ук хәзерге татар әдәби телендә дә сакланып калган. Мәсәлән, *Öjlädän ikende namazyna qadär...* [Әлҗилдү рәбигу, б. 195] ‘Өйләдән икенде намазына кадәр...’; *Jästü namazyn kičektereb uqymaqda küb säwab bardyr imdi* [Кырык вәзир, б. 72] ‘Ястү намазын кичектереп укуда күп савап бардыр...’.

Намаз уку тәртипләренә караган хәрәкәтләрнең берсе – сәҗдә кылу. Тәрҗемә текстларында әлеге төшенчә *säcdä* ‘сәҗдә’ сүзе белән белдерелгән һәм ул туры мәгънәдә кулланыла. Мәсәлән: *mäläk äl-mäwet axyr sacdädä canyn aldy...* [Әлҗилдү хәмисү, б. 5] ‘Әҗәл фәрештәсе (Газраил) соңгы сәҗдәдә (аның) җанын алды...’; *...jözen sacdägä qujyb Xaq Tăğalägä jalwaryb* [Кырык вәзир, б. 57] ‘...йөзен сәҗдәгә куеп, Хак Тәгаләгә ялварып...’; *Qoš... säcdä ajäten uqysa išetkän kešelärgä säcdä qylmaq läzim bulmas* [Тутыйнамә, б. 2] ‘Кош... сәҗдә аятен укыса, ишеткән кешеләргә сәҗдә кылырга кирәкмәс...’.

Текстларда гамәлдә булган дини терминнар арасында номинатив функцияне башкарган түбәндәге сүзләрне аерып күрсәтергә мөмкин: *xağ* ‘хаҗ’, *ruza* – ‘ураза’, *iftar* ‘ифтар’ ‘сыйлану’. Бу лексемалар текстларда дини семантиканы саклыйлар: *Šähär ählen dašeb, xağya baramyn dijeb* ... [Әлф ләйлә, б. 50] ‘Шәһәр халкын җыеп, хажга барам, диде...’; *Bu qarčyq köndezen ruza totyb kičen qaim bulyr ide* [Әлҗилдү сәни, б. 27]; ‘Бу карчык көндез ураза тотты, кич белән намаз укыды’; *Fäqat toz ikmäk ilä iftar idär ide* [Әлҗилдү сәни, б. 27] ‘Фәкать тоз-икмәк белән генә ифтар итәр иде’; *Zahid xağ šärifne tämam ideb öjenä kerde* [Тутыйнамә, б. 96] ‘Заһид хаҗ шәрифне тәмамлап, өенә кайтты’.

Хәзерге татар әдәби телендә *doğa* ‘дога’ сүзе өч мәгънәдә кулланылырга мөмкин: Аллаһы Тәгаләгә мөрәҗәгать итү, үтенеч, теләк, фатиха бирү [Татар теленең аңлатмалы сүзлеге, 2020, б. 201]. Тикшерелгән текстларда әлеге лексема ике мәгънәдә очрый. Беренчесе – номинатив мәгънәдә: *Atasynyŋ mädex sänasyna tel ačyb šundyj doğalar äjtde* [Әлҗилдү рәбигу, б. 178] ‘Әтисен мактарга керешеп, шундый догалар укыды’; *Siŋa ber doğa qylajyqmy* [Кырык вәзир, б. 52] ‘Сиңа бер дога укыйбызмы’; *Mal fani närsäder, doğa kiräk* [шунда ук] ‘Мал фани әйбер, дога кирәк’; *Doğasy Xodaj därgähendä qabul buldy* [Әбүгалисина, б. 23] ‘Догасы Ходай хозурында кабул ителде’ һ.б.

Шулай ук бу лексеманың *xäjer* ‘хәер’ сүзе белән бергә килеп, күчерелмә мәгънәдә кулланылган очрагы да теркәлде: *Mindän razyj bulyb xäjer doğa qylsaŋ, dönjany ber tamaša idär idem* [Кәлилә вә Димнә, б. 14] ‘Миннән риза булып, хәер-догаңны бирсәң, мин дөньяны күрер идем’.

Текстларда актив кулланылган дини лексиканың тагын бер төркеме – җәннәт, җәһәннәм, кыямәт, ахирәт кебек төшенчәләрне белдерә торган бакый дөнья белән бәйле сүзләр.

Җәннәт төшенчәсен белдерү өчен әкиятләрдә *cännät* (җәннәт), *näğim* (нәгыйм) һәм *ocmax* (оҗмах) дигән алынма сүзләр кулланыла: *Cännät ğyjlmanyndan bulyb donja ğalämen tamaša idärgä kilmešder...* [Әлҗилдү әс-сәни, б. 66] ‘Җәннәт әһелләреннән булып, дөнья галәмен күрергә килгәндер...’; *...ul bänem fani donjadan baqyj näğimgä baruymğa säbäb bulsa da...* [Әлҗилдү әс-сәни, б. 54] ‘…ул минем фани дөньядан бакый нәгыймгә күчүемә сәбәп булса да...’; *Aŋa jide qat kükne, sigez ocmaxny, jide tämuğny jöreb kürsätde* [Кырык вәзир, б. 7] ‘Ул аңа җиде кат күкне, сигез оҗмахны, җиде тәмугны йөреп күрсәтте’; *…Ocmax širbäte urynyna küreb* [Кырык вәзир, б. 32] ‘...оҗмах ширбәте урынына күреп…’; *Mahšäkär ocmax tawisy kedek tözäneb-jasanyb mäxbübe qatyna jünälde* [Тутыйнамә, б. 20] ‘Махшәкәр, төзәнеп-ясанып, сөеклесе янына юнәлде’ һ.б.

Гөнаһлары күп булган затлар үлгәч барачак урынны белдергән җәһәннәм төшенчәсе шул мәгънәдәге сүзләрнең киң спектры ярдәмендә бирелә: *cähännäm* ‘җәһәннәм’, *tamug* ‘тәмуг’, *kyjämät* ‘кыямәт; *jaumul xašr u mäxšär köne* ‘мәхшәр көне’; *axirät* ‘мәхшәр көне’; *zakum* ‘зәкум, тәмуг агачы’.

Болар арасында иң киң таралган сүз – *cähännäm* (җәһәннәм): *Xaq Täğalä anyŋ canyn alyb cähännämgä qujdy* [Әлҗилдү рәбигу, б. 7] ‘Хак Тәгалә аның җанын алып, җәһәннәмгә куйды’; *Allahy Täğalä any cähännämdä ğazab idäčäkder* [Кырык вәзир, б. 19] ‘Аллаһы Тәгалә аны җәһәннәмдә газаплаячак’; *Tösendä kyjämätne kürde* [Кырык вәзир, б. 98] ‘Ул төшендә кыямәтне күрде...’; *Wä Sirat küpere qorylğan, ocmax išekläre ačylğan, cähännäm utlary qyzdyrylğan* [шунда ук] ‘Сират күпере корылып куелган, оҗмах ишекләре ачылган, җәһәннәм утлары кыздырылган’; *Xalyqny… qajsyn ocmaxqa, qajsyn cähännämgä sörerlär* [шунда ук] ‘Кешеләрнең кайсын оҗмахка, кайсын җәһәннәмгә җибәрерләр...’.

Текстларда *qyjämät* ‘кыямәт’ сүзенең кулланылышы да үзенчәлеккә ия. Әлеге лексема «Мең дә бер кичә» әсәрендә *jawmu-l-qyjämä* ‘кыямәт көне’ изафә конструкциясе составында, туры мәгънәдә теркәлде. Мәсәлән: *Gömär ibn Xattabqa jawmu-l-qyjämätdä Xaq Cällä wä Gallä xäzrätläre sö’äl idär*... [Әлф ләйлә, б. 208] ‘Гомәр ибн Хаттабка яумүл-кыямәтдә Хак Җәллә вә Галлә хәзрәтләре сорау бирер…’. «Кәлилә вә Димнә» әсәрендә ул күчерелмә мәгънәдә кулланыла: *Tyb tynyč urmanda kük göreldäwdän wä jäšen jäšnäwdän… äjterseŋ qyjämät buldy*... [Кәлилә вә Димнә, б. 11] ‘Тып-тыныч урманда күк гөрелдәүдән һәм яшен яшьнәүдән... әйтерсең кыямәт башланды…’.

Тикшерелгән әсәрләрдә мәхшәр көне төшенчәсе ике төрле конструкция ярдәмендә белдерелә. Беренчесе – кулланыштан төшеп калган *jaumul hašrdä* (яумүл-хашер) изафә составында теркәлде: *Ägär hälaq bulsam jaumul xašrdä bänem qanym sindän soralyr* [Әлҗилдү рәбигу, б. 172] ‘Әгәр һәлак булсам, яумүл-хашердә (мәхшәр көнендә) минем каным өчен җавап синнән соралыр’; *jaumul hašrdä xaqymny sindän istärmen* [Әлҗилдү рәбигу, б. 151] ‘Яумүл-хашердә хакымны синнән таләп итәрмен’.

Икенчесе – бүгенге көндә әдәби норма булып саналган *mäxšär köne* конструкциясе белән бирелә: *mäxšär könendä Xaq Tägalä xäzrätlärenä närsä dib cawab birermen*... [Кырык вәзир, б. 81] ‘Мәхшәр көнендә Хак Тәгалә хәзрәтләренә нәрсә дип җавап бирермен...’.

Бакый дөнья, үлгәннән соңгы тормыш төшенчәсе өйрәнелә торган текстларда хәзерге көндә әдәби норма булып киткән *axirät* (ахирәт) сүзе ярдәмендә белдерелә. Мәсәлән: *Bän tiz jitešmägän bulsam, sine axirätkä jibärgännär ide imde*... [Әлф ләйлә, б. 175] ‘Әгәр мин тиз җитешмәгән булсам, сине ахирәткә җибәргән булырлар иде инде...’; *Sin dönja jortynda bolaj ğazab qyldyŋ axirätneŋ ğazaby jänä qatydyr* [Әлф ләйлә, б. 63] ‘Син дөнья йортында болай газап кылдың, ахирәтнең газабы тагы да көчледер’; *Dönja wä axirätdä däwlätle bulyb qal* [Кәлилә вә Димнә, б. 3] ‘Дөнья вә ахирәттә дәүләтле булып кал’ һ.б.

Анализлана торган текстларда *xur* ‘хур’ һәм *färeštä* ‘фәрештә’ лексемаларының метафорик кулланылышы да игътибарга лаек. Барлык әсәрләрдә дә алар, нигездә, персонажларның матурлыгын тасвирлау өчен кулланыла. Мәсәлән, *Xur kebi ğarijälär čornab alyan*... [Әлф ләй-

лә, б. 150] ‘Әйләнә-тирәсен хур кызлары кебек матур кызлар урап алган’; *Šämsetdinneŋ xatyny färeštä kebi ber matur qyz tuɣyrdy...* [Әлф ләйлә, б. 103] ‘Шәмсетдиннең хатыны фәрештә кебек матур кыз тудырды’; *Ǧänät xury misalynda känizäklär... toralar* [Әбүгалисина, б. 16] ‘Җәннәтәге хур кызлары кебек матур кәнизәкләр (басып) торалар’.

Әдәби телнең бер өлеше булган дини сүзләр төркемен *tahärät* ‘тәһарәт’, *räkäɣat* ‘рәкәгать’, *sadäqa* ‘сәдака’, *zäkät* ‘зәкәт’; *käfen* ‘кәфен’ кебек алынмалар да баета.

Шулай итеп, анализланган әсәрләрдә илаһи затны белдерү өчен *Allah* һәм *Täɣalä* лексемалары, *Täŋre* ‘Тәңре’ һәм *Xodaj* ‘Ходай’ сүзләре кулланыла. Аллаһы Тәгалә исемнәрен куллану текстның эмоциональ тәэсир көчен арттырырга мөмкинлек бирә.

Нәтиҗә ясап әйткәндә, кыйсса жанрындагы текстларда *Qor’än* ‘Кор′ән’, *namaz* ‘намаз’, *xaǧ* ‘хаҗ’, *ruza* ‘ураза’, *iftar qylu* ‘ифтар кылу, авыз ачу’, *tahärät* ‘тәһарәт’, *räkäɣat* – ‘рәкәгать’, *sadäqa* – ‘сәдака’, *zäkät* ‘зәкәт’; *käfen* ‘кәфен’ кебек лексемаларның киң кулланылуы күзәтелә. *Xur* ‘хур’ һәм *färeštä* ‘фәрештә’ кебек җәннәт әһелләрен белдергән сүзләр текстларда персонажларның матурлыгын тасвирлау өчен кулланыла. Әлеге категориягә караган сүзләр өстәмә мәгънә белдерми һәм килеп чыгышы ягыннан алынмалар булып торалар.

**Әдәбият**


*Баранов Х.К.* Арабско-русский словарь. М.: Русский язык, 1985. 944 с.

Древнетюркский словарь. Ленинград: Наука, 1969. 676 с.

*Әхмәтьянов Р.Г.* Татар теленең этимологик сүзлеге: ике томда. I т. (А–Л). Казан: Мәгариф – Вакыт, 2015. 543 б.

*Әхмәтьянов Р.Г.* Татар теленең этимологик сүзлеге: ике томда. II т. (М–Я). Казан: Мәгариф – Вакыт, 2015. 568 б.

ابوعلي سينا قصه سي ديمكله مشهور تخيلات ننك ترجمه سي.عبدالقيوم عبدالناصر اوغلي ننك ترجمات و تصنيفاتندار. قزان اونيويرسيتيتي ننك طبع خانه سنده باصمه اولنمشدر ١٨٩٤ نچي يلده. ١١٢ ب. = Әбүгалисина кыйссасы димәкле мәшһүр тәхйиләтнең тәрҗемәсе = Рассказы Абу Гали Сины. Казань: Изд-во Казан. ун-та. 1894. 112 с.

الف ليلة و ليلة،بو منكده بركيچه كتابنى ترجمه قيلدم عثمنلى تركي تلندن روسيه داكى مسلمانلر تركى تلينه محمد فاتح ملا حماد اوغلى خالدي،١٨٩٧ سنهده ٢١٢ ب. = Әлф ләйлә вә ләйлә = Тысяча и одна ночь. Т. 1. Казань: Изд-во Казан. ун-та. 1897. 212 с.

الجلد الثاني ترجمة الف ليلة و ليلة ايكنچى جلد منكده بركيچه ترجمه سيننك. بو منكده بركيچه كتابنى ترجمه قيلدم عثمنلى تركي تلندن روسيه داكى مسلمانلر تركى تلينه محمد فاتح ملا حماد اوغلى خالدي ١٨٩٧ سنه ده. اوشبو مننك ده بر كيچه كتابى قزان اونيويرسيتيتى نكن طبع خانه سنده بصمه اولنمشدرل قزان اويازى توبان قرصى آولى حاجى شمس الدين حسين اوغليننك ورثه لري خراجاتي ايلان اول مرتبه ١٨٩٨ يلده ١٦٠ ب. = Әл-җилдү әс-сәни тәрҗәмәти әлф ләйлә вә ләйлә = Тысяча и одна ночь. Т. 2. Казань: Изд-во Казан. ун-та. 1898. 120 с.

الجلد الثالث ترجمة الف ليلة و ليلة. اوچنچى جلد منكده بركيچه ترجمه سيننك. بو منكده بركيچه كتابنى ترجمه قيلدم عثمنلى تركي تلندن روسيه داكى مسلمانلر تركى تلينه محمد فاتح ملا حماد اوغلى خالدي اول مرتبه باصلوى قزان اونيويرسيتيتى نكن طبع خانه سنده بصمه اولنمشدرل ١٨٩٩ سنه ده. ٣١٨ ب. = Әлҗилдү әс-сәлисү тәрҗәмәти әлф ләйлә вә ләйлә = Тысяча и одна ночь. Т. 3. Казань: Изд-во Казан. ун-та, 1898. 286 с.

الجلد الرابع ترجمة الف ليلة و ليلة. درتنچى جلد منكده بركيچه ترجمه سيننك. بو منكده بركيچه كتابنى ترجمه قيلدم عثمنلى تركي تلندن روسيه داكى مسلمانلر تركى تلينه محمد فاتح ملا حماد اوغلى خالدي اول مرتبه

باصلوى قزان اونيويرسيتيتى نكن طبع خانه سنده بصمه اولنمشدرل ١٨٩٩ سنه ده. ٣١٨ ب. = Әлҗилдү рәбигу тәрҗәмәти әлфи ләйләти вә ләйлә = Тысяча и одна ночь. Т. 4. Казань: Изд. Казан. ун-та, 1899. 318 с.

الجلد الخامس ترجمة الف ليلة و ليلة. بشنچى جلد منكده بركيچه ترجمه سيننك. بو منكده بركيچه كتابنى ترجمه قيلدم عثمنلى تركي تلندن روسيه داكى مسلمانلر تركى تلينه محمد فاتح ملا حماد اوغلى خالدي اول مرتبه باصلوى قزان اونيويرسيتيتى نكن طبع خانه سنده بصمه اولنمشدرل ١٨٩٩ سنه ده. ١٩٢ ب. = Әлҗилдү хәмисү әлфи ләйләти вә ләйлә = Тысяча и одна ночь. Т. 5. Казань: Изд-во Казан. ун-та, 1899. 192 с.

الجلد السادس ترجمة الف ليلة و ليلة. الطنچى جلد منكده بركيچه ترجمه سيننك. بو منكده بركيچه كتابنى ترجمه قيلدم عثمنلى تركي تلندن روسيه داكى مسلمانلر تركى تلينه محمد فاتح ملا حماد اوغلى خالدي اول مرتبه باصلوى قزان اونيويرسيتيتى نكن طبع خانه سنده بصمه اولنمشدرل ١٨٩٩ سنه ده. ٣٨٢ب = Әлҗилдү сәдисү әлфи ләйләти вә ләйлә = Тысяча и одна ночь. Т. 6. Казань: Изд-во Казан. ун-та, 1899. 382 с.

طوطي نامه. عبدالعلام فيض خان اوغلي نك ترجماتندن. مطبعة كريميه، قزانده ١٩١٦. ١٧٥ ب . = Тутыйнамә = Тутыname. Казан: Матбага Кәримия, 1916. 175 б.

كليله و دمنه كتابي. بو كتاب باصمه اولنمشدر قزان اونيويريستيني ننك طبع خانه سنده١٨٨٩ نچى يلده. ٨٧ ب . = Кәлилә вә Димнә китабы = Книга Калилы и Димны. Казань: Изд-во Казан. ун-та, 1889. 87 с.

قرق وزير قصه سي، عثمانلى تلندن ترجمه قيلنوب قزانده اوچونچى مرتبه باصلدى. عبدالقيوم عبدالناصر اوغلي ننك ترجماتنداندر. قزانده انيويرسيتيت طبع خانهسنده باصما اولنمشدر ١٨٨٣ سنه ده.١٦٠ ب. = Кырык вәзир кыйссасы = Рассказы сорока визирей. Казань: Изд-во Казан. ун-та, 1883. 160 с.

***Гыйлемшин Флёр Фоат улы,***
*филология фәннәре докторы, доцент, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының баш фәнни хезмәткәре, «Россия Фәннәр академиясенең Казан фәнни үзәге» федераль тикшеренү үзәгенең әйдәп баручы фәнни хезмәткәре*

***Гыйлемшина Айсылу Габделҗәмил кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, Казан дәүләт медицина университетының рус һәм татар телләре кафедрасы доценты*

УДК 81'373.221

***И.И. Сабитова***

# ТАТАР ХАЛЫК АВЫЗ ИҖАТЫНДА ФИТОНИМНАР (кыска җырлар мисалында)

Статья посвящена исследованию употребления фитонимической лексики в татарском песенном творчестве. Выявлены названия растений в татарских коротких песнях, определены их тематические группы. Установлены фитонимы, обладающие высоким символическим потенциалом с учётом активности их употребления. Определены функции и роли фитолексики в рассматриваемых текстах.

**Ключевые слова:** фитоним, фитолексика, названия растений, лингвофольклористика, образ, символ, фольклор, короткие песни, татарский язык.

The article is devoted to the study of the use of phytonymic vocabulary in Tatar songwriting. The names of plants in Tatar short songs are revealed, their thematic groups are determined. Phytonyms with high symbolic potential have been identified, taking into account the activity of their use. The functions and roles of phytolexics in the texts under consideration are determined.

**Keywords:** phytonym, phytolexics, names of plants, linguofolcloristics, image, symbol, folklore, short songs, Tatar language.

Татар халык авыз иҗаты жанрының иң таралган төрләреннән берсе – дүрт юлдан торган кыска җырлар – дүртьюллыклар. Алар үзләренең күпсанлы булулары белән халык лирикасының башка төрләреннән аерылып торалар. Башка халыкларда да дүрт юллы җырлар популяр жанр санала. Лирик җырның бу төре төрле исемнәр астында төркиләрдә дә киң таралган. Төрки халыкларда бергәләп ял иткәндә еш кына кара-каршы җыр ярышы уздырылган. Җыр әйтешү вакытында һәркемгә шагыйрьлек сәләтен, зирәклек, тапкырлыгын күрсәтергә юл ачыла. Бер үк вакытта кара-каршы җырлашу кешеләр арасында аралашу хезмәтен дә үти [Татар халык иҗаты..., 1975, б. 8]. Кыска җырлар – халык көнкүрешенә аеруча якын торган жанр.

Татар лингвистикасының актив үсештәге өлкәләреннән берсе булган лингвофольклористиканың тикшерү объекты халык иҗаты текстлары булса, төп бурычы – фольклор телен өйрәнү. К.М. Миңнуллинның 2003 елда басылып чыккан «Һәр чорның үз җыры» китабы бу өлкәдә монографик пландагы беренче тикшеренү булып санала. Биредә автор татар җырлары текстларында тупланган сүз сәнгатен төрле яклап анализлый. Җыр текстларындагы сүзләрне берничә лексик-семантик төркемгә, төркемнәрне төркемчәләргә бүлеп өйрәнә [Миңнуллин, 2003, б. 280–360]. Тикшеренүче, статистик анализга нигезләнеп, җырларның лексик фондына тематик яктан зур төрлелек хас булу белән бергә, төркемнәрдә сүз сайланышы һәм кулланыш ешлыгының бердәй булмавын ассызыклый [Миңнуллин, 2003, б. 368].

Хәзерге көндә лингвофольклористикада ике юнәлештә эш алып барыла. Беренче юнәлеш халык авыз иҗаты әсәрләрен төрле яклап өйрәнү, ягъни фольклор әсәрләренең сүзлек составын ачыклау, аларның кулланыш үзенчәлекләрен өйрәнү, андагы лексиканың семантик, морфологик характеристикаларын билгеләү һ.б. үз эченә ала. Әлеге өлкәдә паремияләр (мәкаль-әйтемнәр, канатлы әйтелмәләр) шактый тирән өйрәнелгән. Икенче юнәлеш – сүзлекләр төзү [Галиуллин, 2018].

Татар тел белемендә фитонимик лексиканың кайбер аспектлары лингвистлар тарафыннан махсус тикшерелгән: этимологиясе, тарихи-генетик катламнары, номинацияләү принциплары, сүзьясалыш структуралары, диалектлардагы үсемлек атамалары һ.б. өйрәнелгән [Саберова, 1996; Хайретдинова, 2004; Ахметова 2012 һ.б.]. Төрле типтагы сүзлекләр дә төзелгән [Русча-татарча..., 1985; Саберова, 1997, 2002; Сабитова, Саберова, 2020 һ.б.]. Шул ук вакытта фольклор текстларындагы үсемлек атамаларын, алар белән бәйле лексиканы чагыштырма-тарихи, структур-чагыштырма планда өйрәнү лингвокультурологик тикшеренүләрнең актуаль объекты булып кала.

Тәкъдим ителә торган әлеге мәкаләдә татар халкының кыска җырлары текстларында фитонимнарның кулланылышы тикшерелә. Тикшерү өчен лексик материал тоташ сайлау методы белән «Татар халык иҗаты. Кыска җырлар (дүртьюллыклар)» [Татар халык иҗаты..., 1975] җыентыгыннан тупланды.

Гомуми тел беленең үсемлек атамаларын өйрәнә торган бүлеге (фитонимика) терминнарны конкрет төркемнәргә бүлеп тикшерә. Үсемлекләр дөньясына караган барлык лексемалар фитонимнар дип санала, биредә үсемлекләрнең үз атамалары, аларның анатомиясе һәм физиологиясе белән бәйле төшенчәләр дә күздә тотыла. Дендронимнар (агач һәм куак атамалары) – лингвистлар тарафыннан иң күп тикшерелгән төркем, чөнки алар югары шигъри һәм символик потенциалга ия. Шулай ук фитонимнардан чәчәк исемнәре дә шундый ук үзенчәлекләре белән аерылып тора.

Татар халкының кыска җырларын анализлау әлеге жанрның үсемлек атамаларына искиткеч бай булуын күрсәтә. Аларны, фитонимикадагы хәзерге классификациягә нигезләнеп, шартлы рәвештә түбәндәгечә тематик төркемнәргә бүләргә мөмкин:

а) **үсемлекләр белән бәйле гомуми төшенчәләр:** агач, иген, икмәк, үлән, печән, җимеш, гөл, җиләк, куак, уҗым, тирәк *(Агачта яфрак ничаклы, Бездә хәсрәт шул чаклы; Бу ел җәйне печән чаптым, Калын булды, кипмәде; Су сипмәгән гөлләр кебек Йөримен янып-көеп; Ерактан яшел күренә – Уҗым түгел, юлдыр ул...);*

ә) **үсемлекләр анатомиясе, физиологиясе белән бәйле атамалар:** кайры, ботак, кабык, чәчәк / чәчкә / сачәк, чәчәкләнү, бөре, бөреләнү, камыл, кыяк, сабак, тамыр, тармак, төп, туз, чыбык, ылыс, яфрак / җафрак, кузак *(Чәчәк идек илләрдә, Чәчелдек чит җирләргә; Яфрак төшә җирләргә Көзге каты җилләрдә; Ишеккәем алды куш*

*алмагач, Ботаклары саен карлыгач; Гөл булсак, айрылмас идек, Гөл тамырлары тоташ...);*

б) **агач һәм куак атамалары**: алмагач / алма агачы, артыш, зирек, имән, каен, карагай, миләш, нарат, сирень, тал, карама, тубылгы, туйра / туера, тут, усак, чыршы, шомырт / муел *(Каен гына агач тал булмас, Каен суы койган май булмас; Сездә шомырт чәчәктәме, Бездә шомырт чәчәктә; Өй артындагы миләшне Кемнәр әйтә балан дип...);*

в) **җиләк-җимеш һәм яшелчә атамалары:** алма, әфлисун / апельсин, әлвән җимеш / әлүчә, багалма, балан, (кызыл, кара) бөрлегән, виноград / йөзем, гөлҗимеш, җир җиләге / җир җиләк, (кызыл) карлыган, кура җиләге, лимон, чия, шомырт, бәрәңге, кавын, карбыз, кәбестә, кишер, кыяр, помидор, сарымсак, суган, шалкан *(Абау Алла, уф Алла, Бер ботакта биш алма; Су буенда уңган бөрлегән, Былбыл кошлар кунгач бөгелгән; Агыйделнең яры буенда Чәчәк аткан диләр бер кавын; Су буенда суганың, Су сипсәнә, туганым...);*

г) **бөртекле ашлык атамалары**: арпа, арыш, тары, бодай / богдай, борчак, (ак, күк) җитен, карабодай, көнбагыш, солы *(Күк күгәрчен бодайда, Минем җаныем кайда?; Җилфер-җилфер җилләр исә, Җитен башын җил кисә; Ерактан яшел күренә Арышның басулары...);*

д) **чәчәк һәм гөл атамалары**: бадьян / бадиан, фикус, (ал, зәңгәр, күк, сары, алсу) чәчәк, мәк / мәк чәчәге, умырзая, төнбоек, роза / роза гөле, рәйхан гөле, (кызыл, үрмә / үрмәле, чалмалы, тамчылы, зәйтүн, асыл, исле, ефәк, алмалы, кына, яран, төк) гөл, миләүшә, канәфер / каләнфер / каләмфер *(Иртә генә торып юлга чыксам, Очырадым умырзаяга; Сиңа охшатып бер генә төп Тамчылы гөл үстерәм; Исле гөл исле була, Яран гөл төсле була...);*

е) **кыргый үсемлек атамалары**: какы / кукы / куклык, кыяк үлән, курай, юа, сарут, тигәнәк, кырлы курай *(Болын сары була икән, Үләне сарут булса; Агыйдел буенда бер курай, Кунып сайрый шуңар бер тургай; Каенлыкларның какысын Җыеп ашар идем татлысын...);*

ж) **үсемлек бергәлек атамалары**: алан, андызлык, әрәмә, болын, зиреклек, имәнлек, каенлык, камышлык, куаклык, печәнлек, таллык, тамырлык, тирәклек, урман, урманлык, элмәлек, шомыртлык, чытырманлык *(Сандугачлар моңлы сайрый Әрәмәдә муелда; Кермә, җаный, камышлыкка, Камыш төбе су булыр; Җиләк җыям ялгыз гына Аланның алларыннан...).*

Җыр текстларындагы фитолексемаларны структур яктан тикшерү аларның сүзьясалыш мөмкинлекләрен ачыкларга ярдәм итә һәм әлеге потенциалның шактый зур икәнлеген күрсәтә: *алма – алма+лы, алма+чы, алма+агач, әнис алма; урман – кара урман, карурман (кара+ урман), урман+лык; тал – тал-тирәк, тал чыбык, бөдрә тал; чәчәк – чәчәк+ле, чәчәк+сез, (ал, зәңгәр, күк, сары, алсу) чәчәк; гөл – гөл+ле, гөл бакчасы / гөл+бакча, рәйхан гөле (кызыл, үрмә / үрмәле, чалмалы,*

*тамчылы, зәйтүн, асыл, исле, ефәк, алмалы, кына, роза, төк, яран) гөл* һ.б.

Кайбер гиперонимнарның гипонимнары да очрый: *алма – әнис алма; тал – бөдрә тал; чыршы – ак чыршы; чәчәк – миләүшә, мәк / мәк чәчәге, умырзая, төнбоек, зәңгәр (күк, сары) чәчәк; гөл – рәйхан гөле, (кызыл, үрмә / үрмәле, чалмалы, тамчылы, зәйтүн, исле, ефәк, алмалы, кына, роза, төк, яран) гөл* һ.б.

Семантик анализ текстларда үсемлек исемнәренең күп очракта туры мәгънәдә генә кулланылуын күрсәтә *(Кара урманнан узганда Карама кистем таякка; Безнең сулар бигрәк тонык, Чәчәк ата төнбоек; Ишек алдым яшел усак, Усак түгел, сарымсак...).* Икенчеләре җырга поэтик мәгънә бирә һәм төрле хис, сыйфат һ.б. чагылышы, символы булып хезмәт итә.

Кыска җырларда үсемлекләр дөньясына караган образлардан *алмагач, каен, имән, тал, камыш, мәк, җиләк, чәчәкләр, гөлләр* образы киң кулланылган. Шулар арасыннан *алмагач, алма бакчасы, каен, тал, исле гөл* образларының аеруча популяр булуын әйтергә кирәк.

Мәхәббәт лирикасында еш очрый торган *алма, чәчәк, тал* һәм *гөл* образлары матурлык символын гәүдәләндерә: *Алма кебек яр ташладым Дошман сүзләре белән; Исле гөлдә бер чәчәк бар, Өзмим, синең төсле ул; Буең зифа яшь тал кебек, Йөзең тулган ай кебек; Мәкнең ал чәчәге кебек Димәс идем сөймәсәм; Тамыр җәйгән гөлләр кебек Китмисең, йөрәгемнән; Гәүдәләрең күз алдымда Чәчәк аткан гөл кебек; Ал чәчәкләр синең төсле, Алып түшемә кадыйм; Алма кебек син матурны Кем бәхетле, шул сөяр* һ.б.

Мәхәббәт җырларында *чәчәк, чия, карлыган, алма, бөрлегән, шомырт* образлары лирик геройларның тышкы портретларын сурәтли: *Мәкнең ал чәчәге кебек Битләрең, иякләрең; Алма алсу, чия кызыл, Син шуларга охшаган; Камадай кара кашларың, Карлыгандай күзләрең; Шомырттан кара чәчеңне Алтын тарак белән тарыймын; Карлыганнан кара кашларың, Бөрлегәннән кызыл йөзләрең; И алма бит, алма бит, Алма битләр кала бит* һ.б.

Гомумән, кыска җырларда әлеге атамалар – лирик геройларның йөз чалымнарындагы гүзәллек, чибәрлек, нечкәлек, ягымлылык, сөйкемлелек символларын чагылдыручы образлар. Шул ук вакытта алар табигатьтәге, якын кешеләрдәге матурлыкны, тормыштагы гармонияне дә гәүдәләндерәләр: *Авылларның яме беткән, Чәчәксез гөлләр кебек; Кара безнең дус-ишләргә, Бакчада үскән гөл кебек; Алма чәчәкләре кебек Минем дус-ишләрем дә; Җыен дуслар арасында Мәк чәчәге кебек сез; Ал чәчәкләр кебек яшик, Бирешмик кайгыларга; Гөлләр кебек матурлана Безнең хәзерге көннәр* һ.б.

Кыска җырларда гомер *чәчәккә* тиңләштерелә. *Чәчәк* образы гомернең шатлыгын, матурлыгын, рәхәтлеген, шул ук вакытта тиз үтүен дә гәүдәләндерә торган символ булып тора: *Зур корсаклы байга саттым Чәчәк кебек гомерне; Чәчәк аткан җиләк кебек Кыз баланың гомере; Яшь гомерем чәчкә койды, Яңадан атмас инде; Вакыт җитми*

*яшь гомернең Чәчәкләрен коймагыз; Үткән гомремне охшатам Сулган умырзаяга* һ.б.

Татар халкында сары һәм кара төсләр кайгы билгесе булып санала. Кыска җырларда кайгы-хәсрәт, сагыш-сагыну, юксынудан туган күңелдәге төшенкелек, моңсулык *куак, тал, чәчәк, лимон* образлары аша бирелә: *Саргайган куаклар кебек, Саргайды инде йөзләрем; Сары тал яфрагы кебек Саргаясы бар икән; Мин саргайдым лимон кебек, Булмагыз минем кебек; Мескен солдат моңаядыр Сары чәчәк атканда; Сары лимоннан да сары Булды хәзер ак йөзем; Лимон сарылары керде Сине уйлап йөземә; Бүген төнлә төштә күрдем Карасу кара урман; Шул карасу кара урман Без айрылырга булган* һ.б.

Кыска җырларда *бадьян* / *бадиан* – бәхет символы: *Күпме йөрдем, күпме күрдем, Бадьян чәчкән җирләр юк; Бадьян чәчеп, бадьян алып Игелекләнер илләр юк.* Шулай ук *канәфер* образы да *бадиян* белән бергә килеп, бәхет эзләп туган җирләрен ташлап чит илләргә, чит җирләргә китүчеләрнең туган җирне сагыну, аны калдырып киткәнгә үкенү, ачыргалану, ялгызлыктан моңаюын да тасвирлый: *Канәфер белән бадиян Кайсы авыр мизанда; Канәфер авыр мизанда, Ризык кайда, без анда; Канәферләр белән, ай, бадиян Кай җирләрдә чәчәк ата икән? Кара да кашым, карлыгачым, Кай җирләрдә ялгыз ята икән?* һ.б.

Югарыда китерелгән мисаллардагы фитонимнар, бер яктан, җырга шигърилек, нәфислек бирүче тасвирлау чаралары булса, икенче яктан, чагыштыру функциясен дә үти.

Э.Р. Әхмәтова үзенең «Татар телендә яшелчә һәм җиләк-җимеш атамалары» дигән хезмәтенең V бүлегендә яшелчә һәм җиләк-җимеш атамаларының фольклор текстларындагы функциональ үзенчәлекләренә кыскача анализ бирә. Автор бу атамаларның мәкаль-әйтем, сынамыш, фразеологик әйләнмәләр һәм лирик җырларда башкарган функцияләрен билгели. Аның фикеренчә, яшелчә исемнәре күп очракта ирониялe, кимсетүле образ булдыруда катнаша, тискәре бәя бирә, ә җиләк-җимеш исемнәре мактау, уңай бәя бирү, матурлыкны тасвирлау яки хатын-кызларга, сөйгән ярларга мөрәҗәгать итү өчен кулланыла [Ахметова, 2012, б. 161–162].

Кыска җырларга килгәндә, яшелчә атамалары *(кәбестә, кишер, кыяр, помидор, сарымсак, суган, шалкан)* аларда туры мәгънәдә генә килгән. *Бәрәңге* сүзе җырга шаяру төсмере бирә: *Бүген төштә сине күрдем, Бәрәңге ашыйсың икән. Бәрәңгеле кулың белән Башың кашыйсың икән. Кәбестә* ямансулата, җан өшетә торган мохитне сурәтләргә ярдәм иткән: *Кәбестәдән өйрә пешә Без бәхетсез балага; Солдатларның ашаганы – Базда черегән кәбестә.*

Популяр жанр булган кыска җырлар татар халык авыз иҗатында аерым урын алып тора. Алар даими хәрәкәттә, үзгәрештә булып, халкыбызның үткәнен, хәзергесен, тарихи, иҗтимагый үзгәрешләрне, мәхәббәт дөньясын төрле образлар аша чагылдыралар. Анализ татарның кыска җырларында үсемлек исемнәренең еш кулланылуын

күрсәтә. Алар күпсанлы һәм күптөрле булулары белән дә аерылып тора. Күбесе бары туры мәгънәдә генә очрый. Кайберләре төрле символик мәгънәгә ия. Бу татар халкының мәдәнияте, милли үзенчәлеге, яшәү рәвеше, тышкы дөньяны образлы кабул итүе белән бәйле. Үсемлек исемнәре кешенең эчке психик, рухи халәтен, конкрет эмоцияләрен сурәтләү функциясен башкара. Матурлык, гүзәллек символларын гәүдәләндерүче образлар буларак, мәхәббәт хисләрен, тойгы-кичерешләрне тасвирлауда *чәчәк, чия, карлыган, алма, бөрлегән, шомырт* атамалары аеруча актив. *Алмагач, каен, имән, тал, камыш, мәк, җиләк, чәчәк, гөл* сүзләре югары кулланышка ия булулары белән аерылып тора.

**Әдәбият**

*Ахметова Э.Р.* Названия овощей и фруктов в татарском языке: дис. ... канд. филол. наук: 10.02.02 . Казань, 2012. 245 с.: ил.

*Галиуллин К.Р.* Татар фольклоры теле: мәкальләр, канатлы әйтелмәләр, җор сүзләр һәм әйтемнәр: сүзлек. Казан: ТӘһСИ, 2018. 588 б.

*Миңнуллин К.М.* Һәр чорның үз җыры. Казан: Мәгариф, 2003. 400 б.

*Миңнуллин К.М., Сабитова И.И.* Татар халкының борынгы җырларында соматизмнар һәм аларның функциясе // Фәнни Татарстан. 2022. № 1. Б. 15–22.

Русча-татарча биология терминнары сүзлеге. Казан: Татар. кит. нәшр., 1985. 198 б.

*Саберова Г.Г.* Названия растений в татарском литературном языке. Казань, 1996. 130 с.

*Саберова Г.Г.* Русско-татарский словарь для работников лесной промышленности. Казань: Татар. кн. изд-во, 1997. 66 с.

*Саберова Г.Г.* Татарско-русско-латинский словарь названий растений. Казань: Фикер, 2002. 96 с.

*Сабитова И.И., Саберова Г.Г.* Үсемлек атамаларының татарча-русча аңлатмалы сүзлеге. Казан: ТӘһСИ, 2020. 216 б.

Татар халык иҗаты. Кыска җырлар (дүртьюллыклар). Казан: Татар. кит. нәшр., 1976. 392 б.

*Хайрутдинова Т.Х.* Народные названия растений в татарском языке. Казань: Фикер, 2004. 224 с.

*Хәйретдинова Т.Х.* Табигать концепты: үсемлекләр дөньясы. Казан: ТӘһСИ, 2017. 384 б.

***Сабитова Илһамия Исламетдин кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының лексикография бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре*

УДК 81'373

***Э.И. Сафина***

# ГАРӘП ҺӘМ ФАРСЫ ТЕЛЛӘРЕННӘН КЕРГӘН ОРНИТОЛОГИК ЛЕКСИКА

Статья посвящена исследованию арабо-персидских заимствований в орнитологической лексике татарского языка. Как показывает анализ, из арабского и персидского языков было заимствовано множество названий птиц и слов, связанных с птицами. Часть из них стала основными общеупотребительными орнитонимами татарского языка (*былбыл, тавис, тутый, һөдһөд, һомай* и др.), которые воспринимаются как собственные слова. В то же время есть орнитонимы, которые утратили активность (*гораб, гасфур, шәбгир* и др.). Некоторые названия не используются в литературном языке, но существуют в диалектах (*хорус*), некоторые встречаются в лексикографических источниках и художественной литературе (*шаһбаз, шаһин, әбабил, гандәлиб* и др.).

**Ключевые слова:** орнитоним, орнитологическая лексика, заимствование, татарский язык, арабизм, фарсизм, терминология.

The article is devoted to the study of Arabic-Persian borrowings in the ornithological vocabulary of the Tatar language. As the analysis shows many bird names and words related to birds were borrowed from the Arabic and Persian languages. Some of them have become the main commonly used ornithonyms of the Tatar language (*bylbyl, tavis, tuty, khodhod, khomai,* etc.), which are perceived as their own words. At the same time there are ornithonyms that have lost their activity (*gorab, gasfur, shabgir,* etc.). Some names are not used in the literary language but exist in dialects (*horus*), some are found in lexicographic sources and fiction (*shahbaz, shahin, ababil, gandalib,* etc.).

**Keywords:** ornithonym, ornithological vocabulary, borrowing, Tatar language, Arabism, Persian word, terminology.

Бүгенге көндә татар әдәби телендә кулланыла торган кош атамаларының бер өлешен чит телләрдән кергән орнитонимнар тәшкил итә. Рус яки башка телләрдән кабул ителгән терминнарның алынма икәнлеге ачык күренеп торса, гарәп яки фарсы теле атамалары тулысынча диярлек үзләшеп беткән.

Гарәп һәм фарсы телләреннән кергән орнитологик лексика *кош атамаларын* һәм *кошлар белән бәйле сүзләрне* (әгъза-органнар, яшәү-оялау урыннары һ.б.) үз эченә ала. Кош атамаларын ике төркемгә бүлеп тикшерергә мөмкин. Беренчесе – телебездә кабул ителгән һәм күп еллар дәвамында татар теленең үз сүзләре кебек кулланыла торган орнитонимнар, икенчесе – бүгенге көндә кулланылмый торган атамалар. Үткән гасырларда гарәп һәм фарсы телләреннән алынган орнитонимнар еллар узу белән акрынлап кулланылыштан төшеп кала барган. Иң тотрыклылары һәм бүгенге көндә актив кулланылыштагылары түбәндәгеләр: *былбыл* (بلبل), *ләкләк* (لقلق), *тавис* (طاوس),

*тутый (тутый кош)* (طوتي), *һөдһөд* (هدهد), *һомай* (هما), *сәмруг* (سيمرغ), *ганка* (عنقا).

**Былбыл** (بلبل) – гомумтөрки *сандугач* орнитонимының поэтик жанрда кулланыла торган синонимы. Көндәлек тормышта *сандугач* варианты актив булса да, *былбыл* атамасы борынгы әдәбиятта һәм бүгенге көн әдәби әсәрләрдә еш очрый, яраткан кешегә мөрәҗәгать сүзе буларак та кулланыла (*былбыл, былбылым*). Эпитетлар, чагыштырулар, фразеологизмнар составында татар телендә генә түгел, башка төрки телләрдә дә очрый. Матурлык, гүзәллек символы буларак, хатын-кыз исемнәренә күчкән [Саттар-Мулилле, 1998, б. 346]. – *Мине сагындыңмы соң? – диде кызый,* ***Былбыл*** *апасының юлына аркылы төшеп* [Фәттах, 2002, б. 125]. *Бульбуль* формасында рус теле диалектларында да бар [Малыхина, Писарева, 2013, с. 172].

**Тавис** (طاوس) (ГТРАС, 1965, т. 2, б. 538; *тавус* (طاوس), *тавис кошы* дип бирелә). Берничә гасыр дәвамында кулланылып килә торган атама борынгы язма чыганакларда да очрый. Хатын-кыз исеме буларак, М. Кашгари сүзлегендә [Мусаев, 1984, с. 216], *tawic, taus* (*таус*, ар.) формасында «Codex Cumanicus» сүзлегендә [Махмутова, 1982, с. 131] теркәлгән. С. Хәлфин һәм А. Троянский хезмәтләрендә *таузы кош* дип бирелә [Сафина, 2005, с. 186].

**Тутый** (тутый кош) (طوتي) атамасы фарсы теленнән кергән. Татар телендә, *попугай* кошын белдерүдән тыш, «үз фикере булмыйча, башкаларның сүзен, фикерен кабатлаучы, кешегә ияреп эш итүче кеше» дигән күчерелмә мәгънәдә дә кулланыла [ТТАС, 2019, т. 5, б. 824]. Татар телендәге тезмә *тутый кош* атамасы кушма атамага (*тутыйкош*) әйләнеп бара. *Тутыйкош* орнитонимы күчерелмә мәгънәдә «кәпрәеп, эреләнеп йөрүче кеше», «киемнәре белән башкалардан аерылып тора торган, гадәттә, купшы, чуар киенгән кеше», «ир-атларның күзе төшә торган яшь, чибәр хатын-кыз» мәгънәләрен белдерә [шунда ук, б. 824]. Мишәр диалектының хвалын сөйләшендә *тутый* орнитонимы урынына *түти* варианты йөри: *Былбыл микән, түти микән* [ТТЗДС, 2009, б. 668].

**Ләкләк** (لقلق) орнитонимы гарәп теленнән кергән. Ул кошлар чыгарган авазларга охшатып ясалган. Орнитологик лексикада мондый күренеш еш очрый: атамалар гадәттә кошларның сайрау, кычкыру тавышлары нигезендә барлыкка килә [Сафина, 2005, с. 133–134]. Искәрмә буларак, *ләкләк*нең нинди авазларга, тавышларга охшатылуы турында бердәм фикер юк. Мисал өчен, фәнни әдәбиятта канат каккан тавышларга [Сетаров, 1970, с. 94; Петров, 1982, с. 60], томшык шакылдаткан тавышларга [Шипова, 1977, с. 222], тел шартлаткан авазларга [Радлов, 1905, т. 3, с. 729] бәйле рәвештә исем бирелгән, дигән фикерләр очрый. Р.Г. Әхмәтьянов атаманы «кайгыру, кайгырып кычкыру; ләкләк» сүзеннән дип саный [Әхмәтьянов, 2015, т. 1, б. 534].

Гарәп теленнән кергән **һөдһөд** (هدهد) [ГТРАС, т. 2, б. 791] атамасы рус телендәге *удод* кошын белдерү өчен кулланыла башлаган. Әдәби

телдә әлеге кошны атау өчен башка орнитоним юк. Урта диалектның каргалы сөйләшендә *һөдһөд* атамасы урынына *пупуп* орнитонимы йөри [ТТЗДС, 2009, б. 543]. Татар исемнәрен өйрәнгән Г.Ф. Саттаров орнитонимның антропоним буларак кулланылуын да теркәп калдырган [Саттар-Мулилле, 1998, б. 458]. А.К. Тимергалин сүзлегендәге мәгълүматлар *һөдһөд*нең мифик кош булуын ассызыклый: «Сөләйман патша белән аның мәгъшукасы Билкыйс арасында хәбәр йөрткән мифик кош, Коръәндә дә телгә алына. *Һөдһөд* кошын фарсыларда «мөрг Сөләйман» дип атыйлар. Билкыйснең һөдһөде җәннәткә керәчәк икән. Һөдһөдкә гарәпләр һәм греклар ихтирам белән караганнар, аның турында күпсанлы хикәятләр һәм мәсәлләр бар» [Тимергалин, 2007, б. 534].

**Һомай** (هما) атамасына «Гарәпчә-татарча-русча алынмалар сүзлеге»ндә түбәндәге аңлатма бирелгән: **Һома (һөма)** (1 (هما) Бәхет кошы (күләгәсе кемгә төшсә, аңа чиксез бәхет китерә дип йөртелгән мифик кош исеме); 2) «Бәрән карак» бөркет. Һавалар тын ... кисеп очкан һөма юк. (Дәрд.) [ГТРАС, 1965, т. 2. б. 785]. «Фарсыча-русча сүзлек»тә орнитонимның кеше исеме буларак кулланылуын аңлаткан өченче мәгънәсе дә бар [ПРС, 1985, т. 2, с. 721–722]. Һомайга «әкият кошы, затлы бөркет, феникс, җәннәт кошы» дип аңлатма биргән Л.З. Будагов фикеренчә, «бик биектә оча һәм беркайчан да җиргә төшми торган әлеге кошның күләгәсе берәр кешегә төшә икән, ул патша дәрәҗәсенә ирешә, бик бәхетле була» [Будагов, 1871, т. 2, с. 315]. Бу фикер А.К. Тимергалинда да бар: «Шуңа күрә Иран патшаларын *һумаюн* «бәхет иңгән» дип тә атыйлар» [Тимергалин, 2007, б. 150]. Галим теркәп калдырган *дәүләт һомае* (дәүләт кошы, ягъни дәүләтнең дәрәҗәле кешесе) тезмәсе әлеге сүзләрне тагын да дәлилли кебек [шунда ук, б. 150].

Орнитоним С. Сараиның «Гөлестан» әсәрендә мифик кош буларак телгә алынса [Сараи, 1999, б. 44, 54], Котбның «Хөсрәү вә Ширин»ендә бәхет кошы буларак бирелгән [Котб, 2003, б. 43]. *Һомай* татар халык әкиятләрендә күп очрый, төшлекләрдә телгә алына. «Төшеңдә һөдһөд кошын күрсәң, зур галим һәм ачык гыйлем иясе булырсың, диелә (Төхфәтел-мөлек) китабында» [Төшлек..., 1997, б. 324].

Фарсы теленнән кергән **сәмруг** (семург سیمرغ симорг, *миф.* симург [ПРС, 1985, т. 2, с. 81]) орнитонимына «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә түбәндәге аңлатма китерелә: **СӘМРУГ** *и. фар.* 1) Фарсы мифологиясеннән төрки халыклар, шул исәптән татар фольклорына кергән зур, көчле һәм бик зур тизлек белән оча торган кош образы (күп очракта бәхет символы); 2) *куч.* Россия гербындагы ике башлы бөркет [ТТАС, 2019, т. 5, б. 91].

«Сәмруг кошны Борынгы Шәрык халыклары күзаллавындагы «Бәхет кошы» – *Гамаюн, Һумай, Һома* белән чагыштыру да бар. Гәрчә сәмруг кош соңгысына караганда югарырак дәрәҗәдә тора» [Урманче, 2009, т. 2, б. 324]. «Кайвакыт исеме дә төрлечә булырга мөмкин: бөркет, каракош, алыпкаракош» [шунда ук, б. 323]. Р.Г. Әхмәтьяновта

орнитоним *сәмрәү [сәмрәw], сәмер кош* дип бирелә. Элек халык шул вариантын кулланган, ә *сәмруг, сәмруг кош* дигәне китапларда гына очраган дип уйларга нигез бар. «*Сәмрәү* сүзен гадичә *сийаһ мург* «кара кош» дип тә аңлаталар» [Әхмәтьянов, 2015, т. 2, б. 154].

Исеме гарәп теленнән кергән икенче мифик кош – **ганка**. «Гарәпчә-русча-татарча алынмалар сүзлеге»ндә аңлатмасы түбәндәгечә: **Ганка** (عنقا) Ганка (исеме бар, үзе юк бер мифик кош исеме). *сущ. миф.* Грифон, феникс [ГТРАС, 1965, т. 1, б. 80–81]. «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә төп мәгънәсеннән тыш, күчерелмә мәгънәсе дә бирелә: **ГАНКА** *и. гар. миф.* 1) Каф тавы артында яши дип саналган мифик кош. *Йомыркасы ганка йомыркасы кадәрле була, ди.* Г. Газиз; 2) *күч.* Ахмак, аңгыра кеше. *Әллә ничә йирдән кунаклар адресына «Ганка!» дигән сүз йибәрелде.* Г. Исхакый. *Кәримовлар Шакирҗаны унбиш төрле хат таный, Бу дөньяда табалмассың аның төсле ганканы.* Ш. Хәлиди [ТТАС, 2016, т. 2, б. 45].

*Ганка булма* ‘не будь болваном’ әйтелмәсендә *юләр булма, йоклап калма, мөмкинлегеңне кулдан ычкындырма* дигән мәгънә дә тоемлана, *ганка йомыркасы* искиткеч зур булуны белдерә: «**ганка йомыркасы кадәр** слишком большой, величиной с яйцо анки; **ганка йомыркасы кадәр шатлык** *ирон.* радость величиной с яйцо анки» [ТРС, 2007, т. 1, б. 305].

Р.Г. Әхмәтьянов фикеренчә, «***канка*** ‘күркә’, ихтимал, *ганка* сүзеннәндер. Татарлар күркәнең сәер кыяфәтен күргәч шулай атаганнар» [Әхмәтьянов, 2015, т. 1, б. 230] (к.: КАНКА [рус.] *күрш.* күркә (индюк). *Алаша да тытабыз, сир, куй, үрдәк, канка* [ТТЗДС, 2009, б. 272].

Бүгенге көндә кулланылмый торган орнитонимнар арасында кошларны белдерә торган гомуми атамалар шактый күп. Кош мәгънәсен белдергән **мөргъ** (مرغ) сүзе шундыйлардан. Ул башка атамалар составында да очрый: **мөргъ Сөләйман** – һөдһөд (кош), **мөргъ сәхәр** – таң кошы (сандугач). Сүзлектә шул ук нигездән ясалган **мөрганә** (кош йомыркасы) сүзе дә теркәлгән. Кош мәгънәсен аңлата торган икенче орнитоним – **таир** (طائر). Аның беренче мәгънәсе – очучы, очкыч, икенче мәгънәсе – кош [ГТРАС, 1965, т. 2, б. 539]. Күплек сандагы **таер** (طير) – кошлар варианты да бирелгән [шунда ук, б. 538]. *Кошлар галиме, кошлар белгече* дигән мәгънәдәге **таериюн** (طيريون) сүзе дә шул ук тамырдан [ГТРАС, 1965, т. 2, б. 539].

Аерым бер кошны белдерә торган орнитонимнар: **дөҗаҗ** (دجاج) тавык, **гораб** (غراب) карга, козгын, **гасфур** (عصفور) кечкенә кошчык; чыпчык, **хәмамә** (حمامه) күгәрчен, **һәзар дастан** (هزاردستان) сандугач, **хәттаф (хоттаф)** (خطاف) карлыгач, **шәбгир** (شبگير) сандугач, **хорус (хоруз)** (خروس، خروز) әтәч, **кәбүтәр** (كبوتر) күгәрчен, **шаһбаз** (شاهباز) лачын, **шаһин** (شاهين) һ.б.

Бер үк вакытта карганы да, козгынны да белдерү өчен кулланыла торган **гораб** (غراب) орнитонимын борынгы әдәбиятта очрата алабыз. Гарәп алынмасы буларак ул «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»нә дә

кертелгән: **Гораб** *и. гар. иск.* 1) Карга; 2) Козгын. *Син гораб диб уйлаганың асле шоңкар улмасын.* М. Акмулла [ТТАС, 2016, т. 2, б. 89].

**Гасфур** (عصفور) орнитонимы шулай ук ике мәгънәне белдерә. Бердән, аны чыпчык кошларны, икенчедән, гомумән кечкенә кошларны атау өчен кулланганнар. Мисал өчен, *чыпчык* мәгънәсендә К. Насыйрида очрый: *Бәс, бу Нәсар мәсәл тарикынча: «Әй әмир, бер карчыга бер гасфурны тотып очканда, бичара чыпчык карчыганың тырнагында икән, карчыгага әйтте, бу аз вә кечкенә нәрсә синең кебек олуг кошка локмә булмас, ягъни минем белән карының туймас, мине азат кыйлсана, дип, мәрхәмәт эстәде. Бәс, карчыга ул чыпчыкка кәрәм итеп, тырнагыннан ычкындырып азат кыйлды», – дигәч, хәлифә дәхи Нәсарны азат кыйлды* [Насыйри, 2004, б. 30].

Карлыгачларны белдерү өчен кулланылган **хәттаф (хоттаф)** (خطاف) атамасының татар әдәби телендә эзе калмаган диярлек. Хәтта К. Насыйрида да ул синонимы белән бергә килә: *Хәҗәре хәттаф, ягъни карлыгач ташы димешләрдер, ки карлыгач оясында булыр* [ГТРАС, 1965, т. 2, б. 687].

**Хорус (хоруз)** (خروس، خروز) этәч орнитонимы татар әдәби телендә кулланылмый, әмма диалектларда очрый әле. Мәсәлән: **ҠОРОС** [*фарс.*] *брб.д., том.д.* этәч (петух). Ҡорос ҡыйгырады. – *брб.д.* [ТТЗДС, 2009, б. 416]; **ҠУРАЗ** [*фарс.*] *эчк., әстр.* к.: кучат. Ҡураз йөзөмгә кергән. – *әстр.* Ҡураз суйгалы барам. – *эчк.* **ҠУРАС** II [*фарс.*] *әстр., себ.* к.: кучат. Ҡурасны тотып йелбәйте. – *төм.*; **әмәл ҡурас** *төм., төб.* яз көне балаларга кош рәвешендә пешереп ашатыла торган камыр ашы; **ҡурас маңнау** *туб.-ирт.д.* этәч кычкыру; **ҠУРАЦ** *туб.-ирт.д. к.:* кучат. Ҡурацым та бар, цибеш палларым та кән. – *тбл.*; **ҠУРАЦЛАП** *төм.* этәч рәсеме төшереп. Питйаулыҡны суҡҡаннар ыспайы итеп, ҡурацлап тороп [ТТЗДС, 2009, б. 428].

Күгәрчен кошларны белдерә торган **кәбүтәр** (کبوتر) орнитонимында کبود (кәбүд) сүзе күгәрченнең төсен белдерә [ГТРАС, 1965, т. 1, б. 307]. Атама XVII гасыр сүзлегендә *кәптәр* (*кугярцин*) формасында теркәлгән [Ногман, 1969, б. 49–50]. *Кабутаров* фамилиясе составында кулланылган [Саттар-Мулилле, 1998, б. 126]. Аңлатмалы сүзлектә *кәбүтәр* [ТТАС, 2017, т. 3, б. 195], диалектологик сүзлектә *кәптәр* формасында теркәлгән. Кәптәрләр пала цыҕарып куйҕаннар. – *төм.* [ТТЗДС, 2009, б. 290].

**Шаһбаз** (شاهباز) *ф. ис.* 1) карчыга; лачын, шункар; 2) Батыр, кыю. *Рабиганың матур тавышы моңлы, назлы; назы белән яулап ала ир шаһбазны.* (Ш. Баб.) [ГТРАС, 1965, т. 2, б. 701]. Күчерелмә мәгънәсе «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә дә бирелә: **ШАҺБАЗ** *и. фар. иск.* 1) *к.* **лачын**. *Шаһбазлар Каф тавына күчеп киткән, Урыныңа – козгын, байгыш куныл калган.* М. Акмулла; 2) *күч.* Батыр, куркусыз кеше. *Ирәннәргә торыр ир шаһбазы Аудан кайта дала буйлатып.* С. Әхмәтҗанова [ТТАС, 2019, т. 6, б. 542]. *Шаһбаз ирләр* дигән формада да кулланылган [ТРС, 2007, т. 2, б. 612]. Орнитонимның **шәһбаз** варианты да бар (**шәһбаз** شهباز кара: шаһбаз) [ГТРАС, 1965, т. 2, б. 715].

«Гарәпчә-русча-татарча алынмалар сүзлеге»ндә «аксыл төстәге лачын, шункар (ау лачыны)» дигән мәгънәдә **шаһин** (شاهين) атамасы теркәлгән [ГТРАС, 1965, т. 2, б. 701]. Орнитоним татар теленең аңлатмалы һәм башка сүзлекләренә дә кергән. *Шаһбаз* һәм *шаһин* атамаларының ир-ат исемнәре һәм *Шаһбазов*, *Шагинов* фамилияләре составында кулланылуы билгеле. [Саттаров, 1990, б. 35].

**Әбабил** (ابابيل) термины сүзлекләрдә *керәшә, яр карлыгачы* дип бирелә. «Бу сүз Коръәннең «Фил» сүрәсендә кулланылган, шуннан татарча тәфсирләргә һәм дини китапларга алынып таралган» [Әхмәтьянов, 2015, т. 1, б. 121]. *Әбабилов, Бабилов* фамилияләре составында теркәлеп калган [Саттар-Мулилле, 1998, б. 309].

**Гандәлиб** (عندليب) – сандугачларны атау өчен кулланылган орнитоним [ГТРС, 1965, т. 1, б. 80]. Гарәп теленнән кергән атама әдәби әсәрләрдә дә очрый, сүзлекләрдә дә теркәлгән (**ГАНДӘЛИБ** *и. гар. иск. кит.* Сандугач, былбыл. *Күрүбән гандәлибаны, тамаша әйләдем сәйран.* Г. Тукай [ТТАС, 2016, т. 2, б. 44]). Хатын-кыз исеме буларак актив булган: *Нотфый гел шулай кунакчыл булганга, **Гандәлиб** апаны борчымыйлар, хәер моны ул белми дә кала иде* [Мәһдиев, 1981, б. 60]. *Гандәлиф* (Гандалиф) варианты да бар [Саттар-Мулилле, 1998, б. 352]. Кош атамаларының төрле елларда сүзлекләрдә бирелешен чагылдырган таблицадан күренгәнчә, XIX йөз ахыры – XX йөз башы лексикографик чыганакларының кайберләрендә өч атама (*сандугач, былбыл, гандәлиб*) синоним буларак китерелә [Сафина, 2005, с. 192].

**Шәбгир** (شبگير) орнитонимы – *сандугач* мәгънәсендә фарсы теленнән алынган термин. «Гарәпчә-татарча-русча алынмалар сүзлеге»ндә *шәбгир* сүзенең өч мәгънәсе бирелә. Төп мәгънәсе *төнге* сүзе белән бәйле булса, икенче мәгънәсе – *сандугач*. К.: **Шәбгир** (شبگير) **1.** Төнге. **2.** 1) Сандугач; 2) Төнге сәяхәт, яктыргангача сәяхәт. *Гарипнең кабригә шәбгир кылгыл* (Сайяди) [ГТРАС, 1965, т. 2, б. 706]. Орнитоним телебездә озак кулланылмаган, аңа гомумтөрки *сандугач* атамасы киң таралырга ирек бирмәгән. Мисаллардан күренгәнчә, гарәп һәм фарсы телләреннән *сандугач*ларны белдергән берничә атама (*былбыл, гандәлиб, шәбгир*) кергән, тик барысы да сакланып калмаган. Бу табигый күренеш. Билгеле булганча, «телдәге экономия законы уңышлырак синонимнары булган кайбер сүзләрнең пассив лексикага күчүенә китерергә мөмкин: *гандәлиб – сандугач, былбыл*» [Татар лексикологиясе, 2016, т. 2, б. 312].

Гарәп һәм фарсы телләреннән кабул ителгән **кошлар белән бәйле сүзләр** түбәндәгеләр:

**Кошларның әгъза-органнары, гәүдә өлешләре: хәусалә** (حوصله) кош бүксәсе; **шаһбал** – кош канатының иң зур кауры, чылгый; **җәнах** (جناح) канат; **тадж** (تاج) – кош кикриге. Әлеге алынмалар арасыннан бүгенге көндә *таҗ* сүзе генә кулланыла, әмма аның да *кош кикриге* мәгънәсе инде югалган.

**Кошларның яшәү, оялау урыннары: ашъян, әшьян** (آشيان) оя, кош оясы; **кяшанә** (كاشانه) оя, кош оясы; **кафәс** (قفس) читлек. *Кафәс*

сүзенең киңрәк мәгънәләре дә бар. К.: 1) Читлек. *Кафәс эчендә күрсәң кош вә тоюр хәлас кыйл ул кафәсдин, сән зарур.* (Мөхм.). 2) (Тәрәзәләрдә) рәшәткәле каплагыч. 3) Челтәрсыман, рәшәткәсыман ясалма әйберләр [ГТРАС, 1965, т. 1, б. 207].

Анализдан күренгәнчә, татар теленә гарәп һәм фарсы телләреннән бик күп кош атамасы һәм кошлар белән бәйле сүзләр кабул ителгән. Вакытлар узу белән орнитонимнарның күбесе онытылган, активлыгын югалткан *(дөҗаҗ, гораб, гасфур, хәмамә, һәзар дастан, хәттаф, шәбгир)*. Кайбер атамалар әдәби телдә кулланылмый, әмма диалектларда бар, икенчеләрен әдәби әсәрләрдә яисә сүзлекләрдә очратырга мөмкин. Аерым кош атамалары исем һәм фамилияләр составында теркәлеп калган, тик әкренләп әлеге фамилияләр дә юкка чыга бара. Кошлар белән бәйле сүзләр *(җәнах, хәусалә, кафәс, ашъян)* татар әдәби телендә бүгенге көндә бөтенләй кулланылмый.

Шунысын да ассызыкларга кирәк: алынмаларның күбесе төшеп калган булса да, гарәп һәм фарсы телләреннән кергән орнитонимнарның бер өлеше татар теленең киң кулланыштагы төп атамаларын тәшкил итә. Болар – *былбыл, ләкләк, тавис, тутый, һөдһөд, һомай, сәмруг.* Алар татар теленең үз сүзләре кебек кабул ителә, татар орнитологик лексикасын баетып тора.

**Әдәбият**

*Әхмәтьянов Р.Г.* Татар теленең этимологик сүзлеге: ике томда. I т. (А–Л). Казан: Мәгариф – Вакыт, 2015. 543 б.

*Әхмәтьянов Р.Г.* Татар теленең этимологик сүзлеге: ике томда. II т. (М–Я). Казан: Мәгариф – Вакыт, 2015. 567 б.

*Будагов Л.З.* Сравнительный словарь турецко-татарских наречий, со включением употребительнейших слов арабских и персидских и с переводом на русский язык: в 2-х т. СПб.: Тип. Имп. Акад. наук, 1869. Т. 1. 810 с.; СПб.: Тип. АН, 1871. Т. 2. 415 с.

Гарәпчә-татарча-русча алынмалар сүзлеге: ике томда. Казан: Татар. кит. нәшр., 1965. 853 б.

*Котб.* Хөсрәү вә Ширин (шигъри роман). Казан: Мәгариф, 2003. 367 б.

*Малыхина Т.М., Писарева Л.Е.* Этимологическое исследование наименований соловья в русских народных говорах // Учёные записки. Электронный научный журнал Курского государственного университета. 2013. № 2. С. 171–174.

*Махмутова Л.Т.* Татарский язык и его отношение к древнеписьменному памятнику Codex Cumanicus по данным лексики (Краткий анализ и приложение) // Исследования по исторической диалектологии татарского языка: сб. ст. Казань, 1982. С. 68–153.

*Мәһдиев М.* Торналар төшкән җирдә // Казан утлары. 1981. № 11. Б. 3–79.

*Мусаев К.М.* Лексикология тюркских языков. М.: Наука, 1984. 228 с.

*Насыйри К.* Сайланма әсәрләр: 4 томда. 2 т. Казан: Татар. кит. нәшр., 2004. 400 б.

*Ногман М.* XVII–XVIII йөзләрдә русча-татарча кульязма сүзлекләр. Казан: Казан ун-ты нәшр., 1969. 112 б.

Персидско-русский словарь: в 2 т. 3-е изд., стер., с приложением Грамматического очерка персидского языка. М.: Рус. яз., 1985. Т. 1. 779 с.; Т. 2. 864 с.

*Радлов В.В.* Опыт словаря тюркских наречий: в 4 т. СПб.: Тип. Имп. Акад. наук, 1893. Т. 1. Ч. 1–2. XVIII+1050 с.; 1899. Т. 2. Ч. 1–2. 974 с.; 1905. Т. 3. Ч. 1–2. 651 с.; 1911. Т. 4. Ч. 1–2. 665 с.

*Сараи С.* Гөлестан: Лирика. Дастан. Казан: Татар. кит. нәшр., 1999. 296 б.

*Саттар-Мулилле Г.Ф.* Татар исемнәре ни сөйли? (Татар исемнәренең тулы аңлатмалы сүзлеге). Казан: Раннур, 1998. 487 б.

*Саттаров Г.Ф.* Татар антропонимикасы. Казан: Казан ун-ты нәшр., 1990. 276 б.

*Сафина Э.И.* Названия птиц в татарском языке и их лексикографирование: дис. ... канд. филол. наук / Институт языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова АН РТ. Казань, 2005. 279 с.

*Сафина Э.И.* Татарча-русча-латинча кош атамалары сүзлеге. Казан: ТӘһСИ, 2018. 184 б.

*Сетаров Д.С.* Тюркизмы в русских названиях птиц // Советская тюркология. 1970. № 2. С. 86–95.

Татар лексикологиясе: өч томда. Казан: ТӘһСИ, 2016. Т. II. 392 б.

Татар теленең аңлатмалы сүзлеге. I т.: А–В. Казань, ТӘһСИ, 2015. 712 б.

Татар теленең аңлатмалы сүзлеге. II т.: Г–Й. Казань, ТӘһСИ, 2016. 748 б.

Татар теленең аңлатмалы сүзлеге. III т.: К. Казань, ТӘһСИ, 2017. 744 б.

Татар теленең аңлатмалы сүзлеге. V т.: С–Т. Казан: ТӘһСИ, 2019. 908 б.

Татар теленең аңлатмалы сүзлеге. VI т.: У–Я. Казан: ТӘһСИ, 2019. 912 б.

Татар теленең зур диалектологик сүзлеге. Казан: Татар. кит. нәшр., 2009. 839 б.

Татарско-русский словарь: в 2-х т. Т. 1 (А–Л). Казань: Магариф, 2007. 726 б.

Татарско-русский словарь: в 2-х т. Т. 2 (А–Л). Казань: Магариф, 2007. 726 б.

*Тимергалин А.* Миллият сүзлеге: Аңлатмалы сүзлек. Казан: Мәгариф, 2007. 575 б.

*Тимергалин А*. Миллият сүзлеге // Казан утлары. 2007. № 9. Б. 146–150.

Төшлек: Төшләрне юрау китабы / тупланманы әзерләүче һәм төзүчесе Фәрит Яхин. Казан: Раннур, 1997. 352 б.

*Урманче Ф.И.* Татар мифологиясе. Энциклопедик сүзлек: 3 томда: 2 т. (Д–С). Казан: Мәгариф, 2009. 343 б.

*Фәттах Н.* Сайланма әсәрләр: 5 томда. 4 т. Казан. 2002. 463 б.

*Шипова Е.Н.* Словарь тюркизмов в русском языке. Алма-Ата: Наука, 1976. 444 с.

## Кыскартылмалар

ГТРАС – Гарәпчә-татарча-русча алынмалар сүзлеге.
ПРС – Персидско-русский словарь.
ТРС – Татарско-русский словарь.
ТТАС – Татар теленең аңлатмалы сүзлеге.
ТТЗДС – Татар теленең зур диалектологик сүзлеге.

***Сафина Эльвира Ирфат кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының лексикография бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре*

УДК 81'373.221

***Р.И. Куряева***

# УРТА ИДЕЛ БУЕНЫҢ ӘЙЛӘНӘ-ТИРӘ ТАБИГАТЬНЕ ТАСВИРЛАУЧЫ СҮЗЛӘРДӘН ЯСАЛГАН ТӨРКИ ЧЫГЫШЛЫ РУС ОЙКОНИМНАРЫ

Регион Среднего Поволжья характерен тем, что с древнейших времён на его территории проживали представители финно-угорских, тюркских и славянских народов. Их тесный контакт привёл к взаимовлиянию и взаимообогащению их культур и языков. В статье показан результат влияния тюркских языков на русский язык в сфере названий русских населённых пунктов (ойконимов) семи республик и областей Среднего Поволжья. Приводится этимология ойконимов, производных от основ, дающих качественную характеристику местности; от основ, дающих ориентировочную характеристику; от названий растений и животных. Этимологический анализ показал, что данные ойконимы образованы от русских слов тюркского происхождения, от тюркских слов и от марийских слов тюркского происхождения. Против ожиданий эта группа ойконимов оказалась малочисленной. Это означает, что основной мотив номинации населённых пунктов лежит в другой области.

**Ключевые слова:** тюркология, тюркские заимствования в русском языке, ономастика, ойконимия, этимология.

It is known that on the territory of the Middle Volga region people of the Finno-Ugric, Turkic and Slavonic languages have been living from ancient times. Their close contacts resulted in mutual influence and enrichment of their cultures and languages. The result of influence of the Turkic languages on the Russian language in the sphere of Russian settlements names of seven Republics and provinces of the Middle Volga region is shown in this article. Etymology of settlement names derived from the words describing the surroundings, giving orientation from the names of plants and animals is given in this article. The etymological analysis revealed that the analyzed settlement names are generated from Russian words of the Turkic origin from Turkic words and from a Mari word of the Turkic origin. Unexpectedly this group of settlement names turned out to be small in number. It means that the main motive of settlement names appearance is in some other sphere.

**Keywords:** study of the Turkic languages, Turkic borrowings in Russian, onomastics, names of settlements, etymology.

Россия территориясендә борынгы заманнардан төрле тел төркемнәренә караган халыклар яши. Көнчыгыш һәм Көнбатыш мәдәниятләре очрашкан җирдә урнашкан Урта Идел Буе территориясендә бик борынгыдан фин-угор, төрки һәм славян телләре вәкилләре гомер кичергән. Үзара тыгыз аралашып яшәүләре нәтиҗәсендә тел һәм мәдәни яктан алар бер-берсенең йогынтысын кичергәннәр һәм тагын да баеганнар.

Безнең фәнни тикшеренү эше Урта Идел Буе рус ойконимиясенең (торак пункт атамаларының) төрки катламын өйрәнүгә багышлана. Рус торак пунктлары дигәндә, без күбрәк рус халкы яшәгән урыннарны күздә тотабыз. Бу, атаманың килеп чыгышы нинди булуга карамастан, аның рус теленә караган факт булганлыгын аңлата.

Урта Идел Буе ойконимиясендәге төрки сүзләрне ачыклау материалга этимологик анализ ясауны күз алдында тота. Әлеге эш тюркология һәм рус тел белеме үзара керешкән урында тора. Аның кысаларында төрки чыгышлы рус сүзләреннән, төрки чыгышлы фин-угор сүзләреннән һәм төрки сүзләрдән барлыкка килгән рус ойконимнары тикшерелә.

Географик атамаларга этимологик анализ телнең теге яки бу чордагы халәтен ачыкларга мөмкинлек бирә һәм аерым төбәкнең демографик тарихын күзалларга ярдәм итә.

Тикшеренү эшенең объекты – Урта Идел Буенда урнашкан җиде республика һәм өлкәдәге – Марий Эл, Мордовия, Татарстан һәм Чувашия республикалары һәм Пенза, Самара, Ульяновск өлкәләрендәге рус торак пунктлары (ойконимнары). Бу территориядә 13838 торак пункт исәпләнә, шуларның 7450 сендә рус халкы өстенлек итә.

Ойконимнарга этимологик анализ аларны унөч лексик-семантик төркемгә бүләргә мөмкинлек бирә. Бу мәкаләдә урынга билгеле бер сыйфатлары буенча характеристика биргән нигезләрдән; урынга ориентирлы характеристика биргән нигезләрдән; үсемлек һәм хайван исемнәреннән барлыкка килгән ойконимнар карала.

**1. Урынга билгеле бер сыйфатлары буенча характеристика биргән нигезләрдән ясалган ойконимнар:**

а) төрки чыгышлы рус нигезе **кремляк**тан (‘камень-голыш’) Кремленка ойконимы барлыкка килгән.

**Кремленка** авылы, Марий Эл Республикасы, Новый Торъял районы. Атаманың нигезендә рус сүзе **кремлевый** ‘таза, нык (төзелеш урманы турында)’ ята. Мәсәлән, **кремлевая сосна** ‘урман читендә, коры туфракта үсә торган нарат’ [Фасмер, 1964, II, с. 371]. Рус телендә **кремляк** сүзе шома ташны (камень-голыш) аңлата [Барашков, 1974, с. 48]. В.И. Даль сүзлегендә **кремляк** сүзенең ‘корыч кеше’ (‘человек-кремень’) мәгънәсе дә теркәлгән [Даль, 1955, II, с. 189]. XV гасырда **кремль** сүзе шәһәр эчендәге кирмәнне дә белдергән. XIV гасырда аны **кремникъ** [Фасмер, 1964, II, с. 370], ә шома ташны **кремневик, кремняк** сүзләре белән билгеләгәннәр [Даль, 1955, II, с. 189]. ‘Ныгытма’ мәгънәсендә телгә алынган иң борынгы рус сүзе – **кеременъ** [Шипова, 1976, с. 179]. Безнең фаразыбызча, ул рус теленә төрки телдән кергән. Аларда **кермен** сүзе крепостьны белдерә. М. Фасмер аны кыпчак теленнән алынган дип күрсәтә [Фасмер, 1964, II, с. 371]. Татар телендә ул **кирмән** формасында кулланыла. Рус телендә сүзләрнең мәгънәләре үзгәрү чылбырын түбәндәгечә төзергә мөмкин дип уйлыйбыз: башта **керемень** сүзе кергән, шуңа күрә **кремневик** сүзенең беренчел мәгънәсе ‘кирмән төзү өчен кулланыла

торган таш' булган. Аннары **кремневик**тан **кремник** төзи башлаганнар. **Кремник** өчен **кремляк** ташы кирәк булган, аннан **кремль** төзегәннәр. Шуннан соң ныклы төзелеш материалы **кремлевый** аергычы белән билгеләнгән. Болгар сүзе **кирмән**, безнең фикеребезчә, борынгы төрки **kir**- 'керү' фигыленә [Древнетюркский словарь, 1969, с. 308] барып тоташа. Ул төрки чыгышлы юклык кушымчасы **мә-** һәм хәрәкәт нәтиҗәсен белдергән **-н** кушымчасы белән бергә **кирмән** сүзенә 'керергә мөмкинлек бирми' мәгънәсен биргән.

ә) татар нигезе **таш**тан Ташлиярка, Ташлыярово, Каменный Починок (татарча **Ташлы**) ойконимнары ясалган.

**Каменный Починок** (татарча **Ташлы**) авылы, Татарстан Республикасы, Мамадыш районы. Ойконим татар теленнән ярымкалька булып тора, биредә **ташлы** сыйфаты тәрҗемә ителгән, ул татар сүзе **таш**тан ясалган. Төрки **таш** (чаг.: борынгы төрки **taš** [Древнетюркский словарь, 1969, с. 539]) топонимиядә киң кулланыла. Сүз формасы барлык төрки телләрдә дә бердәй.

**2. Урынга ориентирлы характеристика биргән нигезләрдән барлыкка килгән ойконимнар:**

а) көньякка юнәлешне күрсәтүче, төрки чыгышлы рус нигезе **крым**нан **Крым** ойконимы барлыкка килгән;

**Крым** авылы, Пенза өлкәсе, Земетчино районы. Ойконим икенчел, ягъни ул Кырым ярымутравының атамасына барып тоташа. Пенза өлкәсендә әлеге атаманың барлыкка килүен танылган тел белгече В.А. Никонов болай аңлата: «Вся лежащая к югу от "синбирской черты" сторона называлась "ногайской", "крымской" или просто "степью", отголоски этого звучат во многих названиях деревень, дорог и рек: р. Ногайка, д. Крымка...» [Никонов, 1960, с. 185]. **Крым** сүзенең нигезендә борынгы төрки **qorum** 'ташлы урыннар, кыя ватыклары, валуннар' сүзе ята [Древнетюркский словарь, 1969, с. 460] (чаг.: тувача **хорум** 'ташлы урын, таш өеме, курган', хакасча **хорым** 'чәчелмәләр, кыялар', якутча **курум** 'чәчелмәләр, тау битләрендәге, елга үзәннәрендәге ишелмәләр' [Мурзаев, 1984, с. 320]). **Корум / курум** сүзе географик әдәбиятта платоның тигез өслекле төбәсендәге һәм сөзәклекләрендәге ташлы ишелмәләрне; тау битләрендәге һәм елга юлларындагы таш өемнәрен аңлаткан термин буларак кулланыла.

ә) **Русский Янтык** ойконимы татар теленең көнбатыш диалектындагы **янтык** 'як' сүзеннән килеп чыккан.

**Русский Янтык** (татарча **Рус Янтыгы**) авылы, Татарстан Республикасы, Лаеш районы. Ойконимның нигезендә **янтык** 'як' сүзе ята, ягъни атама '**рус ягы**' мәгънәсенә ия. Татар әдәби телендә **янтык** сүзе 'ян, як' мәгънәсендә кулланыла һәм борынгы төрки телдәге **jan** 'як, кырый' [Древнетюркский словарь, 1969, с. 231] һәм **jaŋaq** 'як' сүзләренә барып тоташа [Древнетюркский словарь, 1969, с. 233].

Бу бүлеккә 2 ойконим карый, Русский Янтык атамасының этимологиясе беренче тапкыр тикшерелә.

**3. Фитоойконимнар – үсемлек атамаларыннан килеп чыккан ойконимнар:**

а) төрки тамырлы рус нигезләре **калганник** ‘кылган кыры’, **камыш** ‘камыш’, **тальник**тан ‘таллык’ Калганник, Камышево, Камыши-Хвощи, Камышинка, Камышовка, Тальники ойконимнары барлыкка килгән.

**Калганник посёлогы,** Самара өлкәсе, Алексеевка районы. Атаманың нигезендә рус сүзе **калган** ‘күпьеллык куе үләнле үсемлек’ ята [Энциклопедический словарь, 1963, I, с. 445]. Рус телендә ул XVIII гасырда барлыкка килгән, шулай ук **галган** һәм **калкан** формаларында да очрый. Без аны төрки теллcounterдән кергән дип уйлыйбыз (чаг.: татарча **кылган** ‘ковыль’, **кылганлык** ‘ковыльное поле, ковыльник’ [Татарско-русский словарь, 1988, с. 180], кыргызча **калкан** ‘кылган’ [Шипова, 1976, с. 154]). Шунысын да билгеләп үтәргә кирәк: кылган – күпьеллык үләнле үсемлек, һәм аның 300 гә якын төре бар [Большой энциклопедический словарь, 2002, с. 543], ә **ковыль** сүзе рус телендә күптәннән очрый [Ожегов, 1988, с. 227]. Димәк, татар теле йогынтысында кылганның бер төре рус сүзе **калган** белән, ә бу үсемлекләрдән торган кыр татар телендәге кылганлыкка охшатып, **калганник** дип аталган. Сүз татар теленең көнбатыш диалектындагы **калгы-** ‘селкетү’ һәм **калгын**- селкенү’ фигыльләренә барып тоташа.

**Камыши-Хвощи** авылы, Пенза өлкәсе, Пенза районы. Ойконимның нигезендә рус сүзе **камыш** ята. Ул рус теленә төрки телләрдән XVIII гасырда гына үтеп кергән [Шанский, 1971, с. 185] (чаг.: татар **камыш, камышлык** ‘заросли камыша’, борынгы төрки **qamïš** ‘тростник, камыш; заросли тростника, камыша’, **qamïšlan-** ‘зарастать тростником, камышом’, **qamïšlïɣ** ‘поросший, заросший камышом’ [Древнетюркский словарь, 1969, с. 415]). И.И. Огиенко **камыш**ны төрек теленнән алынган сүз дип саный [Шипова, 1976, с. 158]. А. Жаримбетов төрки **камыш**ны уйгурларның **камша**сыннан ‘селкенү, калтырану, дерелдәү’ китереп чыгара [Жаримбетов, 1976, с. 12].

**Тальники** посёлогы, Самара өлкәсе, Кинель-Черкассы районы. Атаманың нигезендә рус сүзе **тальник** ‘таллык, тал әрәмәлекләре’ ята. Рус телендә XVIII гасырда гына барлыкка килгән **тальник** сүзен М. Шанский рус сүзьясалышы үрнәге дип саный [Шанский, 1971, с. 436]. Әмма борынгы рус телендә сүз **талия** формасына ия булган [Шипова, 1976, с. 303], шуңа күрә **тальник** сүзе татар телендәге **таллык** сүзенең русчага яраклашуы нәтиҗәсендә барлыкка килгән дип фараз кылабыз, әлбәттә, **талия** сүзендәге йомшак [л] авазын исәпкә алып. **Тальник** сүзе борынгы төрки **tal** ‘тал, таллык, тал чыбыгы’ сүзенә барып тоташа [Древнетюркский словарь, 1969, с. 528].

ә) төрки чыгышлы мари нигезе **олма**дан ‘алма’ Олма-Шойская, Малая Олма, Пукшалма ойконимнары барлыкка килгән.

**Олма-Шойская** (марича **Руш Олма**), **Малая Олма** авыллары, Марий Эл Республикасы, Бәрәңге районы; **Пукшалма** (иске атама-

сы **Пукша-Олма**) авылы, Марий Эл Республикасы, Куженер районы. Ойконимнарның нигезендә борынгы төрки телдәге **alma** ‘алма’ сүзеннән [Древнетюркский словарь, 1969, с. 36] алынган мари сүзе **олма** ‘алма, алмалы’ [Марийско-русский словарь, 1956, с. 378] ята.

б) чуваш нигезе **улма**дан ‘алма’ Яблоновка (чувашча **Улмалла Ял**) ойконимы ясалган.

**Яблоновка** (чувашча **Улмалла Ял**) авылы, Чувашия Республикасы. Русча исеме – чувашча атаманың ярымкалькасы. Чувашча **улмалла улма** ‘алма’ сүзеннән барлыкка килгән ‘алмалы’ мәгънәсендәге сыйфат булып тора [Чувашско-русский словарь, 1961, с. 455]. **Улма** сүзе чувашларга татарлардан кергән (татарча **алма**, чаг.: борынгы төрки **alma** ‘алма’ [Древнетюркский словарь, 1969, с. 36]).

в) татар нигезләре **арпа**, **чия**, **борчак**, **солы**, **тал**дан Арпаяз-Янга-Сала, Вишнёвая Поляна (татарча **Чияле**), Гороховое Поле (татарча **Борчаклы Яз**), Зай-Солояз (татарча **Зәй-Солуяз**), Таллы-Буляк (татарча **Таллы-Бүләк**) ясалган.

**Арпаяз-Янга-Сала** (татарча **Арпаяз Яңа Сала**) авылы, Татарстан Республикасы, Арча районы. Биредә татарча атама беренчел. Ул күчерелгән, чөнки аны Татарстан Республикасы Кукмара районы Арпаяз авылыннан күчеп килгән кешеләр биргән. ‘Яңа Арпаяз авылы’ мәгънәсенә ия. Ойконимның беренче өлеше катлаулы, ул ике компоненттан тора: беренчесе – татар сүзе **арпа**, икенчесе – **яз** ‘кыр, тигезлек, дала’, ул хәзерге төрки телләрдә кулланылмый диярлек. Татар телендә ул бары тик **язы-тау** ‘плато, яссы тау’ сүзтезмәсе составына керә [Мурзаев, 1984, с. 646]. XIX гасыр ахырында түбәндәге сүзләр теркәлгән: госманлыча **йаз** ‘ачык тигезлек’ [Радлов, 1882, III-1, с. 226], алтайча **азы** ‘кыр, тигезлек, дала; шома, киң’, хакасча **чазы** ‘кыр, дала’ [Радлов, 1882, III-2, с. 1911]. Алар барысы да борынгы төрки **jazï** ‘дала, тигезлек’ сүзеннән килеп чыккан [Древнетюркский словарь, 1969, с. 251]. Шулай итеп, **Арпаяз** ул – арпа кыры.

**Вишнёвая Поляна** (татарча **Чияле**) авылы, Татарстан Республикасы, Нурлат районы. Русча атамасы татар теленнән калька булып тора. Атама татар телендәге **чия** сүзеннән алынган, аңа төрки **-ле/-лы** барлык кушымчасы ялганган.

**Гороховое Поле** (татарча **Борчаклы Яз**) авылы, Татарстан Республикасы, Теләче районы. Русча атама татар теленнән калька булып тора, чөнки хәзерге төрки телләрдә **яз** ‘кыр, тигезлек, дала’ сүзе кулланылмый. Рус теленнән хәзер тәрҗемә иткән очракта, **поле** сүзе татарчага **кыр** дип тәрҗемә ителер иде. Бу атама **-ле/-лы** барлык кушымчасы (борчаклы сыйфатыныкы) ярдәмендә татар телендәге **борчак** сүзеннән ясалган. Соңгысы борынгы төрки телендәге **burčaq** ‘борчак һәм кузаклылар гаиләсеннән башка үсемлекләр’ сүзенә барып тоташа. [Древнетюркский словарь, 1969, с. 125].

**Зай-Солояз** (татарча **Зәй-Солуяз**) посёлогы, Татарстан Республикасы, Бөгелмә районы. Ойконимның икенче өлеше катлаулы, ул ике компоненттан тора: беренчесе **соло** / **солу** татар телендәге

**солы** сүзенә барып тоташа [Татарско-русский словарь, 1988, с. 264], икенчесе – **яз** 'кыр, тигезлек, дала' югарыда **Арпаяз-Янга-Сала** атамасын анализлаганда каралды. Шул рәвешле, **Солояз** – арыш кыры 'овсяное поле' ул. **Яз** төрки тамырының борынгылыгы торак пунктның татарча атамасы беренчел булуны күрсәтә.

**Таллы-Буляк** (татарча **Таллы-Бүләк**) авылы, Татарстан Республикасы, Бөгелмә районы. Ойконимның нигезендә татар сүзе **тал** ята, ул күп кенә төрки телләрдә бар һәм борынгы төрки телдә шул ук формада һәм шул ук мәгънәдә кулланылган [Древнетюркский словарь, 1969, с. 528]. Төрки чыгышлы барлык кушымчасы **-лы** ойконимга 'таллы' мәгънәсен бирә.

Бу бүлектә 15 ойконим каралды. Калганник, Яблоновка, Олма-Шойская, Малая Олма, Пукшалма ойконимнарының этимологиясе беренче тапкыр тикшерелде. Рус нигезе **тальник**ның килеп чыгышына ачыклык кертелде.

**4. Зооойконимнар – хайван исемнәреннән ясалган атамалар:**

а) Төрки чыгышлы рус нигезләре **казарка** (үрдәк кошлар семьялыгыннан), **коза, сазан**нан Казарка, Козий, Козий Починок, Козлятское, Сазанье ойконимнары ясалган.

**Казарка** авылы**,** Пенза өлкәсе, Никольск районы. Ойконимның нигезенә ак маңгайлы казның русча атамасы **казарка** яткан. Шулай ук рус телендә **казара** сүзе дә бар, ул киек казлар төрен аңлата. Ул төрки чыгышлы һәм борынгы төрки телдәге **qaz** 'каз' сүзенә [Древнетюркский словарь, 1969, с. 438] барып тоташа дип фаразлана.

**Козий (**Ульяновск өлкәсе, Новоспасское районы), **Козий Починок** (татарча **Кечкенә Починка**; Татарстан Республикасы, Питрәч районы), **Козлятское (**Пенза өлкәсе, Нижний Лобов районы) посёлоклары. Атамаларның нигезендә хайваннарның русча аталышлары **козел**, **коза** һәм аларның кәҗә бәтиләренең күплек сандагы исеме **козлята** ята. Н.М. Баскаков фикеренчә, **коза** сүзе төрки телләрдән алынган (чаг.: команча, телеутча, алтайча, уйгурча, чыгтайча **козы** / **коза** 'бәрән', [Радлов, 1882, II-1, с. 630], кырым-татарча, кыргызча, госманлыча, караимча **козу** / **кузу** 'бер яшьлек бәрән, бәрән' [Радлов, 1882, II-1, с. 631], яңа уйгурча **коза** 'бәрән', борынгы төркичә, казакъча **козы** 'бәрән', кырым-татарча, төрекчә **кузу** / **козы** 'бәрән', казанча, тубылча **кәзә** 'ягнёнок'). Аның турында Н.М. Баскаков болай дип яза: «Слово могло быть заимствовано для названия другого животного, близкого по характеру к овцам, – козы, козленка, и таким образом утвердиться в значении 'коза', от которого позже образовалось и название для самца этого животного – **козел** по аналогии с названием другого домашнего животного **осел**» [Баскаков, 1979, с. 131].

**Сазанье,** Пенза өлкәсе, Сердобск шәһәре. Ойконимның нигезендә **сазан** 'кыргый карп' балыгы исеме [Ушаков, 1938, IV, с. 24] ята. Рус теленә бу сүз XVI гасырда төрки телләрдән кергән [Шанский, 1971, с. 399] (чаг.: төрекчә, казакъча, калмыкча, кыргызча, үзбәкчә **сазан**, чувашча **сасан,** чыгтайча **сазар** [Шипова, 1976, с. 270]). Ул

төрки телләрдәге **саз** ‘сазлык, ләм’ һәм **аң** ‘ауланган һәртөрле хайван’ сүзләренә барып тоташа [Севортян, 1974, с. 152].

ә) борынгы төрки нигез **турна** ‘журавль’ **Турнояс** ойконимы составына кергән.

Турнояс авылы, Татарстан Республикасы, Нурлат районы. Әлеге атама ике төрки сүзнең – борынгы төрки телдәге **turna** ‘соры торна’ [Древнетюркский словарь, 1969, с. 588] (чаг.: татарча **торна** ‘журавль’ [Татарско-русский словарь, 1988, с. 306]) һәм иске татар телендәге **яз** ‘кыр’ (чаг.: борынгы төрки телендәге **jazï** дала, тигезлек’ [Древнетюркский словарь, 1969, с. 251]) сүзләренең кушылуы нәтиҗәсендә ясалган. Соңгысы **Арпаяз-Янга-Сала** атамасы анализланганда каралды.

Шулай итеп, **Турнояс** ‘торналар кыры’ мәгънәсенә ия. **Турна** сүзе **турня** формасында һәм шул ук мәгънәдә мари теленә дә килеп кергән [Марийско-русский словарь, 1956, с. 601].

Бу бүлектә 6 ойконим каралды.

Югарыда санап үтелгән рус ойконимнарына этимологик анализ аларның төрки чыгышлы рус сүзләреннән (**кремляк, Крым, калганник, камыш, тальник, казарка, коза, сазан**), татар сүзләреннән (**таш**, **арпа**, **чия**, **борчак**, **солы**, **тал**), татар диалекталь сүзе **янтык**тан ‘як’, иске татар телендәге **яз** ‘кыр’, борынгы төрки телдәге **turna** ‘соры торна’, чуваш телендәге **улма** ‘алма’ һәм мари телендәге төрки чыгышлы **олма** ‘алма’ сүзләреннән барлыкка килгәнлеген күрсәтте. Анализланган ойконимнар күләме ягыннан зур булмаган дүрт лексик-семантик төркемгә керәләр. Аларның һәрберсендә диярлек торак пунктка исем бирү мотивы чагылыш таба. Тикшеренүдән күренгәнчә, анализланган 1013 төрки сүз-ойконимнан нибары 27 се генә урынга сыйфат, ориентирлы характеристика биргән нигезләрдән, үсемлек һәм хайван атамаларыннан барлыкка килгән.

### Әдәбият

*Барашков В.Ф.* Топонимия Ульяновской области. Ульяновск, 1974. 80 с.

*Баскаков Н.А.* Русские фамилии тюркского происхождения. М.: Наука, 1979. 279 с.

Большой энциклопедический словарь. М.: Большая Российская энциклопедия; СПб.: Норинт, 2002. 1456 с.

*Даль В.И.* Толковый словарь: в 4-х т. М.: Гос. изд-во иностр. и нац. словарей, 1955. 2716 с.

Древнетюркский словарь. Л.: Наука, 1969. 676 с.

*Жаримбетов А.* Тюркизмы в русских названиях растений: автореф. дис. ... канд. филол. наук. М., 1976. 23 с.

Марийско-русский словарь. М.: Гос. изд-во иностр. и нац. словарей, 1956. 863 с.

*Мурзаев Э.М.* Словарь народных географических терминов. М.: Мысль, 1984. 656 с.

*Никонов В.А.* История освоения Среднего Поволжья по материалам топонимии // Вопросы географии. Вып. 50. Историческая георафия. М.: Географгиз, 1960. С. 172–194.

*Ожегов С.И.* Словарь русского языка. М.: Русский язык, 1988. 750 с.

*Радлов В.В*. Опыт словаря тюркских наречий: в 4-х т. СПб., 1882.

*Севортян Э.В*. Этимологический словарь тюркских языков. (Общетюркские и межтюркские основы на гласные). М.: Наука, 1974. 767 с.

Татарско-русский словарь. Казань: Татар. кн. изд-во, 1988. 464 с.

*Ушаков Д.Н.* Толковый словарь русского языка: в 4-х т. М.: Гос. изд-во иностр. и нац. словарей, 1938.

*Фасмер М.* Этимологический словарь русского языка: в 4-х т. М.: Прогресс, 1964.

Чувашско-русский словарь. М.: Гос. изд-во иностр. и нац. словарей, 1961. 630 с.

*Шанский Н.М., Иванов В.В., Шанская Т.В.* Краткий этимологический словарь русского языка. М.: Просвещение, 1971. 542 с.

*Шипова Е.Н.* Словарь тюркизмов в русском языке. Алма-Ата: Наука, 1976. 444 с.

Энциклопедический словарь: в 2-х т. Т. I. М.: Советская энциклопедия, 1963. 656 с., 24 л. ил.: ил., карт.

***Куряева Рауза Исмаил кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, доцент (Казан)*

УДК 81'373

***Р.Ф. Фәттахова***

# ТАТАР ТЕЛЕНДӘ КЕШЕНЕҢ ЯХШЫ МАТДИ ХӘЛЕН БЕЛДЕРӘ ТОРГАН ЛЕКСИК ҺӘМ ФРАЗЕОЛОГИК БЕРӘМЛЕКЛӘР

В данной статье проводится анализ слов и фразеологических единиц татарского языка, отражающих понятие хорошего материального положения человека, а также языковых средств, способствующих выражению отношения к данному явлению. Особое внимание уделяется фразеологическим выражениям, которые не только передают значение материального богатства, но и обогащаются эмоционально-экспрессивными и стилистическими оттенками. Исследование позволяет понять, как язык отражает социальные и культурные ценности, связанные с понятием материального благополучия.

**Ключевые слова:** лексические и фразеологические единицы, номинативная функция, эмоционально-экспрессивный и стилистический оттенок, материальное богатство, культурная ценность.

This article analyzes the words and phraseological units of the Tatar language, reflecting the concept of a good financial situation of a person and is an analysis of linguistic means that contribute to the expression of attitudes towards this phenomenon. Special attention is paid to phraseological expressions that not only convey the meaning of material wealth but are also enriched with emotionally expressive and stylistic shades. The study allows us to understand how language reflects the social and cultural values associated with the concept of material well-being.

**Keywords:** lexical and phraseological units, nominative function, emotional-expressive and stylistic connotation, material wealth, cultural value.

Тел – милли мәдәниятнең трансляторы. Тел чаралары ярдәмендә кеше үз фикерен җиткерә, теге яки бу күренешкә карата үзенең мөнәсәбәтен белдерә ала. Бу вакытта ул затларны, предметларны, күренешләрне, вакыйгаларны характерлаучы сүзләрдән һәм фразеологик әйтелмәләрдән файдалана. Сүзләр дә, фразеологизмнар да лексик берәмлекләр буларак, беренче чиратта, номинатив функция башкаралар. Шулай ук бу ике берәмлеккә шушы зат, предмет, күренеш һәм вакыйгаларга бәя бирү үзенчәлеге дә хас. Дөрес, әлеге үзенчәлек күбрәк фразеологик әйтелмәләрдә чагылыш таба һәм ул төрле эмоциональ-экспрессив, стилистик төсмерләр белән баетыла. Мәсәлән, *бай* һәм *май кайнаган көнне туган* дигән берәмлекләр икесе дә кешенең яхшы матди хәлен белдерәләр, ләкин икенчесендә бу мәгънә интенсиврак яңгырый һәм уңай эмоциональ төсмер белән сугарылган. Фразеологик әйтелмәләрнең күбесе үз эчендә берничә мәгънә төсмерен тупларга сәләтле. Мәсәлән, кемнедер *урыны түрдә* дип характерлаганда, кадер-хөрмәттә, байлыкта яши торган дәрәҗәле кеше турында сүз баруы аңлашыла.

Бик бай булуны белдерүче лексик һәм фразеологик берәмлекләрне аерып чыгару, мәгънәсенә төшенү авырлык тудырмый. Урта хәлле мәгънәсен белдерүче лексик һәм фразеологик берәмлекләрдән аермалы буларак, бу берәмлекләр ташып торган, чиктән тыш байлык, муллыкны белдерәләр. Шуларга өстәп, шушы төркемгә кертелгән *хан, патша, шаһ, әмир* кебек югары дәрәҗәгә һәм титулга лаек булган кешеләргә дә контексттан һәм мантыйк күзлегеннән чыгып фикер йөрткәндә, бик бай булу сыйфаты хас.

Мәкаләнең максаты – татар телендә кешенең яхшы матди хәлен белдергән сүзләрне һәм фразеологик әйтелмәләрне барлау һәм алар аркылы телнең байлык төшенчәсенә бәйле социаль һәм мәдәни кыйммәтләрнең чагылышын тасвирлау.

Татар телендә кешенең яхшы матди хәлен белдерә торган төп лексик берәмлек – *бай*. «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә «аның матди байлык» категориясе белән бәйле өч мәгънәсе теркәлгән. Калган очракларда рухи байлыкны яки яхшы, затлы булуны белдерә:

1. Зур мал-мөлкәтле, материаль кыйммәткә ия булган (*сыйфат).*

2. Мул, күп *(сыйфат).* [...]

5. Зур милеккә хуҗа кеше, эксплуататор сыйныфлар вәкиле (*исем)»* [ТТАС, I т., 110 б.].

Алга таба эш барышында безнең тарафтан «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ннән һәм «Татар теленең диалектологик сүзлеге»ннән теге яки бу дәрәҗәдә «байлык» категориясе белән бәйле булган барлыгы 50 номинатив берәмлек тупланды: *акционер* – акцияләр хуҗасы, капиталист [ТТАС, I т., 38 б.]; акчалы – акчасы бар, акчага бай, дәүләтле [ТТАС, I т., 39 б.]; *алпавыт* – феодаллык мөнәсәбәтләре булган илләрдә эре җирбиләүче, дворян [ТТАС,I т., 50 б.]; *аристократ* – аристократия вәкиле, аксөяк [ТТАС, I т., 66 б.]; *байбикә* – бай хатыны [ТТАС, I т., 111 б.]; *байбичә* – 1. байбикә, бай хатыны, 2. казакъ яки кыргыз бае хатыны [ТТАС, I т., 111 б.]; *байбәтчә* – байның буйга җиткән улы; бай, тәкәббер һәм гадәттә азгын яшь кеше [ТТАС, I т., 111 б.]; *байгура* – бай һәм саран кеше [ТТАС, I т., 111 б.]; *би* – бай, морза, түрә, хуҗа [ТТАС, I т.,159 б.]; *бизнесмен* – һәр эштән зур табыш каерырга омтылучы эшкуар [ТТАС, I т., 160 б.]; *бикә* – бай, би[к] хатыны [ТТАС, I т., 162 б.]; *бәк* – урта Азиянең феодаль ханлыкларында: берәр районда яки шәһәрдә идарә итүче [ТТАС, I т., 206 б.]; *галиҗәнап* – түрәләрне, зур дәрәҗәле кешеләрне атау һәм шуларга мөрәҗәгать итү сүзе [ТТАС, I т., 257 б.]; *иганәче* – иганә бирүче, материаль ярдәм күрсәтүче кеше [ТТАС, I т., 357 б.]; *иркен* – бертөрле дә материаль кыенлыклар кичерми торган, бай, мул тормышлы [ТТАС, I т., 409 б.]; *капиталист* – капиталистик җәмгыятьнең хакимлек итүче сыйныф вәкиле: капитал хуҗасы, ялланган эшчеләрне эксплуатацияләүче [ТТАС, II т., 44 б.]; *кредитор* – товар яки акчаны кредитка биреп торучы (кеше, оешма) [ТТАС, II т., 175 б.]; *кулак* – ярлы-ялчы көче белән файдаланучы бай крестьян, байгура [ТТАС, II т., 185 б.]; *магнат* – 1. кайбер Европа илләрен-

дә эре җирбиләүче, алпавыт, 2. эре капиталист [ТТАС, II т., 354 б.]; *меценат* – буржуаз-дворян җәмгыятьтә: фән һәм сәнгать белән кызыксынып, аның файдасына материаль һәм мораль ярдәм күрсәтүче бай кеше [ТТАС, II т., 387 б.]; *миллиардер* – акча белән исәпләгәндә миллард һәм аннан да күбрәк сумлык байлыкка, милеккә ия булган кеше [ТТАС, II т., 391 б.]; *миллионер* – акча белән исәпләгәндә миллион һәм аннан да күбрәк сумлык байлыкка, милеккә ия булган кеше [ТТАС, II т., 392 б.]; *мирза* – кайбер Көнчыгыш халыкларында өстен катлау вәкиленең титулы; шул титулга ия булган кеше [ТТАС, II т., 396 б.]; *монополист* – эре капиталист, монополистик капитал вәкиле [ТТАС, II т., 403 б.]; *олигарх* – 1. Борынгы заман һәм Урта гасырларда: олигархик хөкүмәт члены, 2. эре монополистик капитал вәкиле [ТТАС,II т., 466 б.]; *оҗмах* – рәхәтлек, иркен, мул тормыш [ТТАС, II т., 493 б.]; *патша* – илдә хөкүмәт һәм гаскәр башлыгы булып саналган, чикләнмәгән хакимлеккә ия булган кеше, монарх, хуҗа, башлык. [ТТАС, II т., 506 б.]; *патшабикә* – патша хатыны, хатын-кыз патша [ТТАС, II т., 506 б.]; патшаларча – патшаларга охшашлы, патшаларга хас булганча [ТТАС, II т., 506 б.]; *плутократ* – хаким сыйныфның иң бай катлавыннан чыккан һәм үз байлыгы аркасында власть һәм йогынты көченә ия булган кеше [ТТАС, II т., 523 б.]; *подвалчы – иск.* читтән килгән сәүдәгәрләрнең малларын үз өенең идән астында саклау белән шөгыльләнгән кеше, бай [ТТАС, II т., 524 б.]; *солтан* – кайбер мөселман дәүләтләрендә: патша, монарх [ТТАС, II т., 659 б.]; *түрә* – эш башында торган кеше, башлык, хуҗа, хаким, бай [ТТАС, III т., 289 б.]; *түрә-кара* – һәртөрле власть башлыклары, хакимнәр, түрәләр [ТТАС, III т., 289 б.]; *тук* – иркен, таза, бай тормышлы, бай [ТТАС, III т., 155 б.]; хан – Урта гасырларда күп кенә Көнчыгыш илләрендә феодаль идарәчегә бирелә торган дәрәҗә [титул]; шундый дәрәҗәдәге кеше [ТТАС, III т., 362 б.]; *ханбикә* – 1. хатын-кыз хан, 2. хан хатыны, ханча [ТТАС, III т., 362 б.]; ханзадә – хан улы [ТТАС, III т., 362 б.]; *хуҗа* – хосусый милекче, хосусый милек иясе [ТТАС, III т., 375 б.]; *хәзинәдар – иск.* хәзинә тотучы, хәзинә хуҗасы [ТТАС, III т., 380 б.]; *шаһ* – кайбер Көнчыгыш илләрендә монарх титулы һәм шул титулга ия булган кеше [ТТАС, III т., 501 б.]; *шаһзадә* – шаһ улы [ТТАС, III т., 501 б.]; *шаһиншаһ* – шаһлар шаһы, бөек шаһ; патшалар патшасы, барысына да баш патша [ТТАС, III т., 501 б.]; *шаһинә* – шаһ хатыны яки хатын-кыз шаһ [ТТАС, III т., 501 б.]; *әмир* – берәр өлкә яки дәүләт башлыгы [ТТАС, III т., 682 б.]; *әукатле* – бай, ризыклы, маллы [ТТАС, III т., 691 б.]; *дуйын* – 1. [нокр.] бай, 2.[Оренбург өл. мишәрләре с.] күплек, муллык [ТТДС,128 б.]; *дәверле* – [оренбург с.] бай [ТТДС, 131 б.]; *калын* – [бәрәңге сөйл., минз.] бай [ТТДС, 190 б.]; *кеттә* – [чист.] кәттә, дәрәҗәле, күренекле, бай кыяфәтле [атаулы] [ТТДС, 240 б.].

Әлеге лексик берәмлекләрнең күпчелеген хакимият башлыкларын, хакимнәрне, түрәләрне, титуллы кешеләрне белдергән сүзләр тәшкил итә: *алпавыт, аристократ, капиталист, патша, хан, шаһ,*

*би, солтан* һ.б. Димәк, түрә кеше – акчалы, бай кеше. Эштән зур табыш алучы, милеккә ия булган кешеләр: *бизнесмен, эшкуар, милекче, хәзинәдар* һ.б. Бу сүзләр, нигездә, атау функциясен үтиләр һәм стилистик яктан нейтраль.

Тел белемендә фразеологик мәгънә төшенчәсе төрлечә аңлатыла. Соңгы елларда чыккан хезмәтләрдә аны денотатив, эмоциональ-экспрессив һәм грамматик мәгънәләр комплексы итеп карауга өстенлек бирелә [Хәзерге татар лексикологиясе, 2015, б. 235]. Фразеологизмнар, аерым сүзләр кебек үк, номинатив функция башкаралар. Аларның бу функциясе безне чолгап алган дөнья күренешләрен исемләргә мөмкинлек бирә [Хәзерге татар лексикологиясе, 2015, б. 235]. Ләкин фразеологик әйтелмәләр теге яки бу предметны, күренешне атап кына калмыйлар, бәлки шул предметка, күренешкә карата сөйләүченең мөнәсәбәтен белдерәләр. Димәк, фразеологик мәгънә көчле эмоциональ-экспрессив, стилистик төсмерләр белән баетылган [Хәзерге татар лексикологиясе, 2015, б. 236].

Бертөрле семантикага берләшкән фразеологик әйтелмәләр, кагыйдә буларак, ике күзлектән чыгып тикшерелә: фразеологик әйтелмәләргә хас гомуми мәгънә һәм шул мәгънәне китереп чыгаруда катнашкан компонентларның роле. Әлеге төр тикшеренүләр фразеологик әйтелмәләрнең эволюциясен, семантик-структур үзенчәлекләрен, функциональ ягын ачып бирергә мөмкинлек бирә.

Мәкалә кысаларында татар телендәге кешенең яхшы матди хәлен белдерә торган фразеологик әйтелмәләр (барлыгы 320 берәмлек), лексик-семантик үзенчәлекләрен тикшерү юлында, түбәндәге семантик төркемчәләргә бүленде һәм аларны оештыручы доминант лексик берәмлекләр аерып чыгарылды:

1. «Акча, материаль байлык» мәгънәле фразеологик әйтелмәләр: *оҗмах байлыгы, эре акчалар, юл аягы, юл хәҗере, җанлы мал, җансыз мал, аршынлы мал, гаип хәзинә, дакъянус хәзинәсе, дусай сумасы, дәүләт кошы, дөнья иманы, кесә башыннан, Питербур ташы, саф акча, сукыр акча, хәләл акча; шау алтын, әндри казнасы.*

2. «Зур милеккә, акчага ия булу, мул, иркен тормышта яшәү» мәгънәсендәге фразеологик әйтелмәләр: *акчасын тавык та чүпләп бетермәс; алашасы колынлау; алтынга чуму; [аның] алтыны янчыкта түгел, капчыкта; [аның] ашы – май, эче бөйрәк, сөт өсте, каймак* һ.б.

3. «Тормыш алга бару, матди байлыкка ирешү» мәгънәсендәге фразеологик әйтелмәләр: *[аның] ишегеннән дә керә, тишегеннән дә керә; [аның] көне алга бара; [аның] сандугачы сайрый; [аның] эше ком тибә; дөньяны әйләндерә* һ.б.

4. «Байлыкка була артык үсенү, кылану» мәгънәсендәге фразеологик әйтелмәләр: *байлыгы кикертә [сикертә]; дөньяның артына тибү; дөньясын дер селкетеп яшәү; дөньясын тетү; дөньясын төкереп тә бирми; кыланмаганны калдырмау; күзен май баскан; мае сикертә; маена чыдый [чыдаша, түзә] алмау, маена*

*сыймау [сыешмау]; ни ашыйм да ни эчим; симезлегенә чыдаша алмый* һ.б.

5. «Югары социаль статуслы булу» мәгънәсендәге фразеологик әйтелмәләр: *асыл сөяк; ак сөяк; иген бае; диме белән; тәңкәле кыз* һ.б.

6. «Урта хәлле булу» мәгънәсендәге фразеологик әйтелмәләр: *авызы икмәккә тук; ашлы-сулы; аякны озын сузу; морҗадан төтен чыгару; мулдан кылану [ычкындыру, кубару]; адәм булу; адәм рәтле; атлы-тунлы кеше; вак милекче; дөньясы түгәрәк, тормышы бөтен; иркен куллы; иркен тоту; итәге бөтен, җиңе киң; казан астыннан уты өзелми; кеше арасына керү.*

7. «Сәүдә эше, сәүдәгәрлек итү» мәгънәсендәге фразеологик әйтелмәләр: *вак кул бай; вак товарчы; кул сугу [сугышу]; кәсеп итү; акча белән башма баш; акча сезнеке, мал безнеке; акча тору; ат бәясе; базар тоту; бер акча; буштан буш; бәдри бәнеж сатып баючы; бәясе кыйммәткә төшү; бәясеннән тормау; бәясе төшү; итәк асты сәүдәсе; күтәргә сату; тәкә башы күрсәтеп эт ите сату; чабу астын тунау; әһле базар.*

8. «Акча эшләү, мал җыю» мәгънәсендәге фразеологик әйтелмәләр: *акча керү; банк сугу; кесә кайгырту; кесә калынаю; кесәгә салу; корсак үстерү; кулга керү; йорт җыю; акча балалату; акча кою [коеп алу]; акча сугу; акча эшләү; акча ясау; ана сөте кебек хәләл; диңгез янында кое казу; дөнья арттыру; дөнья куу; дөнья кыйрату; дөнья рәтен белү; дөнья җыю юлда [җирдә] ятмый* һ.б.

9. «Җиңел юл белән баю» мәгънәсендәге фразеологик әйтелмәләр: *акчадан уйнау; ил корткыч; йөрәк майларын имү; кесә талаучы; кесәне саву; кул җылыту; майлы таба ярату; тереләй тунау [сую]; абуз өстендә арыш суга; авызы тәм сизә [тоя]; аз эшли дә күп тешли; аккош очырып баеган; акмаса да тама; ата малы.*

10. «Акча колы, мал җыючы булу» мәгънәсендәге фразеологик әйтелмәләр: *акча дусты; корсак колы; акчага чукынган; акча капчыгы; акча корты; акча өчен анасын сатар; акча өчен иманын [җанын] саткан; алырсың шайтаннан иман; бармагы үзенә кәкре; бер тиенгә бетәшкән; бер тиен өчен йолдызга кармак атар; бер тиен өчен җәһәннәмгә керер; дөнья җитмәү; дөньяга баткан [бирелгән]; учыннан акканны ялаучы; эт авызындагы сөяк.*

11. «Акча тоту» мәгънәсендәге фразеологик әйтелмәләр: *исәпне хисапка китерү [чыгару]; сарыф итү; түшәгеңә [юрганыңа] карап аягыңны сузу; акча вату; акчаның йөгәне юк; акча тоту; акча чыгу [чыгару]; бөртекләп тоту; исәп-хисапны коры тоту; йодрыкка туплау; кесә як; кесәгә суга; кесәне кысып тоту; кесәсендә ун тиен акча булса, әтәч булып кычкыра; учка кысып тоту.*

12. Байлык, иминлек теләүне белдерүче фразеологик әйтелмәләр: *игелек күргере; өстәүле кием [мал] булсын; авыз-борыныгыз май булсын; аяклары төкле булсын; барына шөкер, югына төкер; башыңа дәүләт яусын; биргәненә шөкер; гаип хәзинәләреннән бирсен; тамгаң*

*ай булсын, нәселең бай булсын; ташка ябышсаң, көмеш булсын, туфракка ябышсаң, алтын булсын; төс бирсен; Ходайның биргәненә шөкер; хәерле кулдан; хәленә күрә хәере, ун тиенгә бер тиен; хәлле хәленчә, хәлдә барынча; эшләр уңсын, уңышлар бергә-бергә булсын; өегезгә бәрәкәт явып торсын; өстеңнән өстәлсен.*

Биредә кешенең яхшы матди хәлен белдерүче фразеологик әйтелмәләрне оештыручы доминант компонентлар булып шул ук тематикага караган *акча, алтын, тиен, тәңкә, сум, байлык, мал, хәзинә* лексик берәмлекләренең торуы табигый. Составында зоонимнар булган фразеологик әйтелмәләр көчле экспрессиягә ия: *акчасын тавык та чүпләп бетермәс; алашасы колынлау; [аның] дуңгызы да боламык ашый; [аның] әтәче дә кубыз уйный; [аның] әтәче дә күкәй сала; [аның] үгезе дә бозаулый; [аның] үрдәге дә каз кебек, йомыркасы баш кебек; үгезе үкерә; тәкә башы күрсәтеп эт ите сату.* Соматик атамалардан *авыз, кул, уч, корсак* сүзләре аеруча актив: *авызы икмәккә тук; корсак үстерү; кулга керү; уч тутырып акча алу.* Кешенең материаль хәле турыдан-туры аның көндәлек тормышы, тормыш дәрәҗәсе белән бәйле булу анализлана торган тематикага караган фразеологик әйтелмәләр составында көнкүреш сүзләренең күп кулланылуына китергән. Аларны шартлы рәвештә түбәндәге төркемчәләргә бүлеп карарга мөмкин: а) азык атамалары: *май, бал, он, тоз: ашаганы бал да май, казы да ял; балда, майда йөзү; он-тоз өстәленең төбе күренми; он-тоз өйдә, иләк-чүмеч чөйдә; авызы икмәккә тук; ашлы-сулы; күктән белен яуганда;* ә) кием яки кием детальләре атамалары: *итәге бөтен, җиңе киң; итәк-кунычы тулып; итәк-җиң бөтәйтү; атлы-тунлы кеше; итәк асты сәүдәсе; чабу астын тунау; кесәсе юан; кесә симертү; кесәгә хәрәкәт ясау; кесәне тишмәс;* б) өй кирәк-яраклары атамалары: *түшәгеңә [юрганыңа] карап аягыңны сузу; морҗадан төтен чыгару; чүптән көрәк булган, себеркедән куак булган; майлы таба ярату.* Анализлана торган семантик төркемдә *дөнья* сүзе бик актив катнаша. Ул тормыш, көнкүреш мәгънәләрендә *бай, бөтен, иркен, киң, түгәрәк* сыйфатлары белән килеп, кешенең яхшы материаль хәлен белдерә торган фразеологик әйтелмәләр барлыкка китерә.

Бай булуга татар халкының мөнәсәбәте ике төрле: акчаны тырышып эшләп, намус белән тапкан, кул һәм акыл көчен кулланып баеган кеше, әлбәттә, уңай караш, хөрмәт тудыра, ләкин әхлак нормаларын онытып, кеше рәнҗетеп, алдау юлы белән табылган байлык беркайчан да бәхет китерми. Мондый очракта татар халкында бай кешегә тискәре караш саклана.

Бу лексик һәм фразеологик берәмлекләр бер үк вакытта бай булуны да, кешенең уңай яки тискәре мөнәсәбәтен дә белдерергә сәләтле. Дөрес, әлеге вазифаны фразеологик берәмлекләр активрак башкаралар. Мәсәлән, *акчасын тавык та чүпләп бетермәс; аның алтыны янчыкта түгел, капчыкта; малга чумган* кебек фразеологик берәмлекләр бай кешегә карата соклану, хуплану кебек уңай караш тудырса,

*байлыгы кикертә, мае сикертә, маена чыдый алмау, симезлегенә чыдаша алмый* кебек фразеологик берәмлекләр, киресенчә, бай кешегә карата тискәре фикер уята.

**Әдәбият**

*Исәнбәт Н.* Татар теленең фразеологик сүзлеге: ике томда. I т. Казан: Татар. кит. нәшр., 1989. 495 б.; II т. Казан: Татар. кит. нәшр., 1990. 365 б.

Татар лексикологиясе: өч томда / проект җит. М.З. Зәкиев; ред. Г.Р. Галиуллина. Казан: ТӘhСИ, 2015. Т. I. 352 б.

Татар теленең аңлатмалы сүзлеге: өч томда. I т. Казан: Татар. кит. нәшр., 1977. 475 б.; II т. Казан: Татар. кит. нәшр., 1979. 726 б.; III т. Казан: Татар. кит. нәшр., 1981. 831 б.

Татар теленең диалектологик сүзлеге: ике томда. I т. Казан: Татар. кит. нәшр., 1969. 644 б.; II т. Казан: Татар. кит. нәшр., 1993. 460 б.

***Фәттахова Рузилә Фердавис кызы,***
*филология фәннәре кандидаты,*
*Татарстан Республикасы Мәгарифне үстерү институтының*
*татар теле һәм әдәбияты кафедрасы доценты*

УДК 81'342.622, 81'282

*А.Ә. Бәдртдинова*

# ТАТАР ТЕЛЕ КУЗНЕЦК СӨЙЛӘШЕНЕҢ ФОНЕТИК ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ
## (Пенза өлкәсенә 2021 елгы экспедиция нәтиҗәләре буенча)

В статье анализируются фонетические особенности речевых образцов, записанных во время экспедиции, организованной ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова АН РТ, с 28 июня по 9 июля 2021 года в Городищенском, Лопатинском, Шемышейском, Иссинском, Лунинском районах Пензенской области. В исследовании отмечается, что в говоре татар, проживающих в данных территориях, встречаются глубокозаднеязычные [к] и [ғ]. Автор также обращает внимание на нарушение сингармонизма в произношении некоторых слов, что проявляется в присоединении к корню слова с гласными заднего ряда окончаний с гласными переднего ряда. Кроме того в статье указывается на тот факт, что в речи жителей преимущественно встречается неогубленный звук [а], но в некторых случаях в первом слоге отмечается и сильно-огубленный звук [а$^{о}$].

**Ключевые слова:** западный диалект татарского языка, кузнецкий говор, пензенские татары, сингармонизм, неогубленный гласный, джоканье.

The article analyzes the phonetic features of speech samples recorded during the expedition organized by the G. Ibragimov Institute of Language, Literature and Art of the Academy of Sciences of the Republic of Tatarstan, from June 28 to July 9, 2021 in Gorodishchensk, Lopatinsky, Shemysheysky, Issinsky, Luninsky districts of the Penza region. The study notes that in the dialect of the Tatars living in these territories, there are deep Western-speaking [k] and [g]. The author also draws attention to the violation of disharmony in the pronunciation of some words, which manifests itself in joining the root of a word with vowels of the back row of endings with vowels of the front row. In addition, the article points to the fact that in the speech of residents an uninhabited sound [a] is predominantly found but in some cases a strongly-coarsened sound [a$^{o}$] is also noted in the first syllable.

**Keywords:** the western dialect of the Tatar language, the Kuznetsk subdialect, the Penza Tatars, vowel harmony, delabialization vowels, jokanye.

2021 елда Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты тарафыннан оештырылган комплекслы фәнни экспедиция кысаларында Пенза өлкәсендәге татарлар яши торган Городище районының Югары Әләзән (Аембура), Урта Әләзән, Түбән Әләзән, Лопатино районының Селәү, Иске Вершаут, Иске Карлыган, Берлек, Шемышейка районының Оз авылы, Исса районының Югары Салмука, Каменка (Плетневка), Шеркәвич (Кильмаевка), Лунино районының Шыкша (Синорово) авылларында тел, халык иҗаты, сәнгать, борынгы кулъязмалар һ.б. өлкәсендә фәнни тикшеренүләр үткәрелде.

Әлеге территорияләрдә татар теленең көнбатыш диалектына караган кузнецк сөйләше таралган. Мәгълүм булганча, бу диалект

сөйләшләре үзләренең тел үзенчәлекләре буенча ике зур төркемгә бүленәләр: чылаштыручы һәм цылаштыручы сөйләшләр. Пенза өлкәсендә, нигездә, чылаштыручы сөйләшләр очрый [Баязитова, 2008, б. 42].

Татар теленең көнбатыш диалекты XIX гасырда ук В.А. Казаринов (1885), Е.А. Малов (1885), Г. Н. Әхмәров (1903), С.Е. Маловлар (1904) тарафыннан өйрәнелә башлый. Без фәнни эзләнүләр үткәргән авылларда таралган сөйләшләрнең аваз үзенчәлекләре турында мәгълүмат «Татар халык сөйләшләренең электрон атласы»нда, «Татар халык сөйләшләре» (2008) җыентыкларының икенче томында чагылыш таба. Моннан тыш фонетик диалектизмнар «Татар теленең зур диалектологик сүзлеге»ндә урын ала. Әйтергә кирәк, сөйләшнең авазлар системасы Ф.С. Баязитова (2008), Л.Т. Мәхмүтова (1962), Э.Х. Кадировалар (2015) тарафыннан җентекле рәвештә тикшерелгән.

Экспедиция барышында сөйләш вәкилләренең сөйләмендә чагылыш таба торган фонетик үзенчәлекләрне өйрәнү махсус төзелгән сораулыклар ярдәмендә башкарылды. Шулай ук авторның шәхси күзәтүләре дә теркәп барылды. Сораулыклар буенча тикшергәндә, диалектлардагы лексик-фонетик диалектизмнар, аваз үзенчәлекләре чагыла. Сораштыручы сүзнең рус телендәге вариантын әйтә, сөйләш вәкиле аны татарчага тәрҗемә итә. Болай эшләгәндә ул нәкъ үзләре әйтеп өйрәнгәнчә җавап бирә. Мәсәлән, явым-төшемнәр темасы буенча сорау биргәндә, Городище районында яшәүче информантлар «град» сүзен «чарахман» дип тәрҗемә иттеләр. Бу сүз – диалектизм, татар теленең диалектлар сүзлегенә дә кертелгән, әдәби телдә «боз». Л.Т. Мәхмүтова фикеренчә, бу лексема шушы якларның күршесендәге Мордва өлкәсеннән кергән [Махмутова, 1962, б. 151].

Сөйләштә рус теленнән яки рус теле аша башка телләрдән кергән сүзләрне туган телгә яраклаштырып сөйләү күренеше күзәтелә. Без өйрәнгән җирлекләрдә ул түбәндәге сүзләрдә чагылыш таба: *балнис* – рус. больница, *вись* – рус. весь, *пинзә // пинза* – рус. пенза, *ысба // ызба* – рус. изба, *пуп* – рус. поп, *вәт // вот* – рус. вот, *капыста* – рус. капуста, *мор'а* – рус. море, *ләпәләре* – рус. лапа, лапки, *картук // карту* – рус. картофель, *ләщә* – рус. лещь һ.б.

Галимнәр әлеге территорияләрдә әдәби телдәге тирән тел арты [қ], [ғ] авазлары таралмаган дип яза [Баязитова, 2008, б. 43; Электронный атлас татарских народных говоров], ләкин без бу авазлар әйтелешен дә күзәттек. Димәк, сөйләш әдәби тел йогынтысы нәтиҗәсендә, күрше сөйләшләр һәм башка телләр тәэсирендә үзгәрешләр дә кичерә. Кайбер мисаллар: тирән тел арты [қ] авазы очраган сүзләр – *қая, юқ, йомырқа, бақый, қызыл, ақча, қаз, йолқалар, қоега, қызын, қадый, қалды, қайда, қуенында, қырларым, ерақ, қайсы;* тирән тел арты [ғ] авазы очраган сүзләр – *барырға, юк иде (йуғиде), булғаннар, соңға, ғына, сағынып, алғач, барғач, туған, ғомерең.* Шушы ук сүзләр [к], [г] авазлары белән дә әйтелә.

Без фәнни тикшеренүләр үткәргән авылларда күбрәк әдәби телдәге [җ] авазы белән әйтелгән сүзләр урынына [й] белән сөйләү таралган. Мисаллар: *җыела – йыйыла, җибәрәләр – йебәрәләр, җеп – йеп;* [җ] һәм [й] авазларын параллель куллану очраклары: *йыр* // *җыр, йырладылар* // *җырладылар, йеде* // *җиде* һ.б.

Татар әдәби теленнән аермалы буларак, сөйләштә [ч] авазы урынына күпчелек вакытта [$^{т}$ч] аффрикаты кулланыла: *ө$^{т}$чен$^{т}$че* – өченче, *үлгән$^{т}$че* – үлгәнче, *ке$^{т}$чкенә* – кечкенә, *ауга$^{т}$ч* – аугач, *кө$^{т}$чсез* – көчсез, *аерган$^{т}$чы* – аерганчы, *$^{т}$чабышып* – чабышып, *о$^{т}$чырдым* – очырдым һ.б. Шулай ук [тч], [$^{т}$ч], [ч] вариантлары да бар [Баязитова, 2008, б. 45].

Кайбер сүзләрдә палатальләшкән [д'] һәм [т'] авазлары әйтелә: *инд'е, айырд'ылар, саламд'ыр, ат'ылды.* Л.Т. Мәхмүтова да тартыклар кайвакыт үзгәреш кичерәләр, палатальләшәләр дип яза: *Хәсән – Хас'ан, кадер – кад'ыр, йад'ым – ядем, кардәш – хар'д'аш* [Махмутова, 1962, с. 130]. Автор фикеренчә, әлеге үзгәрешләр сузыклар тәэсирендә барлыкка килгән, арткы рәт сузыклары алгы рәт сузыклары белән чиратлашып, тартыклар нечкәрәк әйтелә [шунда ук, б. 130].

[у] һәм [а] авазлары бер-бер артлы килгәндә, аларның арасына [в] авазы өстәлә: *йуварга* – юарга (йуарга), *тувар* – туар, *тавык* – тавык (тауык*), быва* – буа, *сувык* – суык, *сөвәк* – сөяк (сөйәк), *йүвеш* – юеш (йүеш). Л.Т. Мәхмүтова *-уа, -үә* дифтонглары *-уwа, -үwә,* ешрак *-ыва, -евә* кебек әйтелә дип яза: *куак – куwак* // *кывак, куала – куwала* // *кывала* һ.б. [Махмутова, 1962, с. 155].

Сүзләрдә еш кына [а], [ә], [ө], [ү] авазларыннан соң килгән [й] тартыгы төшеп кала: *ка$^{т}$чан* – кайчан, *әдә* – әйдә, *әләндерәсең* – әйләндерәсең, *әтәлмим* – әйтә алмыйм, *әтелә* – әйтелә, *әләнә* – әйләнә, *әтәбез* – әйтәбез, *әберләр* – әйберләр, *сүли* – сөйли, *сүләми* – сөйләми, *ү* – өй, *үдә* – өйдә, *үләнергә* – өйләнергә, *кимә* – көймә.

Авылларда калын кушымчаларны нечкәртеп әйтү күренеше дә таралган, ягъни арткы рәт (калын) сузыкларыннан торган сүзләргә алгы рәт (нечкә) сузыклы кушымчалар ялгап сөйләү очрый: *кодагий* – кодагый, *булгалий* – булгалый, *урнең* – урының, *булсен* – булсын, *башымне* – башымны, *авылымне* – авылымны, *бормале* – бормалы, *юле* – юлы, *азаге – азагы, алыгез* – алыгыз, *ярларне* – ярларны, *туйганче* – туйганчы.

Җанлы сөйләмне күзәтү вакытында [и] һәм [е] авазларын чиратлаштыру күренеше дә теркәлде: *мескен – мескин, кеше – кише, җиде – йеде.*

Без йөргән авылларда күбрәк иренләшмәгән [а] авазы кулланыла. Шул ук вакытта кайбер сүзләрдә ул көчле олаштыруга дучар була: *а$^{о}$тасы, мулла$^{о}$, ча$^{о}$кта, а$^{о}$ны.* Бу яктан кузнецк сөйләше урта диалект белән уртаклык күрсәтә [Бәдртдинова, 2017, б. 31].

Көчле олаштыру [у] авазын әйткәндә дә сизелә. Аерым очракларда ул [о] авазы белән алыштырыла: *шондый* – шундый, *шолай* – шулай. Әлеге күренешкә мисаллар башка галимнәр хезмәтләрендә дә

китерелә: урлау – *орлау,* курчак – *корчак,* ул – *ол,* усак – *осак* [Баязитова, 2008, б. 42]. Сөйләш өчен шулай ук [ү] авазын да [ө] авазына охшатып әйтү хас: *үөстер* – үстер*, күөп* – күп. Шуның белән бергә [ү] авазын [у] авазына охшатып калынайтып сөйләү очраклары да билгеләнде: *куп* – күп*, бурәнә* – бүрәнә*, кук* – күк. Сөйләштәге әлеге күренешләрне, күбрәк материал җыеп, махсус эксперименталь методлар белән тикшерү сорала.

Нәтиҗә ясап әйткәндә, Пенза өлкәсе авылларында таралган сөйләш үзенең фонетик үзенчәлекләре ягыннан татар теленең көнбатыш диалекты белән тыгыз бердәмлек күрсәтә. Шул ук вакытта анда урта диалект өчен хас күренешләр дә урын ала. Моннан тыш, ул билгеле бер дәрәҗәдә әдәби тел йогынтысын да кичерә, мәсәлән: сөйләшләрдә тирән тел арты [к] һәм [ғ] авазлары очрый, көчле иренләшкән [°а] авазы да теркәлде. Башка үзенчәлекләргә килгәндә, сөйләштә рәт гармониясе бозылу күренеше: арткы рәт сузыклары белән әйтелүче сүзләргә алгы рәт сузыклы кушымчалар ялгану, кайбер очракларда тартыкларны палатальләштерү, [ж] авазы белән әйтелүче сүзләрне күбрәк [й] авазы белән әйтү, [у] һәм [а] авазлары бергә килгәндә аларның арасына [в] авазы өстәү һ.б. үзенчәлекләр билгеләнде.

**Әдәбият**

Атлас татарских народных говоров [Электронный ресурс]. URL: https://atlas.antat.ru/ (мөрәҗәгать көне: 05.03.2024).

*Ахмаров Г.Н.* О языке и народности мишарей // Известия Общества археологии, истории и этнографии при Имп. Казан. ун-те. Т. XIX. Вып. 2. Казань, 1903. С. 92–160.

*Бәдртдинова А.Ә.* Татар теленең урта диалекты вокализм системасына күзәтү // Фәнни Татарстан. 2017. № 4. С. 28–34.

*Баязитова Ф.С.* Кузнецк сөйләше // Татар халык сөйләшләре: ике китапта. II китап / Ф.С. Баязитова, Д.Б. Рамазанова, Т.Х. Хәйретдинова һ.б. Казан: Мәгариф, 2008. Б. 42–53.

*Кадирова Э.Х., Галиуллина Г.Р., Сайфулина Ф.С., Юсупова Ә.Ш.* Мордовия Республикасы һәм Пенза өлкәсе татарлары: диалектология һәм халык авыз иҗаты материаллары. Казан, 2015. 313 б.

*Казаринов В.А.* О мишарях в Чистопольском уезде Казанской губернии // Известия Общества археологии, истории и этнографии при Имп. Казан. ун-те. Т. IV. Казань, 1884. С. 9–10.

*Малов Е.А.* Сведения о мишарях: Этногр. очерк / [Соч.] Прот. Е.А. Малова. Казань: Тип. Казан. ун-та, 1885. 79 с.

*Малов С.Е.* Из поездки к мишарям: (О наречии мишарей Чистопольского уезда). Казань: Типо-лит. Имп. ун-та, 1904. 24 с.

*Махмутова Л.Т.* Основные характерные черты мишарских говоров на территории Пензенской области (по материалам экспедиций 1958–1960 гг.) // МДТ. Вып. 2. Казань, 1962. С. 125–162.

***Бәдртдинова Алсу Әнис кызы,***
*ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият*
*һәм сәнгать институтының нәшрият бүлеге редакторы*

УДК: 821.512.145

*Д.Ф. Заһидуллина*

# ӘМИРХАН ЕНИКИНЕҢ СУГЫШ ТУРЫНДАГЫ ӘСӘРЛӘРЕНДӘ МӨСЕЛМАН ДӨНЬЯ СУРӘТЕ

Статья посвящена исследованию элементов мусульманской картины мира в «военной» прозе Амирхана Еники. На материале анализа рассказов «Бер генә сәгатькә» («На один только час», 1944), «Тауларга карап» («Глядя на горы», 1948) и автобиографической повести «Без дә солдатлар идек» («И мы были солдатами», 1971) установлено, что его произведения о войне характеризуются присутствием духовно-религиозных традиций татарского народа. Если в рассказах элементы мусульманской картины мира участвуют в воссоздании характеров набожной Марьям-абыстай или Шамсинур-аби, которые искренне уповают на Аллаха, уже в повести, появившейся на волне литературных трансформаций периода «оттепели», прозаик рисует солдат-сослуживцев в условиях ежесекундной встречи со смертью, когда сама ситуация позволяет выражать свое духовное состояние. В его творчестве впервые в татарской советской литературе происходит воссоздание мусульманской картины мира, которая напоминает о глубинных традициях, ментальности, мировоззрении татарского народа.

Мы склонны считать, что прозаик, воспитанный в традициях мусульманской семьи-рода, и самым светлым событием детства, послужившим «духовному перерождению», вспоминал совершение намаза своим дедом, только во время Великой Отечественной войны получил возможность показать образ верующего человека. «Обойти» идеологическую цензуру позволило амплуа героев: в рассказе «Бер генә сәгатькә» Марьям-абыстай – мать троих сыновей, защищающих родину! Во втором рассказе «Тауларга карап» Лукман-карт и его жена Шамсинур-аби в Первой мировой и Великой отечественной войнах потеряли сына и внука! Только одной фразой прозаик намекает, что вчерашний солдат Ахметвали также чтит духовно-религиозные традиции.

Демократические перемены 1960-х годов позволили А. Еники написать повесть «Без дә солдатлар идек» с опорой на мусульманскую картину мира. В это время, по воспоминаниям прозаика, «стало возможным писать, как я сам этого хочу». В повести наблюдается мусульманский взгляд на бытие, жизнь и смерть повествователя и его однополчан – молодых героев. Полуоткрытое выражение мусульманской картины мира ведущим прозаиком А. Еники, первые глубоко психологические рассказы военной поры которого изменили татарскую литературу, стало рубежным явлением в изображении мусульманской картины мира татарской прозой второй половины XX века.

**Ключевые слова:** татарская литература, военная проза, Амирхан Еники, мусульманская картина мира, духовно-религиозные традиции.

The article is devoted to the study of the elements of the Muslim worldview in the “military” prose of Amirkhan Yeniki. Based on the analysis of the short stories “Ber gena sagatka” (“For only one hour”, 1944), “Taularga karap” (“Looking at the Mountains”, 1948) and the autobiographical novel “Bez da soldatlar idek” (“And we

were soldiers", 1971), it is established that his works about the war are characterized by the presence of the spiritual and religious traditions of the Tatar people. If the elements of the Muslim worldview in the stories participate in recreating the characters of the pious Maryam-abystai or Shamsinur-abi, who sincerely rely on Allah, already in the story, which appeared on the wave of literary transformations of the "thaw" period, the novelist paints fellow soldiers in conditions of a second-by-second encounter with death, when the situation itself allows them to express their spiritual state. In his work, for the first time in Tatar Soviet literature, the Muslim worldview is recreated, which recalls the deep traditions, mentality, and worldview of the Tatars

We tend to believe that the novelist, brought up in the traditions of a Muslim family and the brightest event of childhood, which served as a "spiritual rebirth", recalled the performance of prayer by his grandfather only during the Great Patriotic War he got the opportunity to show the image of a believer. The role of the heroes allowed to "circumvent" ideological censorship: in the story "Ber gena sagatka" Maryam-abystai is the mother of three sons defending the motherland! In the second story "Taularga Karap", Lukman-kart and his wife Shamsinur-abi lost their son and grandson in the First World War and the Great Patriotic War! With only one phrase, the novelist hints that yesterday's soldier Akhmetvali also honors spiritual and religious traditions.

The democratic changes of the 1960s allowed A. Yeniki to write the novel "Bez da soldatlar idek" based on the Muslim worldview. At this time, according to the prose writer's memoirs, "it became possible to write as I want it myself". In the story there is a Muslim view of the existence, life and death of the narrator and his fellow soldiers – young heroes. The semi-open expression of the Muslim worldview by the leading prose writer A. Eniki, whose first deeply psychological wartime stories changed Tatar literature became a milestone phenomenon in the depiction of the Muslim worldview by Tatar prose of the second half of the twentieth century.

**Keywords:** Tatar literature, military prose, Amirkhan Yeniki, Muslim worldview, spiritual and religious traditions.

Совет әдәбиятында 1930 еллар ахырыннан башлап дини дөнья сурәте тулысынча кысрыклана, идеологик цензура дини кыйммәтләрне бары тик кире кагу максаты белән генә телгә алырга рөхсәт итә, дигән караш яши. Бер яктан, бу сүзләрдә дөреслек бар. Ф. Әмирханның «Тәгъзия» (1922) хикәясе мөселман дөнья сурәтен тергезеп язылган соңгы әсәрләрдән була.

Әмма Бөек Ватан сугышы, бигрәк тә аннан соңгы вазгыять алып килгән күпмедер ирек татар язучыларына бу хәлне үзгәртергә мөмкинлек бирә. Күренекле прозаик Әмирхан Еники иҗаты моңа мисал була ала. Татар әдәбиятына кешенең рухи олылыгын үзәккә куйган шәхес концепциясе алып кергән прозаик үз чоры каләм иҗатын XX йөз башы татар язучыларының психологизм һәм фәлсәфи гомумиләштерү мөмкинлекләреннән оста файдаланган әсәрләре белән ялгап җибәрә. Аның психологизм төп эчтәлекне хасил иткән сугыш чоры хикәяләрендә фаҗигалы вакыйгаларның кеше күңелендә чагылышын сурәтләү үзәккә алына [Заһидуллина, б. 186–188].

Моның сәбәпләре турында уйлаганда, иң беренче чиратта, язучының мөселман гаиләсендә үсеп, дини-рухи тәрбия алуын күрсәтергә

кирәк. Кечкенә генә бер мисал. Үзенең «Соңгы китап» дип исемләнгән истәлекләрендә ул бик кечкенә чагыннан «күңелендә уелып калган» бер күренешне, бабасының «чирәмгә кара җиләнен» җәеп, намаз укырга керешүен искә төшерә: «Ни хикмәттер, мин үскәч тә, олыгайгач та, хәтта менә картайгач та, әнә шул күренешне – бабакайның үлән-чәчәкләр арасында тезләнеп намаз укуын һич оныта алмадым. Ниндидер бик якты бер эз калдырды ул минем бала күңелемдә. Бәлки, шул мизгелдә мин әйләнәмдәге сихри дөньяны ачыграк күрә, тирәнрәк тоя башлаганмындыр... Нәрсә дим, мин бит үзем дә үлән биеклек кенә бала, берни аңламаган, берни белмәгән бала гына. Тик менә хәзер уйлап куйгалыйм: шул бала чакта күргәнем миңа соңыннан иң авыр чакларда да дөньядан бизмәскә ярдәм итмәде микән?!» [Еники, т. 4, б. 29].

Ә. Еники генә түгел, сугыш чорының барлык язучылары да диярлек – мөселманнар булып тәрбияләнгәнлекне истән чыгармау зарур, билгеле.

Бу урында иҗтимагый-сәяси факторларны да күздән ычкындырмаска кирәк. 1930 еллар ахырыннан урнашкан цензура Бөек Ватан сугышы елларында күпмедер йомшара: татар язучыларына да, патриотик хисләрне җырлау дулкынында, туган җир, әти-әни, бабалар мирасы кебек кыйммәтләргә мөрәҗәгать «рөхсәт ителә». Дөнья күреп, үлем белән күзгә-күз очрашып кайткан фронтовик язучылар исә милли-рухи кыйммәтләрнең мөһимлеген тагын да тирәнрәк аңлап каләмгә үреләләр.

Ә. Еникинең «Бер генә сәгатькә» (1944) хикәясе сугыш чорын, Галимҗан абзый белән Мәрьям абыстай гаиләсендәге бер көнне сурәтли. Госпитальдән фронтка китеп бара торган эшелоны станциядә туктагач, уллары Гомәр бер генә сәгатькә күрешергә кайта. Гаять тәэсирле бу хикәя, психологизмның «җан диалектикасы» кебек катлаулы төренә мөрәҗәгать итеп, геройларның үзгәреп торучы кичерешләрен барлык ваклыкларында тергезүе белән үзенчәлекле.

Мәрьям абыстайның диндә булуы аның исеме янына кушылган «абыстай» сүзеннән дә, сөйләшүеннән дә күренеп тора. Улын күргә, карчык бу күрешү өчен Аллаһка рәхмәтен укый: «Ходаем, зиһеннәрем таралып китте. Төшемме дип торам. Үзем көтә идем бит, көтә идем, йөрәгем сизә иде. Йа Раббым, догаларымны бушка куймадың, инде Шакир белән Фатихымны гына күрәселәрем калды» [Еники, т. 1, б. 12]. Сүз саен Аллаһны (Ходаем, аһ Аллам, Раббым һ.б.) телгә алган Мәрьям, улы яралануын сөйли башлагач та, «берничә тапкыр, үзалдына гына: “Йа Раббым, йа Раббым”, – дип куйды» [Еники, т. 1, б. 14]. Бер урында автор Галимҗан авызыннан да ике тапкыр «Амин» сүзен кабатлата.

Язучы Мәрьямнең үз язмышын да, балалары язмышын да асылда Аллаһ кулына тапшырганлыгын, алар өчен дога кылып яшәгәнлеген хикәянең ахырында, улларын озатырга станциягә килгән ана авызыннан әйттерә. Күңеле Гомәренең иптәшләренә «рәхмәт белән» тулган

карчык: «“Иптәшләре, Ходайга шөкер, әйбәт кешеләр икән!” – ди һәм улының киләчәк гомере, саулыгы өчен тынычлану тоя» [Еники, т. 1, б. 17]. Инде саубуллашу мизгеле җиткәч, ана кеше болай ди: «Хуш, улым! Алла хәвеф-хәтәрләрдән үзеңне сакласын. Яңадан исән-сау күрешергә язсын!» [Еники, т. 1, б. 18].

Шундый ук күренеш «Тауларга карап» (1948) хикәясендә дә күзәтелә. Локман карт һәм Шәмсинур карчык – сугышлар ялгыз тормышка дучар иткән геройлар – Аллаһка шөкер итеп яшиләр. Улларын, оныкларын югалткан, өметләре өзелергә җиткән картларга, оныкларының улын күтәреп, Сания кайтып керү менә болай сурәтләнә: «Биләү эчендә, имезлеген кабып, йокыга киткән 3–4 айлык бала ята иде. Карчык белән карт аның өстенә иелделәр. Шәмсинур әби эченнән генә кызу-кызу нидер укырга тотынды. Локман карт та, нидер әйтмәкче булып, иреннәрен кыймылдатты...» [Еники, т. 1, б. 47].

Картлар гына түгел, аларның оныгы Батырханның дусты, сугыштан исән кайткан яшь герой – Әхмәтгали дә шушы традицияне читкә куймый. Хәлен сораган Шәмсинур әбигә ул болай дип җавап бирә: «Шөкер әле, Шәмсинур әби, сезнең хәер-фатихада менә йөреп кайттык» [Еники, т. 1, б. 38]. Шул рәвешле, яшәеш кыйммәтләре буларак нәсел, дәвам, мәхәббәт аерып чыгарылган хикәядә язучы сугыштан соңгы татар көнитешендә дини-рухи күзаллауның бик табигый яшәвен ассызыклый.

Бу хикәяләр – совет чорында дин-иманлы геройны тискәре яктан сурәтләмәгән беренче әсәрләрдән. Аларның язылуы, басылып чыгуы да милли геройларны тасвирлауда сугыш чоры алып килгән бераз иркенәю белән генә аңлатыла аладыр. Мәрьям абыстай өч улын фронтка озаткан, Шәмсинур карчык исә Беренче бөтендөнья сугышында – улын, Бөек Ватан сугышында оныгын югалткан. Күрәсең, шушы факт әсәрләрне бастыру мәсьәләсен хәл иткәндә дә геройларның менталитетына хөрмәт белән карарга юл ача. Шул ук вакытта бу урында «Тауларга карап» хикәясенең 1948 елда «Совет әдәбияты» журналыннан төшереп калдырылуын да искә алырга кирәк.

Ә. Еникинең дини күзаллауны аерым бер характер билгесе буларак күрсәтүдән – дини дөнья сурәтен тергезүгә килүе, шиксез, «җепшеклек» алып килгән иркенлек белән бәйле була. Бу хакта язучы үзенең истәлекләрендә дә искәртә: «Иң мөһиме: үзем теләгәнне үземчә язу мөмкинлеге туды кебек» [Еники, т. 5, б. 179].

1971 елда Ә. Еники «Без дә солдатлар идек (Фронт дәфтәреннән)» дигән автобиографик повесть яза. Мәгълүм ки, Еники үзе сугышта хуҗалык һәм каравыл гаскәрендә хезмәт итә. Повестьта 1944 елда, инде немецлар чигенгән бер вакытта, боеприпаслар складын саклаучы 15 кешелек взводның тормышы берничә зур вакыйгада тасвирлана. Әсәрнең хикәяләүчесе – сержант Еникеев, автор образы белән тәңгәлләшә. Повестьта да геройларның күбесе – мөселманнар, автор иман мәсьәләсен аларның характерын тирәнтен ачу өчен файдалана.

Әмма, хикәяләрдән аермалы буларак, повестьтагы вакыйгалар һәрберсе сугыш хәлләрен илаһи алдан билгеләнгәнлек, тәкъдир белән аңлату төсен ала. Язмышка буйсыну, гомерне Аллаһ ихтыярына тапшыру – солдатларның күзаллавын да, аларны яшәткән өметне дә, ислам фәлсәфәсен дә белдерә. Әлеге мәсьәләгә фәнни караш ташлаган Г.Д. Гачев мөселман фәлсәфәсен болай аңлата: «Мөселман күккә якынрак. Күк исә – якты йолдызлары язу булган саф китап: анда илаһият, мәңгелек һәм кеше акылы гына бар итә алмас Коръән. Шуннан Язмыш җебе сузыла. (...) Язмышны күктә укып булмас. Аны каян табарга соң? Йөрәктә, “мин”дә, шәхестә, характерда һәм ихтыярда: нәрсә телисең – шул синең язмышыңа әйләнә» [Гачев, б. 160].

Повестьта өч зур вакыйга бар. Шартлы рәвештә беренчесен «Бомбага тоту» дип атап булыр иде. Анда хикәяләүче 1942 елның кышында станцияне немец самолётлары кинәт бомбага тотуны искә төшерә. Писарь Еникеев, рота командирын эзләп, посёлокка юнәлә. Шулвакыт бомбага тоту башланып, әле генә хикәяләүче утырган бүлмә бомба шартлап актарыла, шушы йортта торучы хатын һәлак була. Әлеге күренешне сурәтләгәндә «Йа Рабби», «Ходаем» кебек гыйбарәләрне иркен кулланган автор вакыйганы мондый сүзләр белән тәгәлли: «Уйлыйм: мин бит бернинди хәтәр сизмичә генә чыгып киттем, әмма нәкъ соңгы чиктә генә кузгалганмын, бер генә минутка соңга калсам да, бүлмә эчендә булмаса, йортның тышында мин үлем тырнагына эләккән булыр идем... Кемнең генә догасы мине бу һәлакәттән коткарды икән?... Бәлки, әнкәйнеңдер, бәлки, әнкәй минем колагыма шыпырт кына: “Улым, тор, чык!” – дип әйткәндер... Шулай... Гаҗәп икән бу кеше язмышының серләре – үлем килеп җиткәндә генә берәү чыгып китә, ә берәү әнә...кайтып керә!» [Еники, т. 3, б. 158].

Шушы вакыйганы куәтләп, автор тагын бер хатирә белән уртаклаша. Анда Федько исемле шофёрның бомбага тоту вакытында бернинди физика законнары белән аңлатып булмый торган рәвешле машинасы белән исән калуы, аннары атта барганда минага эләгеп һәлак булган солдат Ефимов, атның һәм җәяүләп атлаган ике солдатның исән калуы сөйләнә. Монда да автор түбәндәгечә нәтиҗә ясый: «Йә, нәрсә әйтәсең? Язмыш... Ләкин теге ике солдат өчен дә язмыштыр инде бу, әмма бәхетле язмыш, чөнки, үзләре дә белмәстән, арткарак калып атламаган булсалар, алар да шунда беткән булырлар иде...» [Еники, т. 3, б. 171].

Сугыш шартларында булсалар да, автор мөселманнарның шпик ашамавын сөйләп уза. Бу икенче вакыйганы – Латвияда утар хуҗасыннан сарык сатып алып пешерү вакыйгасын сөйләүгә килеп ялгана. Сарыкны алып кайту, казакъ һәм кыргызларның аны чалуга, ашарга пешерүгә гаҗәеп бер илаһи гамәл итеп караулары, өлкәннәргә хөрмәт күрсәтү, һәркемгә тигез өлеш чыгару кебек детальләр дә әсәрдә мөселман әхлагы-гадәте кебек күзаллана.

Өченче һәм соңгы вакыйга – сержант Еникеевның, җиде солдат белән дошман тылын узып, поездда алгы сызыктагы сугышчыларга

боеприпаслар илтә баруы. Караңгы төндә дошман снарядлары астында куркыныч юлны узганда, һәркемнең күңелендәге курку һәм ышаныч хисен казакъ Байәхмәт әйтеп бирә: «Әҗәлнең кайда икәнен белеп буламыни? Әллә җирдә, әллә монда, Ходайның бер үзенә тапшырыйк!» [Еники, т. 3, б. 229]. Куркыныч бетүгә, солдатлар «Аллага мең шөкер» кылалар [Еники, т. 3, б. 230]. Бу очракта да хикәяләүче язмыш мотивын калкуландыра.

Геройлар арасында авторга дини карашларны күрсәтергә аеруча ярдәм иткән герой – үзбәк Ишмәмәт. Аның чуваш Емелькин белән дини мәсьәләдә бәхәсләре әсәрне буеннан буена кисеп үтә. Казакъларның да Емелькинга «Ходайдан да курка белми» дип караулары, соңгысының казакъларны татарлар намаз укырга өйрәткән дип көлүе [Еники, т. 3, б. 224–225], башка детальләр сугыш шартларында иман мәсьәләсенең актуальләшүен ачыклый.

Емелькинга куянны үтерергә ярамаганны сөйләгән Ишмәмәт сүзен болай йомгаклап куя: «Мин аның кальбен аяп әйтәм, кальбе ташка әверелмәсен...» [Еники, т. 3, б. 179]. Мөселманлыкны шушыннан да тирәнрәк аңлатып булырмы?! Үлем мәсьәләсендә дә ул үз язмышын Аллаһ кулына тапшырган! Дүрт баласы булуны телгә алып, болай ди: «Миңа үләргә ярамый, Ходай мине саклаячак» [Еники, т. 3, б. 179]. Куркыныч сәфәр тәмамлангач та, Ишмәмәт, «исән каласымны алдан ук белеп тордым» [Еники, т. 3, б. 230] дип, моны да дүрт баласы көтеп тору белән бәйләп аңлатып китә. Аның бу сүзләрен солдатларның «Ходайның Мәҗнүн колы» [Еники, т. 3, б. 231] дип бәяләве дә совет идеологиясенең гади кешеләр күңеленнән динне кысрыклап чыгара алмаганлыгын кабат искәртә.

Тагын бер өлкән яшьтәге герой – татар Төхфәт абзый авызыннан язучы «Агач башы» дигән борынгы җырны җырлата. Аның «Агач башкайлары тәсбих әйтә» дигән тезмәләрен хикәяләүче исеменнән кабатлатып, болай дип куя: «Гаҗәп, кешенең күңел хәзинәсеннән ниләр генә табылмый! Җитмәсә, менә монда, туган илдән ерак читят җирләрдә! ..Хәер, язмыш кешене кайларга гына ташламасын, күкрәгендә шул ук бер йөрәкне йөртә инде ул...» [Еники, т. 3, б. 171]. Бу җырның хәтердә калкып чыгуын Төхфәт абзый үзе дә «Ходаның хикмәте» дип бәяләп уза.

Шул рәвешле, «Без дә солдатлар идек» повесте язучының дини лексика кулланып, мөселман геройлар тудырудан дин фәлсәфәсен, аның үлем белән күзгә күз очрашкан совет солдатларына рухи көч бирүче булуын җиткерүгә кадәр юл узуын күрсәтә. Дини дөнья сурәте Ә. Еникигә сугыш турындагы әсәрләрне өмет ноктасында төгәлләргә мөмкинлек бирә. Үз чиратында, дин – туган җир, ата-бабалар, милли моңнар, туган тел, вөҗдан кебек үк, татарлар өчен иң югары рухи кыйммәтләрнең берсе, аларның милли үзтәңгәллеген билгеләүче кебек аңлатылыш таба.

1960 еллар татар әдәбиятындагы эчтәлек һәм форма ягыннан үзгәрешләрне әйдәп барган Ә. Еники прозасы дини мотивларны милли

мәдәниятебезгә кайтаруны башлап җибәрүчеләрдән була. Бу яктан да алга таба башка язучылар иҗатында дәвам итәчәк эзләнүләрнең башы шушы иҗатта булуы бәхәссез [Заһидуллина, б. 210].

**Әдәбият**

*Гачев Г.Д.* Национальные образы мира. Евразия – космос кочевника, земледельца и горца. М.: Институт ДИДИК, 1999. 368 с.

*Еники Ә.* Әсәрләр: 5 томда. 1 т.: Хикәяләр. Казан: Татар. кит. нәшр., 2000. 447 б.

*Еники Ә.* Әсәрләр: 5 томда. 2 т.: Повестьлар. Казан: Татар. кит. нәшр., 2002. 400 б.

*Еники Ә.* Әсәрләр: 5 томда. 4 т.: Соңгы китап: истәлекләр. Казан: Татар. кит. нәшр., 2003. 479 б.

*Еники Ә.* Әсәрләр: 5 томда. 5 т.: Публицистик язмалар, мәкаләләр. Казан: Татар. кит. нәшр., 2004. 479 б.

*Заһидуллина Д.Ф.* 1960–1980 еллар татар әдәбияты: яңарыш мәйданнары һәм авангард эзләнүләр. Казан: Татар. кит. нәшр., 2015. 383 б.

***Заһидуллина Дания Фатих кызы,***
*филология фәннәре докторы, профессор, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының әдәбият бүлеге баш гыйльми хезмәткәре*

УДК 821.512.145

***В.Ф. Макарова***

# БӨЕК ВАТАН СУГЫШЫННАН СОҢГЫ ТАТАР ПРОЗАСЫ КОНТЕКСТЫНДА ХӘСӘН САРЬЯН ИҖАТЫ: МИЛЛИ-ДИНИ КҮЗАЛЛАУЛАРНЫ ТЕРГЕЗҮ

В статье рассматривается творчество татарского прозаика 50–70-х годов прошлого века Хасана Сарьяна. Анализ лейтмотива повести «Пять сыновей матери» позволяет определить отношение писателя к религии. Х. Сарьян, несмотря на идеологические ограничения, с помощью подтекста находит возможность возрождения этно-религиозных традиций татарской литературы.

**Ключевые слова:** послевоенная татарская проза, лейтмотив, реминисценция, деталь, намёк, мотив смерти.

The article examines the work of the Tatar prose writer of the 50–70s of the last century Hassan Saryan. The analysis of the leitmotif of the story “Five Sons of a Mother” allows us to determine the writer’s attitude to religion. H. Saryan despite ideological limitations finds an opportunity to revive the ethno-religious traditions of Tatar literature with the help of subtext.

**Keywords:** post-war Tatar prose, leitmotif, reminiscence, detail, hint, motive of death.

Тарихка объектив мөнәсәбәт – барыннан да элек, аерым кешенең, бөтен халыкның, җәмгыятьнең иҗтимагый һәм әхлакый үсешен, мәдәниятен билгели торган мөһим факторларның берсе. Моны иҗат кешеләре, шул исәптән татар язучылары да тирән аңлаганнар. Әле 1924 елда ук Ф. Әмирхан «Шәфигулла агай» әсәрендә совет җәмгыятендәге яңа гадәтләрне дини йолалар белән янәшә куеп, берәр догмага фанатикларча табыну, аны тормышта сукырларча куллану кешене кызганыч, көлке хәлләргә китерергә һәм аны мәгънәсез затка әйләндерергә мөмкин икәнен күрсәткән иде. Әдип әлеге әсәре белән киләчәктә балаларны денсезлек, манкортлык көтүе, гасырлар буена урнашып килгән әхлак, традицияләрнең, ата-баба гадәтләренең, теленең югала баруы турында искәртте [Макарова, 1995]. Әмма 1930 еллардан башлап мондый фикерләрне әдәби әсәр битләренә төшерү дә куркыныч була башлады.

Бары тик Бөек Ватан сугышы һәм сугыштан соңгы елларда гына, иҗат эшендә күпмедер иркенлек бирелүгә, аерым язучыларның әсәрләрендә милли традицияләр «кайта башлады». Бу урында күренекле әдәбиятчы А. Әхмәдуллинның сүзләрен искә төшерү урынлы булыр: «Матур әдәбиятта сыйфат үзгәрешләре, гадәттә, берьюлы, кинәт кенә барлыкка килми. Яңалык еш кына күнегелгән тормышта, ягъни иске эчендә туа, шунда үсә, җитлегә. Татар әдәбиятының бүгенге, үзгәреш

һәм яңарыш елларында ирешелгән уңышлары да берьюлы, әзерлексез генә була алмас иде. Совет җәмгыятендәге хәлләрнең асылын ачкан тормыш дөреслегенә ирешү юлы аерым язучылар өчен 60–70 нче елларда ук башланды» [Әдәбият, 2000, б. 143]. Әлеге үзгәрешләрне башлаган иҗатчыларның берсе күренекле прозаик Хәсән Сарьян (1930–1978) булды. Милләтчелектә гаепләнеп, үзенә психологик басым ясалуга карамастан, әсәрләрендә милли хисләр, халкыбыз тарихына, туган телгә, дингә мөнәсәбәт ярылып ята.

Бу җәһәттән Сарьянның «Зәңгәр күл сагышы» хикәясе, «Егет язмышы», «Нокталы өтер», «Бер ананың биш улы» повестьлары игътибарга лаек.

Иң элек, язучының үз фикерләрен җиткерү өчен персонажларның кинаяле сөйләмен куллануы күзгә ташлана. «Нокталы өтер» (1976) әсәрендә, әйтик, Айбулатов фамилияле персонаж болай ди: *...Тарихи үсешнең бүгенге этабында милли тойгылары булмаган кешене мин кешегә дә санамыйм, милли тойгы әле ул – милләтче дигән сүз түгел!* [Сарьян, 1990, б. 133]. Бу җөмлә интернационализм байрагы астында азчылык милләтләрне йоту сәясәте алып барылган чорда Х. Сарьянның милли мәсьәләләргә үз карашы булуын күрсәтеп тора. Шушы ук әсәрдә хикәяләүче: *Без элек Коръәнне белми идек, беләсебез килсә дә укый алмый идек* [Сарьян, 1990, б. 133], – дип, халыкның диннән аерылып яшәргә мәҗбүр булуын искәртә.

«Зәңгәр күл сагышы» (1969) хикәясендәге яратып сурәтләнгән герой – бабасының Коръән күчереп язучы булуы белән горурланган Хәнәфи дә милли тарих белән кызыксына: *Болгарлар турында соңгы елларда күп яза башладылар бит. Болгар дигәннәре, кара син аны, нинди һөнәрле, культуралы халык булган икән лә бит? Әле безнең Чишмә якларына кадәр килеп, нинди мәчетләр салып куйганнар, ә! Без үзебез дә, борынгылар сөйләвенә караганда, ничектер шул болгарларга килеп бәйләнәбез икән...* – [Сарьян, 1980, б. 292] ди ул.

Шулар янәшәсендә хикәяләүче күзәткән тирә-юнь сурәте киная булып яңгырый: *Кояшка чагылып, нурланып яткан өйләр, сарайлар өстендә башларын горур чөеп үрә каткан чиркәү манаралары йөзә, шулар янында бер Сөембикә манарасы гына, моңсу йөз белән кыегая төшеп, түзем аналарыбыз шикелле, тын гына, берүзе читтә басып тора иде. И Казан... Ярый әле, җан кебек якын күргән син бар...* [Сарьян, 1980, б. 257].

Моңа нисбәтән, язучының аерым әсәрләре еш кына бер-берсе белән әдәби «сөйләшү» алып бара. «Зәңгәр күл сагышы»нда болгар бабаларыбызның мәчетләр салып калдыруы турында әйтелсә, «Егет язмышы» повестенда исә бик үк ерак булмаган заманнарда мәчет манарасын кисү картинасы сурәтләнә: *Ходаем ярлыка! – дип, таякка таянган Сәйдә әби дә көрсенеп куйды. – Әүвәл мәчет юлын ташлаттылар, инде хәзер манарасын да кисәләр. Ил өстендә дога кунар җир дә калмый икән, болай булгач... Җан бирәселәребез барлыгын уйламыйлар микәнни соң болар бер дә...* [Сарьян, 1980, б. 177].

Коммунистик идеологиянең милли хисләрне, динне бетерергә тырышуын автор вакыйга-күренешләргә дә сала. Мәчет манарасын кисәргә мәҗбүр булган Нуриман, Фидаилләр («Егет язмышы») – шул чор корбаннары. Бәлки, язучы повестьның журналдагы исемен тиккә генә «Җәза» дип атамагандыр [Сарьян, 1980]. Әсәрдә аның мәгънәсен ике төрле аңларга булыр иде: 1) Баһау картның картлык көнендә кылган җинаятьләре өчен җәза алуы; 2) изге урынны мәсхәрәләгән кешеләрнең язмышлары аяныч булу.

Язучы юмористик, сатирик хикәяләрендә замандашларының ата-баба әхлагына туры килмәгән сыйфатларын тәнкыйтьли (әйтик, ураза вакытында нәфесен тыя алмаган Өркыя әби («Ураза вакытында» (1974) [Сарьян, 1974] хикәясе һ.б.). «Бер ананың биш улы» (1976) әсәрендә исә дини ышануларга битараф булуның эчкечелек кебек ямьсез күренешләрне китереп чыгаруын тасвирлап, әдип халык әхлагының, ата-баба кануннарына нигезләнгән милли яшәү рәвешенең бәхәссез өстенлеген раслый. Дини тәгълиматның чор таләпләренә каршы килүен күрсәтеп, социалистик системаның киләчәге булуына шик белдерә.

Сириннең *Безгә шундый начар гадәт кайдан килгән?* дигән уйлары эчүчелекнең килеп чыгу сәбәпләрен тирәннән эзләргә чакыра. *Барыемыни ул сугышка тикле эчү!* [Сарьян, 2000, б. 272] – ди Шәрифулла карт һәм елына бер *җиде баласы өчен акча алган көнне бер чүлли эчеп* кайткан Кәҗә Талипны искә ала. Димәк, сугышка кадәрге татар авылында таза әхлакка корылган кануннар ныграк сакланган, бу ят гадәт бик сирәк күренеш булган.

Әсәрдә эчкечелекнең соңгы елларда гадәти күренешкә әйләнеп китүен, хәтта иң изге йолаларның да аракыга көйләнә башлавын күрсәтә торган гыйбрәтле деталь бар. Өй күтәргәндә, матчага яңа гына мичтән чыккан зур түгәрәк ипи, калган дүртесенә дүрт ярты бәйләп куялар [Сарьян, 2000, б. 354]. Ире сугышта үлгәч, акылдан шашкан хатын, эчкечелеккә бирелгән Раббани мисалында авырлыкларга каршы тора алмаган яшь буын һәм аларга контраст түземле, дини тәрбия алган ана сурәтләнә.

Өмәчеләр стаканнарын күтәргәндә, ят гадәт буенча, мәрхүм Солтанны искә алалар, русча әйтсәк, поминать итәләр. Шунда ук сугышның шәхес психикасына ясаган тәэсире дә сизелеп китә: күп үлем күргән Раббани *Тёмная ночь. Только пули свистят в тишине...* дип, *сугыштан кайтканнан бирле көйли торган* җырын сузып җибәрә [Сарьян, 2000, б. 355]. Һөҗүмгә ташланыр алдыннан сугышчыларга спиртлы эчемлек эчертә торган булганнар – әлеге күренешләр укучыда әнә шул мәгълүматны яңарта. Димәк, татар авылларында эчүчелекнең тамыр җәюе сугыштан аракының тәмен белеп кайткан ирләргә дә барып тоташа икән. Сугышка кадәр дини инанулар да шактый көчле була әле. Сугышта дуңгыз ите ашап, аракы эчәргә күнеккән ир-атлар тыныч шартларда да шуны ук дәвам иттерәләр. Аракы сату планын кайгырткан кибетчеләр гаебенә дә ишарә бар. Дини таләпләргә көлке

итеп караган совет чынбарлыгы мохитендә эчкечелеккә бирелү өчен киртәләр калмый. Х. Сарьян исә шуларны бербөтен милли проблемага әйләндерә.

Эчкечелекнең аяныч нәтиҗәләргә китерүе турындагы фикер әсәрдә кабатлап бирелә: Мирзаны исерек хулиганнар үтерә; Язиләнең ире эчеп асылынып үлә; Шәрифулла картның да, эчеп, бөерләре «кара янып» чыккан була; эчкечелек Раббаниның да вафатына китерә. Язучының «Егет язмышы» әсәре дә үлем белән башлана, үлем белән тәмамлана. Шуның кебек, «Бер ананың биш улы» әсәрендә дә үлем мотивы кабатлана. Яшәү һәм үлемнең чиратлашуы сөйләмгә эмоциональ фон биреп кенә калмый, үлем мотивы җәмгыятьтә шәхес фаҗигасын, деградацияләнү сәбәпләрен күрсәтә. Х. Сарьян әлеге мәңгелек фәлсәфәнең безнең замандагы аспектларына игътибар юнәлтә. Дини күзаллау дини тәрбия алган, үлгәч кешенең җаны күбәләк булып әйләнеп кайта, дип чын күңелдән инанган ананың үлемгә мөнәсәбәтендә тергезелә [Сарьян, 2000, б. 332]. «Егет язмышы» әсәрендә ул, әтисе үлгәч, кечкенә Даниалга әбисенең бу турыда сөйләвендә күренә.

Эчкечелеккә китергән сәбәпләрнең иң мөһиме – тормыш авырлыгыннан туган ачы хисләр, чорның сорылыгы, юклык, күпме эшләсәң дә тормыш шартларының яхшырмавы турындагы фикерләр «Бер ананың биш улы» әсәрендә тулы бер яшерен эчтәлек хасил итә. Әлеге әсәрне анализлаган Ф. Зөлкарнәевнең «Яшәү дәрте» мәкаләсендә [Зөлкарнәев, 1991, б. 84–96] әсәрнең «фәлсәфи тирәнлеге, халкыбызның милли йөзен, холкын, аның тормыш фәлсәфәсен төгәл бирә алуы», фикерләвенең халыкчан булуы һәм халыкка үз-үзен, үз характерларын күрсәтүе әйтелә.

Повестьның сюжеты артык гади, гадәти кебек тоела, хикәяләү тыенкы гына алып барыла сыман. Ләкин, ныграк игътибар итсәң, аның һәр юлы, һәр сүзе соңгы чиккәчә киерелгән җәя кебек. Язучы сугышка кадәр, тылда, авылда калганнарның тормышына һәм бигрәк тә сугыштан соңгы чор авылына, замандашларына үз карашын сиздерергә омтыла. Әмма ул ишарә-киная өстә генә түгел, бәлки шактый тирәндә ята. Язучының төп фикере, дөньяга карашы, әсәрнең лейтмотивы аскы агымда.

Ф. Зөлкарнәев язганча, әдәбиятның «кинаяләр теленә күчүе, халкыбызның борынгы риваятьләрендә сөйләнгән (кыргыз язучысы Ч. Айтматов тетрәндергеч итеп тасвирлап биргән) маңкорт хәленә төшмәс өчен, һичнәрсәгә карамыйча көрәшүенең бердәнбер һәм соңгы, әмма нәтиҗәле чарасы иде» [Зөлкарнәев, 1991, б. 42]. «Бер ананың биш улы» повестенда да төп фикер читләтеп яисә сизелер-сизелмәс штрихлар аша әйтеп киленә дә (яшәү һәм үлемнең чиратлашуы), автор әсәр азагында ул фикерне гомумиләштереп куя. Өченче улының үлемен кичерергә мәҗбүр булган, бер төндә чәче агарып чыккан ана улының: *Бу кайгыларга ничек түзеп торасың икән акылдан язмыйча!* – диюенә болай җавап бирә: *Мин дә акылдан яз-*

*сам, Раббани улымның бәбәйләрен кем карар?* [Сарьян, 2000, б. 416]. Әлеге сүзләрдә әсәрнең лейтмотивы чагыла.

Биредә «түзү» фәлсәфәсе Коръәни сабырлык мәгънәсендә бирелә. Бер баласы үлгән көнне икенчесенә туй үткәрергә рөхсәт биргән, ирен, өч баласын югалткан ананың олы җанлылыгы, иман ныклыгы, яшәү көченең зурлыгы халыктан, дини тәрбиядән килә. Туган кавеменең тормышка карашы, яшәү фәлсәфәсе аның канына сеңгән. Мәһисәрвәр апа – халыкның гасырлар кичеп формалашкан иң яхшы әхлакый сыйфатларын үзенә җыйган, шуларны оныкларына тапшыручы типик образ. Ана образында халыкның матур теле, гореф-гадәтләре, җыры-моңы, күңеле бирелә. Мәһисәрвәрнең исеме үк халыкны яктылыгы белән ияртүче дигәнне аңлата. «Сәрвәр» исеме «халык башлыгы, ияртүче», «Мәһи» – «айга ия» дигәнне белдерә [Саттаров, 1998, б. 160]. (Гомумән, Х. Сарьян персонажларына исем куйганда, аның мәгънәсенә игътибар иткән. Моның шулай булуын «Исемең кем синең?» исемле язмасы да раслый [Сарьян, 1974]. Язучыларның бу өлкәдә табышларын барлаганда да, ул тапталган, калькалаштырылган исемнәрне тәнкыйтьли) .

Ана образына бәйләп, язучы күп кенә дини детальләрдән файдалана: *Улым изге зат иде, җәннәткә эләккәндер,* – дип сөенә ул. Мәһисәрвәргә дини ышанулары кайгыларга түзәргә ярдәм итә, көч бирә. Догалар укуы (мәсәлән, Хәвадискә кырык бер ясин чыгуы [Сарьян, 2000, б. 385]), дини йолаларны җиренә җиткереп үтәве аның күңеленә күпмедер тынычлык китерә. Корьәннән реминисценцияләр [Хализев, 1999, б. 272] ананың дини эчтәлектәге китаплар белән яхшы ук таныш булуы турында сөйли. Биредә дини фактлар, дини затлар искә алына. *Башкайларның исән булуы Сөләйман пигамбәр дәүләтеннән дә зуррак байлык шул!* [Сарьян, 2000, б. 251] – ди ана (билгеле булганча, Корьәннең 38–37 нче сүрәләрендә Сөләйман пәйгамбәрнең байлыгы турында сүз бара [Корьән, 2000, б. 438]). Ана улларына теләк теләгәндә: *Локман Хәким гомерләре бирсен,* – ди [Сарьян, 2000, б. 256] (дини китапларда Локман мең ел яшәгән кеше буларак бирелә [Сарьян, 2000, б. 385]). *Бәндәләрнең тәкъдире, үзләре туганчы ук, ләүхелмәхфүзгә язып куелган. Кырык ел кырылыш булса да, әҗәле җиткәннәр генә үлә дигән...* [Сарьян, 2000, б. 251]. Моны сын сугышта өч улы үлгән Чибәр әби әйтә. «Ләүхелмәхфүз – Аллаһ янындагы иң дәрәҗәле язмыш – тәкъдир китабы» (Сарьян аңлатмасы [Сарьян, 2000, б. 251]). Әсәрдә 1946–1947 елның кышында яңгыр яуганда, хәвефле көннәрдә әбиләр еш әйтә торган сүзләр китерелә: *Тәкый гаҗәб хәлләри вар*. Көйләп язылган «Ахырзаман» китабындагы һәр куплет «Тагы да гаҗәп хәлләре бар» дигән сүзләр белән тәмамлана» дип, автор аңлатма бирә [Сарьян, 2000, б. 561]. Әсәргә «раббәнә», «әтинә», «фиддөнья», «хәсәнәти» кебек дини сүзләр, дини китаплардан реминисценцияләр кертеп, язучы халыкның дини күзаллаулар белән яшәвен күрсәтә. Ананың яшь бозауны өшкерттерү күренешләрен тасвирлап [Сарьян, 2000, б. 272], *әбиләрнең мәүлет аенда*

*гына әйтә торган*, иске татар телендәге мөнәҗәтләрен әйттереп [Сарьян, 2000, б. 263], ул халыкның үткәненә, борынгыдан ук килә торган гореф-гадәтләренә ишарә ясый.

Гомумиләштергәндә, Й. Нигъмәтуллинаның күп кенә язучыларыбыз «идеология басымына карамастан, аңлы яки интуитив рәвештә, төрле ысуллар белән, әдәбиятыбызның гомумкешелек традицияләрен, дөреслекне җиткерү алымнарын саклап калдылар, үстерделәр» [Нигматуллина, 1997, с. 146], – дигән сүзләрен кабатларга мөмкин. Х. Сарьян кебек язучылар, идеологик чикләүләргә карамастан, характерлар тудырганда, персонажлар сөйләмендә, контраст чагыштыруларда, гыйбрәтле вакыйгаларда, детальләрдә татар әдәбиятының милли-дини традицияләрен тергезү мөмкинлеген таба.

**Әдәбият**

*Әдәбият* (XX йөзнең 30–90 нчы елларында татар әдәбияты): Татар урта гомуми белем мәктәбенең 11 нче сыйныфы өчен дәреслек. 2 нче басма, тулыл. Казан: Мәгариф, 2000. 335 б.

*Зөлкарнәев Ф.* Сабыр төбе алтынмы? Чакма чакмый ут чыкмый: Әдәби тәнкыйть мәкаләләре һәм парчалар. Казан: Татар. кит. нәшр., 1991. 184 б.

*Корьән* / Р. Батулла эшкәртүендә. Казан: Татар. кит. нәшр., 2000.

*Макарова В.* Фатих Әмирхан иҗатын өйрәнгәндә («Шәфигулла агай» хикәясенә анализ) // Мәгариф. 1995. № 2. Б. 29–31.

*Нигматуллина Ю.Г.* Типы культур и цивилизаций в историческом развитии татарской и русской литератур. Казань: Фэн, 1997. 190 с.

*Сарьян Х.* Бер ананың биш улы: Повесть, хикәяләр. Казан: Татар. кит. нәшр., 2000. 301 б.

*Сарьян Х.* Җәза: повесть // Казан утлары. 1980. № 3. Б. 9–51.

*Сарьян Х.* Егет язмышы: Повестьлар, хикәяләр. Казан: Татар. кит. нәшр., 1980. 400 б.

*Сарьян Х.* Исемең кем синең? Татарстан язучыларының VIII съездын каршылап // Социалистик Татарстан. 1974. 19 май.

*Сарьян Х.* Нокталы өтер: Повестьлар. Казан: Татар. кит. нәшр., 1990. 416 б.

*Сарьян Х.* Ураза вакытында: Хикәя // Азат хатын. 1974. № 4. Б. 14–15.

*Саттаров Г.* Татар исемнәре ни сөйли? Татар исемнәренең аңлатмалы сүзлеге. Казан: Раннур, 1998. 224 б.

*Хализев В.* Неавторское слово. Литература в литературе. Теория литературы. М.: Высшая школа, 1999. 398 с.

***Макарова Венера Фәйзи кызы,***
*филология фәннәре докторы,ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының әдәбият белеме бүлеге әйдәп баручы фәнни хезмәткәре*

УДК 821.512.145

***А.С. Шәрипова***

# 1970–1980 ЕЛЛАР ТАТАР ДРАМАТУРГИЯСЕНДӘ КЛАССИК РОМАНТИЗМ ТРАДИЦИЯЛӘРЕ ЯҢАРЫШЫ
## (Илдар Юзеев иҗаты мисалында)

В статье на примере творчества Ильдара Юзеева раскрываются особенности романтического направления в татарской драматургии 1970–1980-х годов. По мнению автора, возрождение традиций классического романтизма достигалось путём активного обращения драматургов к условным приёмам, поэтическим образам-символам, отражающим специфику идеализированного взгляда на изображённую действительность, а также благодаря психологизму и лиризму, что стало предпосылкой для содержательных и качественных изменений поэтического мира драматургических произведений. Укрупнение масштабов конфликта пьес, особое эстетическое использование категорий времени и пространства при развития сюжетных линий, условно-метафорический способ организации действия, мифологизированные и идеализированные герои, фольклорно-мифопоэтический текст, активное использование символов и архетипов, отражающих национальное своеобразие и специфику, обеспечивают глубину основной идеи, создают возможность для передачи скрытого содержания, позволив создать высокохудожественные драматургические произведения, направленные на формирование этнического самосознания татарского народа.

**Ключевые слова:** татарская драматургия, И. Юзеев, романтизм, конфликт, проблема, идея, архетип, фольклорно-мифопоэтический сюжет, концепция героя.

Using the example of Ildar Yuzeev's work the article reveals the features of the romantic trend in Tatar drama in the 1970s and 1980s. According to the author the revival of the traditions of classical romanticism was achieved through the active appeal of playwrights to conventional techniques, poetic images-symbols reflecting the specifics of an idealized view of the depicted reality, as well as through psychologism and lyricism which became a prerequisite for meaningful and qualitative changes in the poetic world of dramatic works. The enlargement of the scale of the conflict of plays, the special aesthetic use of the categories of time and space in the development of storylines, the conditionally metaphorical way of organizing action, mythologized and idealized characters, folklore and mythopoetic text, the active use of symbols and archetypes reflecting national identity and specificity, provide the depth of the main idea, create the opportunity to convey hidden content allowing you to create highly artistic dramaturgical works aimed at the formation of the ethnic identity of the Tatar people.

**Keywords:** Tatar dramaturgy, I. Yuzeev, romanticism, conflict, problem, idea, archetype, folklore-mythopoetic plot, hero concept.

1970 еллар татар драматургиясендә «чынбарлыкны фәлсәфи тоемлау һәм яңа сәнгати алымнар эзләү юнәлешендә җитди үзгәрешләр башлана» [Ханзафаров, 1996, с. 242] һәм бу билгеле бер дәрәҗәдә

XX йөз башы татар әдәбиятына хас булган классик романтизм традицияләре торгызылу белән дә бәйле була. 1960 еллар рус сәхнә әдәбиятындагы кебек үк, «романтикларның әхлакый пафосы, иң әүвәл, шәхес кыйммәтен расларга тырышу омтылышы белән аңлатыла. Актив позицияле, тормыш прозасына каршы бунт күтәргән, һәр эшкә хакыйкать эзләү аша бару кирәклеген аңлаган яңа герой килә. Билгеле бер дәрәҗәдә ул – Гаделлекнең җиңүенә, илнең якты киләчәгенә ышанган хыялый герой» [Денисова, 2013, с. 92]. «Романтизмның милли әдәбиятка әйләнеп кайтуы өр-яңа форма һәм эчтәлек тәкъдим итте, кешедә аң төпкеле, сиземләү, күзаллау-хыял белән бәйле яңа яклар ачарга, әдәбиятта тормышның чиксезлеген һәм кешенең эчке дөньясының байлыгын белдерүче геройлар тудырырга мөмкинлек бирде» [Заһидуллина, 2015, б. 183]. Бу, нигездә, шартлы әдәби чараларга, милли рухны чагылдыра торган символларга мөрәҗәгать итү, психологик алымнар, лиризм аша башкарыла. Әлеге юнәлештә Илдар Юзеев, Әхсән Баянов, Туфан Миңнуллин, Сәет Шәкүров, Әхәт Гаффар һ.б. уңышлы эшлиләр. Романтик пафос хәтта хезмәт темасын яктырткан пьесаларда да (С. Шәкүров. «Туган туфрак» (1968); Т. Миңнуллин. «Кырларым, тугайларым» (1978); Аяз Гыйләҗев. «Китмәгез, тургайлар» (1978) һ.б.) өстенлек ала башлый. «Шартлы-мифологик, символик образлар ярдәмендә җәмгыятьтәге үзгәрешләрнең кешегә йогынтысын күрсәтү көчәя» [Миңнуллина, 2018, б. 29].

1970 еллар татар драматургиясендә романтик юнәлеш үсеш алуда танылган драматург, Татарстан Республикасының халык шагыйре Илдар Юзеевның (1933–2004) роле аеруча зур. Ул «шигърияткә киң масштаблы фәлсәфи эчтәлекне кайтара, яшәү-үлем, шәхеснең үз-үзен һәм яшәешне танып белүе, мәхәббәт кебек фәлсәфи концепцияләрне шигъри әсәр мисалында кулланып карый, моңа ирешү юлында дөньякүләм танылган мифларга мифлаштыру яки мифны җимерү алымнарына таяна, XX йөз башы модернистлары үрнәгендә символистик фикерләү алымнарыннан файдалана. Шушы сыйфатлар, драма әсәрләрендә дә дәвам итеп, үстерелеп, аны башка драматурглардан аерып торучы үзенчәлек – хасиятләр булып формалашып җитә» [Йосыпова, 2018, б. 345].

И. Юзеевның драматургия өлкәсендә иҗади эшчәнлеге 1960 елларда башланып китә, ул – драматик поэмалар һәм шигъри трагедияләр иҗат иткән сирәк авторларның берсе. Аның төрле жанрга караган ике дистәгә якын пьесасы бар, аларның бер өлеше тезмә формада язылган («Янар чәчәк» (1960–1961), «Бөркетләр кыяга оялый» (1970), «Соңгы төн» (1968–1972), «Сандугачлар килгән безгә» (1974), «Кыр казлары артыннан» (1976–1989), «Кайтмый калсам, көтәрсеңме?» (1977), «Бәхетемнән узып барышлый» (1979), «Очты дөнья читлегеннән...» (1980), «Мәңгелек белән очрашу» (1982) һ.б.). Үзәгенә кеше һәм табигать, шәхес һәм җәмгыять, буыннар арасындагы бәйләнеш, тарихи хәтер мәсьәләләре куелган әсәрләренең төп үзенчәлеге шунда: алар романтик күтәренкелек, шигъри аһәң, фәлсәфи тирәнлек белән

аерылып торалар. «Сәхнәне шигъри эчтәлек белән баеткан» [Ахмадуллин, 2012, с. 404], «драматургиядә дә шагыйрь булып калган» [Әхмәдуллин, 2007, б. 114] автор пьесаларының күбесе татар театр сәнгатендә лаеклы урын алды, Татарстандагы гына түгел, ә республикадан читтәге татар театрлары сәхнәләрендә дә зур уңыш белән барды, тамашачы мәхәббәтен яулады.

И. Юзеев драматургиясенә хас төп үзенчәлекләрнең берсе буларак, Р. Мостафин автор ремаркаларында ачыктан-ачык күрсәтелмәгән, кеше күзенә күренмәгән шартлы романтик герой булуны атый, галим фикеренчә, бу – тарихи үткәнебез, сугыштан кайтмаган геройлар, халык бәхете өчен төрле елларда яшьлекләрен, хыялларын корбан иткән кешеләр турындагы хәтер, нәкъ менә шулар геройларның әхлакый йөзен билгели [Мостафин 2001, б. 313]. Л. Ваһапова фикеренчә дә, «хәтер категориясе язучының сәнгати дөньясында төп категория булып тора, һәм бүгенге чынбарлык белән хыялда тудырылган вакытның үзара тәэсире сюжетның нигезен тәшкил итә. Геройларны берничә пространство-вакыт (тарихи, биографик, менталь) аралыгына кую драматургка текстны урын һәм вакыт ягыннан монтажларга, пьеса сюжетын коллажга корырга мөмкинлек бирә» [Вагапова, 2011, с. 6]. Бу хасиятләр «Кыр казлары артыннан» драмасы һәм «Мәңгелек белән очрашу» шигъри трагедиясендә аеруча ачык чагылыш таба.

«Кыр казлары артыннан» драмасында 1970 еллар татар авылында барган вакыйгалар сурәтләнгән. Сюжет туган җирендә яшәүче абыйлы-энеле Малик һәм туган ягына археологик экспедициягә кайткан галим Халик Бикташевларның очрашуына бәйле вакыйгага мөнәсәбәтле үстерелеш ала. Пьеса Халикның туган җиренә кайтуы, ата-бабалары белән хыялдагы диалог формасында аның эчке халәтен, фәлсәфи уйлануларын тасвир иткән романтик-фәлсәфи прологтан башланып китә. Шул рәвешле, автор әсәрнең экспозиция өлешендә үк, шартлылык алымын куллану аша, пьесаның төп идеясен билгели, ул туган җиргә, тарихи хәтергә һәм буыннар арасындагы бәйләнешне сакларга чакыру белән бәйле.

Пьесага символик образлар төрлелеге хас. Драматург яшәеш, кеше язмышы, тормыш мәгънәсе, гомумкешелек кыйммәтләре турындагы фәлсәфи фикерләрен укучыга җиткерү өчен, *көмеш битлек, кыр казлары, салават күпере, ана кабере* образ-символларын куллана. Сюжет үстерелеше капка ясау барышында табылган *баш сөяге* һәм борынгы *көмеш битлек* образ-символлары аша башкарыла. Нәкъ менә шушы табылдыкларга мөнәсәбәт аша автор үзәк геройларның тормышка карашларындагы каршылыкны күрсәтә, драманың конфликтын туганнар арасындагы низаг нигезендә кора.

Үзәк герой Халикның тормыштагы миссиясе автор тарафыннан «иҗатчы» мәгънәсен аңлата торган исеменә үк салынган: ул кайчандыр әлеге төбәктә яшәгән кешеләр турында күбрәк белергә омтыла, шунлыктан галим өчен табылдык көмеш битлекнең фәнни кыйммәте бик зур, ә һәрвакыт башкалардан яхшырак яшәү теләге белән янып

йөргән Малик өчен исә табылдыкның материаль кыйммәте мөһим. Пьесада әлеге символ рухи байлыкны, халыкның рухи ныклыгын, традицияләрнең дәвамлылыгын символлаштыра, төп геройларның дөньяга карашын, киләчәк язмышын билгеләүдә хәлиткеч критерийга әверелә. Пьесаның финал күренешендә Малик битлекне суга ташлый, шуның белән шартлы рәвештә үзенең язмышын билгели: ул тормыш мәгънәсен җуя – гаиләсен – хатыны Ясминәне, улы Римны, үзенең әхлакый йөзен югалта.

XX гасыр татар шагыйрьләре (Һ. Такташ. «Кыр казлары» (1926); Ә. Фәйзи. «Кыр казлары» (1940); Ф. Кәрим. «Кыр казы» (1941)) тарафыннан әсәрләрендә актив кулланылган *кыр казы* архетипик образы И. Юзеев драмасының исеменә үк чыгарылган, ул әсәр сюжетында берничә тапкыр кабатланып, мәхәббәт хисләрен һәм рухи кичерешләрне, гомумән, кешенең психологик халәтен билгеләүгә хезмәт итә, иреккә омтылу символы булып тора, Ясминәнең чынга ашмаган хыялларын күрсәтә. 1980–1990 еллардагы татар прозасында, аерым алганда, М. Мәһдиевнең «Торналар төшкән җирдә», М. Юнысның «Җир, су һәм күк турында», Г. Гыйльмановның «Оча торган кешеләр», Н. Гыйматдинованың «Каракош», «Ак торна каргышы», Ф. Бәйрәмованың «Канатсыз акчарлаклар» әсәрләрендә урын алган «оча торган кеше» архетипик образының Л. Дәүләтшина билгеләгән үзенчәлеге – бер яктан, күк белән аерылгысыз булган һәм күңелләре, уй-ниятләре чиста кешеләрне илаһилаштыру, ә икенче яктан, «канатлары сындырылган», югалып калган, ялгыз, бәхетсез язмышларны сурәтләү [Давлетшина, 2005, с. 17] әлеге пьесага карата да актуаль. Ясминәнең рухи халәтен сурәтләү өчен, автор герой башкаруында пьесага «Кыр казлары артыннан» лирик җырын кертә, нәкъ менә әлеге җыр персонажның хис-кичерешләрен, теләк-омтылышларын, өмет-үкенечләрен укучы-тамашачыга җиткерүгә хезмәт итә.

*Ана кабере* архетибы әсәрдә буыннар арасындагы бәйләнешне күрсәтү вазифасын үти. Хәлим, казу эшләре башланганчы, иң элек әнисенең каберенә бара һәм туган йортына керә. Татар халкына хас әти-әни хәер-фатихасы төшенчәсе әсәрдә шул рәвешле чагылыш таба. Халикны кына түгел, укучыны да тетрәндергән әдәби деталь – кабергә юлның куе үлән белән каплануы – милли традицияләрнең юкка чыгуына, әхлакый кыйммәтләрнең үзгәрүенә, буыннар арасындагы элемтәләрнең өзелүенә ишарә. Р. Мостафин билгеләгәнчә, И. Юзеев шигъриятенең сәнгати үзенчәлеге – үзәк идеянең «туган туфрактан башка, гадәти җир матурлыгыннан башка яшәеш тә, иҗат да, космоска омтылыш та мөмкин түгел» дигән фикер белән бәйләнеше [Мустафин, 2006, с. 269] драмада үзәк герой репликасы аша җиткерелә:

*«Х а л и к. Бабаларыбыз, аталарыбыз безгә җир-туфрак кына калдырмый, шуның өстенә алар безгә кул белән тотып булмый торган ядкәр – балаларының йөрәгенә күчеп кала торган иң изге орлык – мәхәббәт, матурлык рухы калдырганнар»* [Юзеев, 1980, б. 50].

Драмада автор тарафыннан әсәр тукымасына кертелгән мәңгелек саф сөю турындагы Шәрык риваяте аерым миссия үти. Бу очракта параллель үткәрелә: Әкбәр Маликка яңа йорт төзи һәм эше өчен акча алмый, аның өчен хезмәтенең бәяләнүеннән бигрәк, үзенең тәүге һәм бердәнбер мәхәббәте Ясминәне күрү мөмкинлеге мөһим. Шәрык риваяте белән параллель үткәрү драманың эмоциональ тәэсир көчен арттыруга хезмәт итә.

«Кыр казлары артыннан» драмасында төп герой Халик укучыга идеаллаштырылган милли характер буларак тәкъдим ителә. Автор археолог образына, шулай ук халыкның тарихи үткәненә мөрәҗәгать итеп, тамырлары белән күпгасырлык милли традицияләргә барып тоташкан кыйммәтләргә игътибарны юнәлтә. Символик образларга, шартлылыкка мөрәҗәгать итү, шигъри чаралар, ремаркалар, җырлар куллану – болар барысы да лирик-эмоциональ башлангычны, романтик рухны көчәйтә һәм әсәрнең сәнгати кыйммәтен арттыра.

Л.Н. Ваһапов билгеләп үткәнчә, И. Юзеев пьесаларының мифопоэтик вакыт-урын бердәмлеге күп катламлы булуы белән дә аерылып тора: пространство һәм вакыт категорияләре аның драматургиясендә сюжет ясаучы элементлар гына түгел, символларга, мифологемаларга әверелә һәм авторның фәлсәфи карашларын чагылдыра [Вагапова, 2011, с. 16). Бу җәһәттән шигъри формада язылган «Мәңгелек белән очрашу» (1982) трагедиясе аерым игътибарга лаек.

Трагедия мистик-мифологик һәм реалистик ике катламны үз эченә ала, аларның үрелеп баруы әсәрнең тирән фәлсәфи эчтәлеген тәэмин итә. Чынбарлык күренешләре прологта урын алган, бу пьесаның төп герое – археологик төркем җитәкчесе Атлантның кайчандыр хәрби бәрелешләр булган урыннарда казу эшләре алып барганда сугыш чорыннан калган снаряд шартлавыннан җитди яралануын тасвир итү белән бәйле. Аның үлем алды халәте борынгы грек мифологиясе геройларына бәйле алты күренештә сурәтләнә: 1) «Атлант җир астына китә»; 2) «Атлантның Җир асты Алласы белән очрашуы»; 3) «Атлант Аллалар арасында»; 4) «Афинаның Атлантка килүе»; 5) «Афина атасы Зевс каршында»; 6) «Афинаны җәзалау. Атлантның үлеме». Вакыйга өч вакыт яссылыгында бара: җир астында – борынгы чор, җир өстендә – бүгенге көн, күктә – киләчәк заман. И. Юзеев, борынгы грек мифологиясе сюжетына һәм образларына мөрәҗәгать итү аша кешелек дөньясы өчен хас булган гомумкыйммәтләр системасын булдыра. Фәлсәфи-романтик мотивлар, мифологик образлар, сурәтләнгән картиналарның масштаблылыгы, романтик һәм реалистик алымнарның үрелеп баруы кешелекнең үткәне һәм киләчәге, шәхеснең рухи гармониясе белән бәйле глобаль гомумкешелек проблемаларын тирән фәлсәфи планда күтәрергә мөмкинлек тудыра.

Трагедия сюжеты нигезенә кайчандыр Атлантик океанда булган һәм инде җир йөзеннән эзсез югалган серле Атлантида утравы турында риваять салынган. Борынгы грек фәлсәфәчесе Платон язмалары буенча, су астында калган әлеге утрауда кайчандыр югары цивилизация

булган, һәм анда бәхетле, горур халык – атлантлар яшәгән. Риваять буенча, бервакыт аларга Зевсның бик нык ачуы чыга һәм ул утрауны җир өстеннән юкка чыгара. Атлантиданың югалу серен ачыклау турында хыялланган үзәк герой Атлант үзенең Җирдәге миссиясен «бөтен кешелекнең шәҗәрәсен» төзүдә, үз халкының язмышына кагылышлы тарихи хакыйкатьне эзләүдә күрә. Шулай итеп, «Мәңгелек белән очрашу» трагедиясе сюжеты төп геройның, асылда, үзенең чын «мин»ен эзләвенә корылган, бу И.Юзеев драматургиясенә хас булганча, анда «очрашу, юл, сәяхәт һәм кайту мотивлары, туры мәгънәдән тыш, тирән эчке мәгънә йөртә. Аның өчен юл – кешенең үз асылына кайту юлына тиң» [Вагапова, 2011, с. 20]:

*«А т л а н т.*
*... Җирдә яшәр өчен мәңгелеккә*
*Килмәвемне беләм, –*
*Тик шулай да очрашырга телим*
*Мин мәңгелек белән!»* [Юзеев, 2019, б. 102].

Әсәрнең сюжеты буенча, Атлант, яралангач, аңын югалта һәм аның «хыялы эшкә җигелә»: ул Аллалар арасына, үзенең тарихи үткәненә килеп чыга. Зевс, аның кызы – акыл алиһәсе Афина, җир асты патшалыгы алласы Аид, язмыш алиһәсе Ананка, ташка әверелгән газиз этисе белән очрашу халыкның гасырлар буена сер пәрдәсе артында калган тарихын ачуга китерә. Трагедиянең конфликты атлантлар һәм Зевс каршылыгы мисалында яхшылык белән яманлык бәрелешенә нигезләнә, шуның белән беррәттән, автор фикеренчә, кешелек дөньясын һәлакәткә алып барган яманлыкның төп чыганагы булып илаһи көчләр түгел, ә иң беренче чиратта, гади җир кешесе үзе тора. Җир йөзендәге фаҗигаларның, глобаль проблемаларның төп сәбәпләре булып бетмәс-төкәнмәс сугышлар, халыклар арасындагы дошманлык, кеше үзе башлап җибәргән экологик һәлакәтләр тора, һәм бу фикер Атлантның этисе сүзләренә салынган:

*«Т о р а т а ш.*
*Без ышанып киттек Җирдән,*
*Соңгы бу сугыш диеп,*
*Балаларга яшәү биргән*
*Соңгы бу сулыш диеп...*
*(Тораташларның сүзсез авазы.)*
*Яңа сугыш гөрелтесе*
*Диңгездә, Җирдә, Күктә...*
*(Еракта атом бомбасы шартлаган авазлар.)*
*Ракеталар һәр кешене*
*Юк итәр йөкләр йөртә!»* [Юзеев, 2019, б. 118].

Әсәрнең төп идеясе кешелек дөньясын үзенең тарихи үткәне, бүгенгесе һәм киләчәк язмышы турында уйланырга чакыру һәм үзеннән алдан килгән буыннарның фаҗигалы язмышын, хаталарын кабатламаска өндәүдән гыйбарәт.

Билгеле булганча, «икенчел шартлылык алымын куллану сүз сәнгатенең мөмкинлекләрен киңәйтә, аңа шигъри күзаллау тирәнлеге һәм фәлсәфи күпмәгънәлелек бирә» [Давыдова, Пронин, 2003, с. 26]. Автор кулланган символ-образлар – салават күпере, яшен, күк күкрәү, мәңгелек ут – трагедиянең фәлсәфи яңгырашын тирәнәйтүгә, Җир асты, Күкләр, Кыя-таулар, Кыя-ташлар, Сугышчылар, атлантлар, Нимфалар хорлары үзенчәлекле структур-композицион төзелеш булдыру, шартлылык аша әсәрнең төп идеясен ачуга, романтик пафосның көчәюенә, метофорик мәгънәне тирәнәйтү һәм әсәрнең сәнгати көчен арттыруга хезмәт итә.

Татар драматургиясенең романтик-фәлсәфи юнәлеше үзенчәлекләрен аеруча тулы чагылдырган И. Юзеев пьесаларын анализлаудан чыгып, түбәндәге нәтиҗәгә килергә мөмкин: 1970–1980 елларда татар драматургиясендә, традицион сюжетлы-композицион формалар белән беррәттән, хәрәкәтне оештыруның шартлы-метафорик ысулын актив куллану күзәтелә. Бу, нигездә, мифологик сюжетлар һәм образлар системасына мөрәҗәгать итү юлы белән ирешелә. Пьесаларның нигезенә кешенең үз-үзен һәм яшәеш мәгънәсен танып белү, халык язмышы, тарихи хәтер, милли әхлак белән бәйле проблемалар ешрак куела башлый. Пьесаларның төп үзенчәлеге шунда ки, аларда эчке дөньясы бай, югары әхлаклы һәм нык характерлы идеаллаштырылган милли герой алгы планга чыга. Туган җиргә, табигатькә, тарихи үткәнгә игътибарлы булу аның характерлы сыйфатына әверелә. Милли үзенчәлекләрне чагылдырган образ-символлар ярдәмендә төп идеянең тирәнлеге тәэмин ителә, яшерен эчтәлекне тапшыру мөмкинлеге тудырыла. Совет чоры әдәбиятына хас революцион романтизмнан аермалы буларак, төп игътибар гомумкешелек мәсьәләләренә, милли идеал булдыруга юнәлтелә, шул рәвешле дөньяның социаль картинасы тасвирыннан милли дөнья картинасы тасвирына күчү күзәтелә, бу исә татар халкының этник үзаңын формалаштыруга юнәлдерелгән драма әсәрләре иҗат итәргә мөмкинлек тудыра.

**Әдәбият**


*Ахмадуллин А.Г.* Татарская драматургия: история и проблемы. Казань: Татар. кн. изд-во, 2012. 511 с.

*Әхмәдуллин А.Г.* Күңелләрне уятыр: Хәзерге татар драматургиясе: монография. Казан: Мәгариф, 2007. 242 б.

*Вагапова Л.Н.* Поэтика драматургии Ильдара Юзеева: автореф. дис. … канд. филол. наук. Уфа, 2011. 26 с.

*Давлетшина Л.Х.* Мифологизм в татарской прозе конца XX – начала XXI веков: автореф. дис. … канд. филол. наук. Казань, 2005. 22 с.

*Давыдова Т.Т., Пронин В.А.* Теория литературы: учеб. пособие. М.: Логос, 2003. 232 с.

*Денисова Т.Н.* Романтический герой русской драматургии 60-х гг. XX в. // Вестник Вятского государственного гуманитарного университета. 2013. № 2 (2). С. 90–92.

*Заһидуллина Д.Ф.* 1960–1980 еллар татар әдәбияты: яңарыш мәйданнары һәм авангард эзләнүләр: монография. Казан: Татар. кит. нәшр., 2015. 382 б.

*Йосыпова Н.* Илдар Юзеев // Татар әдәбияты тарихы: сигез томда [төз. Р.Ф. Рахмани]. Казан: Татар. кит. нәшр., 2014. 6 т.: 1960–1980 еллар / [фәнни мөх.: Д.Ф. Заһидуллина, Ә.М. Закирҗанов]. 2018. Б. 319–345.

*Миңнуллина Ф.Х.* Татар әдәбиятында трагедия жанры // Фәнни Татарстан. 2018. № 2. Б. 30–34.

*Мостафин Р.* Илдар Юзеев // Татар әдәбияты тарихы: алты томда. 6 т.: 60–90 еллар әдәбияты. Казан: Раннур, 2001. Б. 299–315.

*Мустафин Р.А.* Литературные портреты писателей Татарстана. Казань: Татар. кн. изд-во, 2006. 351 с.

*Ханзафаров Н.Г.* Татарская комедия (истоки и развитие). Казань: ФӘН, 1996. 266 с.

*Юзеев И.* Кыр казлары артыннан: пьесалар. Казан: Татар. кит. нәшр., 1980. 207 б.

*Юзеев И.* Шигъри трагедияләр / [төз. һәм кереш мәкалә авт. Л. Шәех]. Казан: Татар. кит. нәшр., 2019. 296 б.

***Шәрипова Алсу Сәмигулла кызы,***
*филология фәннәре докторы, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты директорының инновацион эшчәнлек һәм тышкы элемтәләр буенча урынбасары*

УДК 821.512.145

***Л.Р. Надыршина***

# ГАРИФ АХУНОВНЫҢ «ИДЕЛ КЫЗЫ» ДИЛОГИЯСЕНДӘ МИЛЛИ-ДИНИ КЫЙММӘТЛӘР

Ключевым фактором качественных изменений в татарской литературе 1960–1980-х гг. является преодоление идеологических рамок за счет актуализации национальной темы, возвращения к национальным традициям, поиска путей возрождения национальных художественных традиций и т.д. Авторы начинают вести диалог с читателем о важности сохранения языка и духовных традиций, значимости национальных ценностей в жизни татарского народа и красоте национальных обычаев и устоев. Примером такого произведения является дилогия «Идел кызы» («Дочь Волги») Гарифа Ахунова, где повествование о судьбе главных героев – деревенского муллы Габбаса и его дочери Нурии – тесно переплетается с раздумьями о судьбе татарского народа в целом. Опровергнув идеологические стереотипы о дореволюционном национальном бытии, автор раскрывает роль татарских религиозных деятелей в истории народа, показывает красоту национального бытия и важность сохранения духовных ценностей, транслирует идею деструктивности тоталитарного режима, искореняющего национально-религиозные ценности и традиции народа.

**Ключевые слова:** Гариф Ахунов, татарская литература, образ, идея, проблема, национальная картина мира.

The key factor of qualitative changes in Tatar literature of the 1960s and 1980s is overcoming ideological frameworks by actualizing the national theme, returning to national traditions, searching for ways to revive national artistic traditions, etc. The authors begin to engage in a dialogue with the reader about the importance of preserving language and spiritual traditions, the importance of national values in the life of the Tatar people and the beauty of national customs and the foundations. An example of such a work is the dilogy “Idel kyzy” (“Daughter of the Volga”) Garifa Akhunov, where the narrative about the fate of the main characters – the village mullah Gabbas and his daughter Nuria – is closely intertwined with thoughts about the fate of the Tatar people as a whole. Having refuted ideological stereotypes about prerevolutionary national existence, the author reveals the role of Tatar religious figures in the history of the people, shows the beauty of national existence and the importance of preserving spiritual values, translates the idea of the destructiveness of a totalitarian regime that eradicates national religious values and traditions of the people.

**Keywords:** Garif Akhunov, Tatar literature, image, idea, problem, national picture of the world.

1960–1980 еллар татар әдәбиятында башланган үзгәрешләрнең иң әһәмиятлеләреннән берсе – сүз сәнгатенең милли асылына кайтуы – реализм кысаларында иҗат ителгән әсәрләрдә милли геройлар, этнографик детальләр, халыкчанлык, милли психология сыйфатлары табылуда чагыла. Әдәбияттагы шушы үзенчәлек турында сүз алып барганда, Гариф Ахунов исемен дә атау зарур.

Әдәби мәйданга узган гасырның илленче елларында килеп, иҗатының башлангыч чорында төп игътибарын хезмәт кешесен данлауга юнәлдергән, чор өчен традицион булган уңай герой концепциясен нигез итеп алган язучы үзенең тәүге әсәрләрендә үк милли яшәешнең аерым якларына кагылып үтә. Мәсәлән, «Яшьлек яме» (1953–1955) повестенда, артык куертмыйча, сүз уңаеннан гына дип әйтерлек, ул татар телен саклау зарурлыгын ассызыклый, татар факультетындагы кыенлыклар хакында әйтеп уза, халкыбызның рухи мирасына ихтирам белән карарга өнди. Әсәрдә урын алган фольклор мотивлары, җыр-бию, риваятьләр повестьны милли бизәкләр белән баета. «Хәзинә» (1958–1962) романында исә язучы, татар авылларында нефть сәнәгате белән бәйле барлыкка килгән үзгәреш-яңалыкларны бер нәсел язмышы үрнәгендә ачып биреп, шушы нәселнең иң өлкән буыны вәкиле – милләт анасы архетибы югарылыгында тасвирланган йөзьяшәр Йөзлекәй карчык авызыннан рәсми идеология тарафыннан үсеш-алгарыш дәвере дип тәкрарланган заманның татар авылларына хас рухи-әхлакый кыйммәтләрне юкка чыгаруын, яшьләрнең үткәнгә, нәсел тарихына битарафлыгына китерүен әйттерә. Йөзлекәй карчыкның үлеме дә символик рухта кабул ителә һәм үткән традицияләрнең бетүе кебек аңлашыла.

Шул рәвешле, гомуми эчтәлеге идеологик кысаларда калса да, башка күп кенә татар әдипләре иҗатындагы кебек үк, Г. Ахунов әсәрләрендә дә совет әдәбиятында күләгәдә калып килгән милли яшәеш белән бәйле проблемалар, этнографик детальләр шактый урын ала, системаның, чор-вазгыятьнең милли кыйммәтләрне юк итүе хакындагы фикер тоемлана.

Узган гасырның 70 нче елларына таба инде Г. Ахунов иҗатында социалистик реализмның катгый кануннарыннан читләшү тенденциясе тагын да көчәя. Тарихка йөз белән борылуы, милли характерларга мөрәҗәгать итүе белән игътибарга лаек «Идел кызы» дилогиясе – шуның ачык мисалы.

1901–1934 елларны үз эченә алган беренче китапта автор XX йөз башында илдәге сәяси-иҗтимагый үзгәреш давылының шәхси фаҗигаларга китерүен сәнгатьчә ачып бирә, инкыйлабның милли көнитешнең табигый агышын бозуын, гасырлар буе татар халкының рухи үзәген хасил иткән кыйммәтләрне кире кагуын сурәтли. Үзәк герой буларак сурәтләнгән Габбас мулланың катлаулы һәм каршылыклы язмышы ил һәм милләт тарихы белән бер үремтәдә бирелә. Чыгышы белән ярлы гаиләдән булган Габбас мулла гомер буе хезмәт белән көн күрә, масаю, дини фанатизм, башкалар җилкәсендә көн күрү – аның өчен ят гамәлләр, хәзрәтнең яшәү мәсләге – текстта үз авызыннан әйтелгәнчә, *халыкка аң-белем таратып, дөньяга мәгърифәт нуры сибеп яшәү* [Ахунов, т. 2., б. 12]. XX йөз башындагы үзгәрешләргә нигез салучы алдынгы фикерле яшьләрнең дә күбесе нәкъ менә Габбас муллада белем алганнар. *Хөррият заманасы килә, татарның да күзе ачылырга тиештер бит инде...* [шунда ук, б. 32] – дип фикер йөрткән

дин әһеле үз кызын да русча укыта, аны заманча белемле итеп күрергә тели, җыр-бию белән шөгыльләнүен дә тыймый. Гомумән, Габбас мулла «халкыбызның бик күп милли сыйфатларын үзендә туплаган көчле рухлы, белемле, намуслы, хезмәт сөючән, итагатьле, сабыр холыклы милли характер» [Ганиева-Гыйниятуллина, 2015, б. 63] буларак сурәтләнә. Авыл халкы арасында ихтирамга лаек, тырыш, тирән фикерле бу шәхеснең яңа заманга ят булуы, йортсыз-җирсез калдырылуы, бигрәк тә система богауларыннан куркып калган кызы тарафыннан кире кагылуы совет чоры әдәбиятында һәрвакыт алсу төсләр белән сурәтләнгән инкыйлабның, асылда, шәхес фаҗигасына китерүен ачып бирә: *...пожардан соң мең бәла белән җиткергән соңгы йортын тартып алып, үзен мунчада яшәргә калдырулары, киңәш сорап калага баргач, Нуриянең аны караңгы чырай белән каршы алып, бүтән килеп йөрмәвен үтенүе Габбас мулланы тетрәтеп җибәрде. Шул минуттан башлап аның өчен дөньяда яшәүнең кызыгы бетте. <...> Карале, хикмәти Хода, Габбасның моңарчы күңелен нык итеп тоткан нәрсә икәү булган икән: берсе – кызы Нуриягә булган ышаныч, икенчесе – авыл халкының ихтирамын тою* [Ахунов, 2005, т. 2, б. 373].

Гомумән, Гариф Ахунов XX йөз башына хас дөнья сурәтен берьяклы гына тасвирлаудан читкә китә, геройларны ак-карага бүлү юлын сайламый, байлар, милли зыялыларның, дин эшлеклеләренең халык өчен кылган яхшылыкларын да санап үтә, аларны бер калыпка кына салып бәяләүне дөрес дип санамый. Мәсәлән, Габбас мулла фикерләре аша муллаларның өч төркемгә: шымчы (*Боларның указлары була, болар жандармерия идарәсендә хисапта торалар, болар авыл халкы арасында барган барлык хәлләрне охранкага җиткереп, хәбәр итеп торалар. Болар Аллаһның барлыгына һәм берлегенә ышанмыйлар, болар өчен кеше җанын кыю бер тиен дә тормый һәм болар моны Алла исеменнән, патша хәзрәтләре исеменнән эшләп килгәннәр* [шунда ук, б. 374]), шагыйрь *(Гасыр саен андыйлар булган: Габделҗәббар Кандалый, Утыз Имәни, Мәрҗани. Боларның укымышы зур. Болар кеше җанының матурлыгына ышаналар, болар, халыклары алга китсен, аңы үссен дип, гомер буе тырышалар; патша ялчылар аларны эзәрлекли, кайберсенең иманын сындыра, әмма шагыйрьлектән туктата алмый* [шунда ук]) һәм Габбас кебек гади авыл муллаларына (*Өченче төркемгә кергән муллалар халык өчен иң зур эшне эшләгәннәр: гомер буе балалар укытканнар, кара халыкны агартырга тырышып яшәгәннәр. Аларга казна акча түләми, алар патша хәзрәтләренең сөекле балалары түгел, мәгърифәткә булган ихтирам, башкаларга да дөньяны таныту хисе аларны алга әйдәгән* [шунда ук]) бүленүен әйтеп, ул совет әдәбиятында күп еллар тискәре типлар буларак сурәтләнгән дин әһелләренә берьяклы бәя бирүдән читкә китә. Совет чорында исемнәре татар тарихыннан сызып ташланган атаклы татар байларының да милли алгарыш идеяләре белән янучылардан булуын искәртә. Әйтик, максатына ирешүдә бернәрсәне дә, беркемне дә аямавы белән

яманаты чыккан Тәминдар Тураевның Зартугайда җәдиди мәктәп салдыруы, анда *булдыклы, белемле кеше тәрбияләргә ниятләве* [Ахунов, 2005, т. 2, б. 14], *Берләшергә кирәк, әфәнделәр. Мөселман кардәшләребезне цивилизациягә алып чыгарга кирәк* [шунда ук, б. 109], дип, татар халкының икътисади куәтен киң масштабка җәелдерергә хыяллануы һич тә идеология таләпләренә буйсынмый.

Уйланучан укучы вакыйгалар сөрешеннән, Габбас мулла һәм аның авылдашлары язмышы аша инкыйлабның милли алгарыш турындагы шушы хыялларга чик куюын, ата – улны, туган туганны сатар дәрәҗәгә җиткерүен, әхлакый кануннарның санга сугылмавына китерүен, милли кыйммәтләр системасында иң югары баскычның берсен биләгән буыннар арасындагы бәйләнешнең өзелүе инкыйлаб китергән иң олы фаҗига булуын аңлый. Туганы Габбас мулланы мыскылларга яраткан Наҗия, яңа җәмгыятьтә үз урынын табарга теләп, әтисеннән баш тарткан Нурия, кулаклаштыру, күмәкләштерү эшләрендә үз әтисен дә, Габбас мулланы да аямаган Солтан һ.б. образлар аша шушы ачы хакыйкать бөтен тулылыгы белән ачыла. Ахыр килеп, Нурия белән Солтан күргән сынаулар, фаҗигаларның бер (бәлки, иң төп) сәбәбе дә ата-ана фатихасын алмаудан, аларга каршы чыгудан түгелме, дигән уйлануларга да җирлек кала.

Романда татар халкының матди һәм рухи мәдәнияте белән бәйле этнографик детальләр әсәрнең миллилеген көчәйтә, язучы тарафыннан күпләп кертелгән милли интерьер сурәтләре, портрет сурәтләрендә тәфсилләп саналган кием-салым детальләре, халык яшәешенең аерылгысыз өлешен хасил иткән гореф-гадәтләр, хезмәт йолалары, мәдрәсәләрдә уку тәртибе, шәкертләр тормышыннан өзекләр, гаилә мөнәсәбәтләрен ачып биргән өлешләр, әкият-риваятьләр XX йөз башы татар милли дөнья сурәтен тергезә, гади җир кешесенең көндәлек яшәеш матурлыгын ачып бирә. Әсәр «мулла образын төп герой дәрәҗәсендә фаҗигалы тасвирлавы, үткән тормышның милли-матур агышын тергезүе, инкыйлабларга кешеләрнең гадәти көнитеш рәвешен җимергән, аң-акылларына фаҗигалы тәэсир ясаган вакыйга итеп каравы белән яңалык алып килә» [Заһидуллина, 2015, б. 237].

Романның икенче өлешендә вакыйгалар вакыты 1934–1944 еллар аралыгын үз эченә ала. Нурия язмышын үзәккә куеп, әдип аның ихтирамга лаеклы талантлы врач булып җитешүе, фәндә хөрмәт казануы, фән кандидаты дәрәҗәсенә ирешүе, докторлык диссертациясе өстендә эшләве, иңнәренә төшкән авыр сынауларны җиңә алуы турында сөйли. Героиняның характер буларак формалашуы шәхси фаҗигалар фонында бара: яшьлегендә, чор дулкынына ияреп, күңелен гомер буе бимазалаячак ялгышлык кылган – әтисен кире каккан, бала хәсрәте кичергән, ирен югалткан Нурия роман дәвамында гаҗәеп тирән сентименталь кичерешләргә сәләтле, әмма көчле рухлы татар хатын-кызы буларак ачыла. Әти-әнисеннән дин тәрбиясе алган, татар халкының әхлакый кыйммәтләрен: сабырлык, гаделлек, намуслылык, фидакярлекне кечкенәдән кальбенә сеңдергән татар кызының шун-

дый уңышка ирешүе, сынауларны эчке бер ныклык белән үтеп чыгуы укучыда ирексездән горурлык хисе уята.

*Дөньяның нинди генә фаҗигалары, нинди генә авырлыклары булмасын, караңгыдан яктыга чыгар өчен өй стенасына тәрәзә тишкән төсле, күңел юатырдай матурлыклары, гыйбрәтле хәлләре дә булгалый* [Ахунов, 2005, т. 3, б. 266], – дип уйлана тормыш сынауларын күп күргән Нурия. Гаилә, нәсел дәвамы, туганлык җепләрен саклау, башкаларга карата миһербанлы булу – менә шушы тәрәзәдән төшкән яктылык нурлары шулар. Романның икенче кисәгендә туганнар арасындагы җылы мөнәсәбәтләр, үзара ярдәмчеллек, кешелеклелек, аеруча бер җентеклелек белән сурәтләнә, тормыш нинди генә борылышларга китерсә дә, ялгышу-хаталарга бай булса да, кеше җанына җылылыкны якыннары, кан туганнары, кардәш-ыруында таба ала, туган туганны һәрвакыт аңлый, кичерә, дигән фикер кызыл җеп булып сузыла. Г. Исхакыйның «Остазбикә»сендәге Сәгыйдә чалымнары сизелгән, *гаять дәрәҗәдә түзем, кайгы-хәсрәтне башкалар башына аудармый торган сабыр җанлы, үз гомерендә читләргә күз яшь күрсәтмәгән, ничәмә-ничә буыннан килгән затлы нәселенә тап төшерүдән курыккан* Шәмсениса абыстайның Нурия өчен җан атып торуы, Габбасның кече хатыны Хәнифәнең көндәше турында ялгышып та начар сүз әйтмәве, Нуриягә һәрвакыт җылы карашлы булуы, Нуриянең сеңлесе Шәфика, энеләре Мәхмүт белән Әхмәтне туганнарча өзелеп яратуы, Солтанның туганнан-туган энесе Әхнәфне үз энесыдәй якын күрүе, Әхнәфнең эти-әнисе Мөхәммәтша агай белән Фәтхениса җиңгиләрнең гади авыл кешеләренә хас булганча садәлеге, киң күңеллелеге, юмартлыгы, нинди авыр, кытлыклы сугыш елларында балалары белән авылга фельдшер булып эшләп торырга кайткан Нурияне *рәхәтләнеп бер чүкердәшеп кыш чыгыйк әле* дип өйләренә сыендыруы – болар барысы да татар халкына хас күркәм сыйфатлар булып күңелгә уела.

Яшьлегендә, артык тирәнгә төшеп уйламыйча, этисеннән дә баш тарткан, әмма гомер буе шуның үкенечен тоеп яшәгән Нуриянең күңеленә иң кыен чакларында, җаны сызланганда, туган авылы – Зартугайга ашкынуы да әдәбияттагы мәңгелек кайту мотивын яңарта, туган нигез, нәсел җепләрен саклау, яшәешнең асыл кыйммәтләре турында уйландыра. Авыл халкының яхшылыкны онытмавы, кешегә игелеклелек ноктасыннан бәя бирүе, әхлакый кануннарга буйсынып яшәве аның бөтен малы таланган Габбаска казанын кире сатып алып китереп бирүендә, яңа чор хакимнәреннән яшереп булса да, сәдакадан өлеш чыгаруында, *бер мыскал ризык исәптә чагында Шәфиканы укытып кайтарган*, сугыштан имгәнеп кайтканнарны дәвалаган Нурияне олылавында, аны хөрмәтләп озатуларында һ.б. ачык чагыла.

Яңа система тарафыннан кире кагылган, онытттырылган кебек тоелса да, татар кешесенең канында дини тәрбия орлыклары: олыны олы итү, намуслылык, гаделлек, сабырлык, язмышка буйсыну, туганлык җепләрен өзмәү һ.б. беркайчан да югалмый. Менә шул

милли-дини кыйммәтләр – кеше холкын формалаштыруда төп этәргеч нокта, җәмгыятьне кешелек баскычында тотучы бер үзәк ул. *Ә шулай да Ходай бар дөньяда. Ходай ул – кешенең намусы. Намус бетмәсә, дөньяда яшәп була* [шунда ук, б. 265], – дип уйлана инде үзен материалист дип санаган Нурия. Нәкъ менә шушы канда, җанда яшәгән дини тәрбия, иман нуры Нурияне, әҗәле җиткән әнисенә «Ясин» чыгарга, этисе Габбас рухына, кешедән яшереп булса да, Коръән укытырга этәрә дә.

Халыктан шушы әхлакый таяныч ноктасын тартып алган, дәһрилекне әләм иткән яңа система Бүре Бадул, Нух Галләм кебекләрнең кулын чишә, Аллаһ җәзасыннан курыкмаган куркыныч кешелек җәмгыяте барлыкка китерә, күпгасырлык рухи кыйммәтләр алышына, кешеләр үзләре төзегән системаның колына әверелә. Шул рәвешле, беренче өлештә совет чоры әдәбиятында озак еллар көчләп тагылган XX йөз башы милли дөнья сурәте хакындагы миф җимерелсә, романның икенче өлешендә социалистик җәмгыять турындагы идеологик миф кире кагыла, тарихның канлы, фаҗигалы дәвере торгызыла, системаның кеше язмышларын җимерү, колга әйләндерү, яла-ялган ярдәмендә ныгуы ачып бирелә. Шушы фонда милли-дини кыйммәтләрнең кешелекне саклап калачак асыл хасиятләр булуы турындагы яшерен фикер кызыл җеп булып сузыла. Менә болар барысы да Г. Ахуновның «Идел кызы» дилогиясенең татар әдәбиятындагы әһәмиятле ролен, яңалыгын билгелиләр дә.

**Әдәбият**

*Ахунов Г.* Идел кызы: роман. Беренче китап // *Ахунов Г.* Сайланма әсәрләр: 5 томда. 2 т. Казан: Татар. кит. нәшр., 2005. 14 б.

*Ахунов Г.* Сайланма әсәрләр: 5 томда. 3 т. Роман. Казан: Татар. кит. нәшр., 2005. 266 б.

*Ганиева-Гыйниятуллина А. Ф.* Гариф Ахуновның соңгы чор иҗатында яңа эзләнүләр // Фәнни Татарстан. 2015. № 3. Б. 63.

*Заһидуллина Д.Ф.* 1960–1980 еллар татар әдәбияты: яңарыш мәйданнары һәм авангард эзләнүләр: монография. Казан: Татар. кит. нәшр., 2015. 237 б.

***Надыршина Ләйсән Рәдиф кызы,***
*филология фәннәре докторы, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма мирас үзәге өлкән фәнни хезмәткәре*

УДК 821.512.145

***А.Ф. Ганиева,***
***И.Ш. Ганиев***

# МИРСӘЙ ӘМИР СӘНГАТИ ДӨНЬЯСЫНДА ГЕРОЙҺӘМ ПРОБЛЕМАТИКА

Статья посвящена изучению творчества видного представителя татарской литературы советского периода Мирсая Амира. Автор статьи рассматривает в плоскости героя и проблематики произведения, занимающие важное место в творчестве писателя, но малоизвестные общественности: роман «Командир», повести «Ничтожество» и «О вчерашнем – сегодня». Автор приходит к выводу, что эти произведения М. Амира отвечают требованиям советского времени и ставят общечеловеческие ценности выше всего, отодвигая идеологию на второй план.

**Ключевые слова:** татарская проза, Мирсай Амир, главный герой, роман, повесть.

The article is devoted to the study of the work of Mirsai Amir, a prominent representative of Tatar literature of the Soviet period. The author of the article examines works that occupy an important place in the writer’s work but are little known to the public of the hero and the problematic: the novel “Commander”, the novella “Insignificance” and “About yesterday – today”. The author comes to the conclusion that these works by M. Amir meet the requirements of the Soviet era and put universal values above all, pushing ideology into the background.

**Keywords:** Tatar prose, Mirsai Amir, the main character, novel, novella.

Мирсәй Әмир – совет чоры әдәбиятының күренекле әдипләреннән берсе. Аның башлангыч чор иҗаты 1920–1930 елларга туры килә. Ул үзенең шаян, җор телле «Мөстәкыйм карт йокысы» кебек хикәяләре, пейзаж остасы буларак таныткан «Агыйдел» повесте, чорның мөһим мәсьәләләрен драматик кискенлектә күтәргән «Миңлекамал», «Тормыш җыры» кебек драмалары, киң полотнолы мавыктыргыч вакыйгаларга бай «Саф күңел» роман-дилогияләре белән безгә яхшы таныш. Әлеге әсәрләр үз чорында татар совет әдәбиятының йөзен билгеләделәр. Шул ук вакытта язучының иҗатында мөһим урын тоткан, әмма җәмәгатьчелеккә аз билгеле әсәрләре дә бар.

М. Әмир татар әдәбиятында хәрби теманың аз яктыртылуын искә алып, гади татар авылыннан чыккан егетнең командир дәрәҗәсенә ирешүен, характеры ничек чыныгуын, гомумән, аның катлаулы тормыш юлы турында зур күләмле әсәр язарга алына. Әлеге «Командир» дип атаган романының бер кисәге 1934 елда аерым китап булып басылып та чыга. Әсәр әдәби җәмәгатьчелектә каршылыклы фикер тудырганлыктан, ВЛКСМның Татарстан Өлкә комитеты җыелышында махсус тикшерелә, соңрак фикер алышу «Совет әдәбияты» журналында дәвам итә.

Роман төп герой Сәүбанның армиягә алыну хәбәре белән башланып китә. Әсәрнең күп өлешендә аның авырлыкта үткән балачагы, армиягә китү алды көннәре вакыйгалары сурәтләнә. Автор җанлы күренешләр, оста тотып алынган аерым детальләр аша утызынчы еллар татар авылы картинасын тудыра. Романның дөньяга чыгуы совет язучыларының Беренче съездында социалистик реализм методы рәсми кабул ителгән вакытка туры килә (1934).

М. Әмирнең «Командир» романын да соцреализм кысаларыннан чыгып бәяләү күзгә ташлана. Тәнкыйтьчеләр (нигездә, Латыйф Җәләй һәм Мәхмүд Максуд) [Җәләй, 1934; Максуд, 1935] романдагы «кимчелекләрне» язучының «политик ялгышуыннан» күрәләр. Алар, беренче чиратта, 1928–1929 еллар авылы фоны дөрес күрсәтелми, совет властеның йогынтысы сизелми, дип белдерәләр. Икенчедән, Кызыл Армиянең артык караңгы бирелүен, капитаннарының да дөрес сурәтләнмәвен билгелиләр. Шулай ук әсәрдә интернационализмның чагылмавы кимчелек итеп карала, ә инде командир Моратовның милли полк турында хыялланулары М. Әмирнең милли мәсьәләне «ялгыш аңлавы»ннан дип аңлатыла. Кыскасы, «Командир» романының авторы тормыш диалектикасын аңламауда һәм әсәрендә партиячелекне чагылдырмауда гаепләнә. Чынлыкта, Ф. Галимуллин билгеләп үткәнчә, «сәнгатьчә дөреслеккә ирешүдә әһәмиятле баскыч булган әлеге роман – М. Әмирнең характер мантыйгы буенча язылган иң уңышлы әсәрләренең берсе» [Галимуллин, 2004, б. 33]. Кызганычка каршы, әлеге тар идеологик кысалар сәнгать әсәрен бәяләүдә үкенечле хаталануларга китерде, шуның нәтиҗәсендә язучының иҗади мөмкинлекләрен чикләде.

Сугыш чоры иҗатын җиңүгә тирән ышаныч белдереп, романтик-оптимистик рухта язылган «Тагын да зуррак бәйрәмгә кадәр» хикәясе (1941) белән башлап җибәргән М. Әмир алга таба сугыш афәтен тирәнрәк аңларга һәм аны тизрәк укучыга җиткерергә омтыла. Шуңа да бу дәвердә күбрәк тирән хис һәм көчле фикер белән бердәй сугарылган публицистик-агитацион характердагы очерк, фельетоннар, кыска комедияләр, хикәяләр языла. Аларда кешенең гайре табигый шартларда үз-үзен тотышына игътибар бирелә, сугыш Ватан һәм аерым шәхес алдына килгән әхлак вә намус сынавы буларак карала. Хикәяләрдә тыныч тормышның гүзәл күренешләре дәһшәтле сугышка каршы куела. «Курай» (1943) очеркында һәм «Сыерчык» (1943) нәсерендә әсәрләрнең исеменә үк чыгарылган образлар – сугышның кирәксез һәм коточкыч күренеш булуын ачу өчен кулланылган махсус символик детальләр. Сугыш – сәнгатьнең, гүзәллекнең капма-каршысы. Алар янәшәсендә сугыш фаҗигасы тагы да ныграк чагыла.

М. Әмирнең «Җан көеге» (1969) повесте башка әсәрләреннән хикәяләү стиле һәм сурәтләнгән тормыш материалының үзгә булуы белән шактый нык аерылып тора. Ул 1969 елда языла, әмма берничә елдан соң гына, анда да язучының үҗәтлеге аркасында гына

басылып чыга. Моңа кадәр Бөек Ватан сугышына багышлап иҗат ителгән әсәрләрдә сугышчан батырлыклар сурәтләнсә, М. Әмирнең, беренчеләрдән булып, дезертир образын үзәккә куеп язуы ул заманда чын мәгънәсендә кыю адым була. Тик шунысы үкенечле: В.Г. Распутинның шул ук темага язылган «Живи и помни» әсәре тәүге тапкыр 1974 елда «Наш современник» журналында басыла, һәм шундук киң җәмәгатьчелек тарафыннан югары бәяләнеп, 1977 елда СССРның Дәүләт премиясенә лаек була. Тема, сюжет, идея ягыннан гына түгел, сәнгатьчә эшләнеш җәһәтеннән дә бу ике әсәрнең охшаш яклары бик күп. Аерма милли җирлектә һәм сугыштан качып кайткан ирләрнең хатыннары Хәтирә белән Настёнаның гражданлык хисләрендә генә. «Җан көеге» әсәре, «Живи и помни»дан берничә ел алданрак язылып та, үз вакытында тиешле бәя ала алмый, өстәвенә аның авторы татар халкына яла ягуда гаепләнә. Чынлыкта М. Әмирнең әлеге повесте әдәбиятта сугыш темасын яңача ачкан югары дәрәҗәдәге сәнгать әсәре иде. Аның тематик яңалыгы белән бергә, сугышны фәлсәфи-психологик, әхлакый-эстетик яктан күрергә һәм бәяләргә омтылуы да зур әһәмияткә ия булды.

Повестьта вакыйгалар кырык беренче елның көзендә бара. Йөрәккә шом салырлык җилле-яңгырлы төн. Каенана белән килен ятарга җыеналар. Яшь хатын Хәтирә, күптән түгел генә сугышка киткән ирен сагынып, беркатлы гына әйтеп куя: «И-и, хәзер шушында Камәретдин кайтып керсәе…» [Әмир, 1972, б. 149]. Дөньяның ачысын-төчесен күп күргән ана хупларга ашыкмый. «Исән булсын, хәере белән кайтсын» [Әмир, 1972, б. 159], ди. Чыннан да, ул төнне Камәретдин кайтып төшә, тик сөенеч белән түгел, үзен хурлыкка, якыннарын хәсрәткә салып – качып кайта. Ул, газиз кешеләре белән күрешеп тә тормыйча, печәнлеккә менеп китә. Көннәр суыткач, идән астында яшеренеп ята башлый. Анасы Сабира белән хатыны икәүләп аны кире китәргә үгетләп карыйлар, төрле кинаяле, төрткеле сүзләр әйтәләр, акылга килер, үз хатасын аңлар дип өметләнәләр.

Әсәрнең төп героинясы Хәтирә үтә катлаулы тормыш ситуациясендә кала. Ата-баба тәрбиясе, күңеле кушуы буенча ул беркайчан да ирен сатмаячак, әмма авылдашлары, туганнары, якыннары – бөтен ил халкы авыр сугыш көннәре кичергәндә, үзләренең бөтен егәрләрен, көчләрен, гомерләрен биреп, ил азатлыгы өчен көрәшкәндә, ирен идән астында качырып асравы аңа коточкыч авыр була. Шуңа да алар (каенанасы белән) үзләрен халык алдында гаепле саныйлар.

Сугышка кадәр яратышып матур яшәгән булсалар да, качып кайткан көненнән башлап, Хәтирәнең сатлыкҗан иренә карата күңеле суынганнан-суына бара. Повесть башында бирелгән дәртле мәхәббәт әсәр дәвамында көчле нәфрәткә әверелә. Җан көеге Камәретдин, куркаклыгы аркасында сугышка барып җиткәнче үк качып кайтып, әкренләп кешелек сыйфатларын югалта, кыргый хайван рәвешенә керә.

Повестьта ана бәхете мәсьәләсе дә тирән фәлсәфи планда карала. Улы сугыш кырында батырларча һәлак булган күрше карчыгы кайгысы белән бүлешеп чыгып киткәннән соң, Сабира: «Бәхетле ана!» дип көрсенеп куя. Моннан ана кеше өчен тормышта баласының үлеменнән дә зуррак хәсрәт була ала икән, дигән гыйбрәтле нәтиҗә чыга.

Сугыш трагедиясен чагылдырган әсәрләр арасында «Җан көеге» повесте проблеманың тирәнлеге, характерларның халыкчанлыгы белән аерылып тора. Кеше ил җитәкчеләрен, үзе яшәгән иҗтимагый-сәяси формацияләрне кабул итмәскә, кире кагарга да ирекле, әмма аның туган илен, халкын сатарга хакы юк. Хаталанып яки куркып ясаган ялгыш адым да халкың һәм якыннарың беркайчан гафу итмәслек зур кайгы булып әйләнеп кайтырга мөмкин. Автор шул турыда уйлана һәм укучыны да уйланырга чакыра.

Билгеле булганча, 1950 еллар уртасыннан башлап, милли әдәбиятларда, шулай ук рус әдәбиятында мемуар әдәбият үсеш ала. Бу бигрәк тә илдәге «җепшеклек чоры» сәясәте белән бәйле. Революция дәверендә әдәбиятка килгән каләм әһелләре үткәнгә карата үз карашларын җиткерергә телиләр. Гадәттә автобиографик формага катлаулы гомер юлы үткән, әдәбиятта үз йөзен булдырган язучылар мөрәҗәгать итә. М. Әмир дә «Без бәләкәй чакларда» повестен җитмеш яшендә иҗат итә, калган «Үсә төшкәч», «Казан» бүлекләрен тагы да соңрак яза. Автор аларны ун кисәк итеп эшләргә планлаштыра, тик повестьның өченче кисәген дә тәмамларга өлгерми. (Язучы 1980 елның 1 июнендә вафат була.) Татарстан китап нәшрияты, әдипнең тууына 95 ел тулу уңаенннан, бу өч повестьны «Кичә турында бүген» исеме белән бастырып чыгара.

Язучы керештә үк «фәкать тормышта булган фактик материалларга нигезләнүен», үз чоры авылы тормышының «үзенә хас йолалары, кием-салым, йорт җиһазлары, эш кораллары, якын киләчәктә ерак тарихка әйләнеп калу ихтималын күздә тотып, этнографик детальләргә дә күбрәк урын бирүен», стиль ягыннан да «иркен кылануын» [Әмир, 2002, б. 5] әйтеп куя. Трилогиянең беренче кисәгендә Мирсәяфнең авыр да, катлаулы да, шул ук вакытта кызыклы һәм гыйбрәтле дә балачагы сурәтләнә. Ата-ана җылысын тою, сабый чакның онытылмас хатирәләре, беренче сабак, мавыктыргыч уеннар нечкә психологизм һәм җиңелчә юмор белән язылган. Хәтта дәһшәтле егерме беренче елгы ачлык вакыйгаларын сурәтләгәндә дә, язучы махсус тәэсир итү чараларын эзләми. Унике-унөч яшьлек Мирсәяф, әтисе, әнисе, туганнары үлеп беткәч, бертуган Мәрьям апасы белән генә кала. Балалар йортында үлгән энесенең мәетен чанага салып алып кайту күренеше, аклар атына йөк төяп алып киткәч, малын кулыннан ычкындырмаска тырышып күргән михнәтләре, әнисе белән зелпе куагына баргандагы авырлыклар, балалар йортындагы куркыныч төннәр – берсе дә гадәти хәлләр түгел. Ләкин хикәяләүче герой язмышына зарланмый; үзе белән аралашкан һәр кешегә ихтирам белән каравы, якташларын

яхшы яктан гына күрергә теләве, еллар үтүгә карамастан, язучы күңелендә туган ягына – Башкортстанга – чиксез мәхәббәте саклануын күрсәтә.

Әсәр героенда ике «мин» берләштерелгән, берсе – бала Мирсәяф булса, икенчесе – өлкән Мирсәй Әмир. Бу аеруча дингә мөнәсәбәттә ачык чагыла. Әсәрдә совет власте алып барган сәясәтнең кеше күңеленә сеңгән иманны какшатуы ачык чагыла. Беренче кисәктә сабый күңеленә сеңгән иман нуры һәртөрле дингә каршы чаралардан саклап килә. Икенче кисәктә герой, Стәрлетамак һәм Авыргазы чорларында заман шаукымына ияреп, үзен атеистик карашка ышандырырга тели. Ә өлкән «мин»нең исә фикере мондый: «Тора-бара барыбер аңладык: дин ул, теге вакытта без уйлаганча, ярлыларны изү өчен байлар тарафыннан юри уйлап чыгарылган гади карачкы гына түгел, аның катлаулы тарихы бар икән. Дәверенә карап, кешелек җәмгыятенең үсешен күрсәткән чаклары да булган. Хәзерге көндә дә аңардан аерылып бетә алмаучылар бар икән, кемнәр өчендер ул җан азыгы булуда дәвам итә икән, димәк, аның әле һаман да тиешенчә ачылып бетмәгән серләре бар» [Әмир, 2002, б. 240].

«Казан» – «Кичә турында бүген» автобиографик трилогиясенең соңгы кисәге. Ул – М. Әмирнең Казан чоры, ягъни сәнгать училищесында уку, күп кенә күренекле кешеләр белән аралашу, язучы буларак җитлегү дәвере. Монда XX гасырның 20 нче еллары азагында башкаладагы әдәби мохит, мәдәни тормышның үзәгендә кайнаган сәнгать әһелләре белән якыннан танышырга мөмкин. Холкына хас булганча, салмак агышлы ышандыргыч тел белән әдип, үз гомере мисалында, халык тарихының бер дәверен чагылдырырга омтыла.

М. Әмир әдәби тәнкыйть өлкәсендә дә актив әдипләребезнең берсе буларак танылa. Аның тәнкыйте дә, иҗаты кебек, социалистик реализм принципларына нигезләнә, әдәбиятның партиялелеген яклый. Тик шунысы әһәмиятле: «Идеялелек әдәби әсәрнең художество кыйммәтенә зыян китерү исәбенә бирелергә тырышыла икән, андый әсәрнең әдәбият өчен дә, халык өчен дә, партия өчен дә кирәге шулкадәр» [Әмир, 1971, б. 14] , – дип яза ул.

М. Әмир – агымга кире йөзгән, я булмаса аңа параллель иҗат иткән язучы түгел. Ул – илдәге сәясәтне чын күңеле белән кабул иткән, аның уртасында кайнаган, башкаларны да үзе ышанган идеалга өндәгән һәм үз кыйбласына тугры калган әдипләребезнең берсе. Әсәрләре совет чоры таләпләренә җавап бирсә дә, аның геройлары милли җанлы татар кешеләре булуы белән кадерле. Язучының гомумкешелек кыйммәтләрен бар нәрсәдән өстен куюы идеологияне икенче планга калдыра. Нәфис сүз сәнгатенең түмен тоеп, халкыбызның гуманистик традицияләренә нигезләнеп иҗат ителгән М. Әмир әсәрләре татар әдәбияты хәзинәсендә үзенә лаеклы урынны биләп тора.

**Әдәбият**

*Әмир М.* Без бәләкәй чакларда // Кичә турында бүген: автобиографик трилогия. Казан: Татар. кит. нәшр., 2002. Б. 7–231.

*Әмир М.* Җан көеге // Исеңдәме... Казан: Татар. кит. нәшр., 1972. 149 б.

*Әмир М.* Үзебез турында. Әдәби тәнкыйть мәкаләләре, чыгышлар. Казан: Татар. кит. нәшр., 1971. 199 б.

*Әмир М.* Үсә төшкәч // Кичә турында бүген: автобографик трилогия. Казан: Татар. кит. нәшр., 2002. Б. 233–316.

*Галимуллин Ф.* Реализммы, романтизммы? // Табигыйлеккә хилафлык. Казан: Татар. кит. нәшр., 2004. Б. 32–33.

*Җәләй Л.* Киң җәймәдәге таплар // Совет әдәбияты. 1934. № 9. Б. 81–89.

*Максуд М.* Тагын «Командир» романы турында // Совет әдәбияты. 1935. № 7. Б. 85–89.

***Ганиева Айгөл Фирдинат кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының әдәбият белеме бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре*

***Ганиев Илнур Шәһит улы,***
*Казан дәүләт мәдәният институтының халык иҗатын өйрәнү һәм музыкаль белем бирү кафедрасы өлкән укытучысы*

УДК 821.512.145

***Н.Ш. Насыйбуллина***

# ЗӘКИ ЗӘЙНУЛЛИН ШӘХЕСЕ
# ҺӘМ ТАТАР ӘДӘБИЯТЫ

В статье анализируется жизнь и творчество татарского писателя конца XX – начала XXI века – Заки Зайнуллина, основные темы, стиль и язык произведений. Творчество писателя представляет значительный интерес для современного читателя, так как оно дополняет огромный пласт татарской литературы. Произведения, характеризующиеся глубокой психологической проницательностью и обнажением моральных противоречий, оставили неподражаемый след в национальной литературе и продолжают быть актуальными до сегодняшнего дня. В них изображается действительность, повседневность, в которой проходит наше бытие, но сквозь неё просматрвается совершенство жизни, к которому мы стремимся.

**Ключевые слова:** татарская литература, Заки Зайнуллин, общество, личность, нация.

The article analyzes the life and work of the Tatar writer of the late 20th – early 21st centuries – Zaki Zainullin, the main themes, style and language of his works. The writer's work is of significant interest to the modern reader, as it complements the huge layer of Tatar literature. Works characterized by deep psychological insight and exposure of moral contradictions have left an inimitable mark on national literature and continue to be relevant to this day. They depict reality, everyday life, in which our existence passes but through it we can see the perfection of life to which we strive.

**Keywords:** Tatar literature, Zaki Zainullin, society, personality, nation.

Зәки Лотфулла улы Зәйнуллин (1933–2021) – татар әдәбияты һәм мәдәнияте тарихында тирән эз калдырган олы шәхес. Җәмәгать эшлеклесе, милләт киләчәген кайгыртып иҗат иткән әдип. Милли азатлык хәрәкәтенә зур өлеш керткән көрәшченең иҗаты иҗтимагый фикер тарихында лаеклы урынын алды. Тирән эрудицияле әдип әлеге өлкәләрнең һәркайсына яңалык өстәп кенә калмады, туры сүзе белән әйдәп баручы да булды. З. Зәйнуллинның милли образы, бай һәм катлаулы тормыш юлы, сәяси һәм иҗтимагый эшчәнлеге роман-повестьларында калку гәүдәләнеш тапты. Әдәби әсәрләре, бай публицистикасы XX гасыр – XXI гасыр башында яшәгән һәм иҗат иткән бик күп шәхесләр хакында биографик мәгълүмат бирүе белән дә кыйммәтле булды. Драма әсәрләре төрле театрларда куелды.

Зәки Лотфулла улының язмышы һәм иҗаты чор һәм аның иң мөһим күренешләре белән тыгыз бәйләнештә үрелеп барды. Язучы заман таләпләренә җавап биреп, сәнгатьнең яңа тенденцияләрен кабул итеп, шул ук вакытта кире кагып, үз фикерләрен халыкка җиткерү

максаты белән иҗат итте. Ул туган халкының, азатлык хәрәкәте аша, яңа тормышка омтылышын, шуның өчен көрәшен, шул максатка ирешү юлындагы өметләрен, алдану-фаҗигаларын үзенең җәмәгать эшчәнлегендә, әдәби иҗатында, әсәрләрендә гаять тулы һәм тирән, бөтен катлаулылыгы һәм каршылыклары белән чагылдырды.

З. Зәйнуллин феноменын барлыкка китерүдә катнашкан бик күп мөһим факторлар тезмәсендә аның туган җиренең, нәсел-чыгышының, гаилә тәҗрибәсенең, татар мәктәбендә алган белем дәрәҗәсенең һәм ул үткән тормыш университетларының роле гаять зур. З. Зәйнуллин характерындагы бик күп сыйфатлар – әдиплек, хәрбилек, галимлек, мөгаллимлек сәләте әти-әнисеннән күчкән, әби-бабаларыннан ук килгән.

Каләм иясенең нәсел тамырларын тикшергәндә һәрвакыт туган җиренең кайда, нинди булуы хакында сораулар туа. Әдипнең дөньяга килгән һәм тәрбияләнеп үскән урыны – татар әдәбиятына талантлы язучыларны мул биргән бәрәкәтле Башкортстан туфрагы, заманында мәшһүр мәдрәсәләре белән дан тоткан Стәрлебаш авылы. Татар авылының бай тарихы, гүзәл табигате булачак язучының рухи дөньясына, киң күңелле, хисләргә бай, шул ук вакытта кырыс холыклы шәхес булып формалашуына зур йогынты ясаган. Туган җиренең җанга якын, элек-электән изге саналган истәлекле урыннары бөтен иҗат гомере дәвамында күңелен дәртләндереп, рухландырып, туендырып, әсәрләрендә чагылыш тапкан.

Олы шәхеснең гомер һәм иҗат юлы күпмедер дәрәҗәдә үз халкының язмышын чагылдыра. Язучының озын тормыш юлында, төрле борылмаларга юлыккан гаять үзенчәлекле, урыны-урыны белән каршылыклы, бай иҗатына Стәрлебашның, татар халкының бер гасырлык рухи язмышы сыйган. Атаклы Стәрлебаш мәдрәсәсе мөдәррисе Мөхәммәдшакир Тукаевның 1899 елда Казанда басылган һәм бер нөсхәсе З. Зәйнуллинның үз китапханәсендә сакланган «Тарихе Стәрлебаш» китабындагы тарихи материаллар әдипнең «Эстәрлебаш мәдрәсәсе» дип исемләнгән зур гына мәкалә-очеркында, «Агыйделнең аръягында» (1998) күләмле роман-кыйссасын язганда киң файдаланыла. З. Зәйнуллин тормышының иң зур вакыйгалары итеп Стәрлебаш тарихын тасвирлаган «Эстәрлебаш мәдрәсәләре», «Эстәрлебаш дарелфөнүне», «Тукаевлар» әсәрләрен санарга кирәк.

Стәрлебашның борынгыдан мәгърифәтле җир булуы тарихта яхшы мәгълүм. XIX гасырга кадәр ике мең кешесе булган бу авылда 16 бинадан торган мәдрәсәләр эшләгән. Биредә укыткан һәм укыган зыялыларның тирә-якта яшәгән халыкларның аң-белемен үстерүгә йогынтысы зур булган. Стәрлебаш мәдрәсәсен тәмамлап, халыкка мәгърифәт нуры тараткан күренекле шәхесләр – Габдерәхим Утыз Имәни (1754–1834), Гали Чокрый (1826–1889), Мифтахетдин Акмулла (1831–1895), Гали Рафикый (1890–1944), Төхвәт Янәби (1894–1938) үзләренең шигырь һәм поэмаларында белем, акыл, кешелеклелеккә

дан җырлап, әхлакый камил шәхес образын тудырсалар, Әбелмәних Каргалый (1782–1826), Һибәтулла Салихов (1794–1867), Шәмсетдин Зәки (1825–1865) иҗатта Урта гасырлар дини-суфичылык әдәбияты традицияләрен дәвам итәләр. XX гасыр башында мәгърифәт үзәгенең туздырылуы, кыйммәтле язма ядкәрләрнең юк ителүе халыкның иҗат көченә зыян китерә. Совет хакимияте ныгып урнашу дәверендә әдәбият «сүнү»гә йөз тота. Яңа идеалларга дан җырларга, элеккеләрен фаш итәргә әзер булган язучылар буыны күренми. Әмма ничек кенә булмасын, татар сүз сәнгате яшәүдән туктарга теләми. XX гасырның икенче яртысында әдәбият мәйданына Зиннәт Галимов (1922–1983), Фәйзи Гомәров (1926–2002), Равил Шаммас (1930), Зәки Зәйнуллин (1933–2021), Әдхәт Синугыл-Куганаклы (1935–2004), Рәфкать Рысаев (1939), Равил Гөзәеров (1942–2021), Хисаметдин Исмәгыйлев (1953) киләләр. Алар татар халкының мөһим ихтыяҗларына җавап бирүгә, рухи тормышны агартуга зур өлеш кертеп, иҗатларында милләт тарихы, үткәннең һәм бүгенгенең бәйләнеш-мөнәсәбәте, кешенең тормыштагы һәм җәмгыятьтәге урыны һәм башка фәлсәфи фикерләргә киң урын бирәләр. Ә. Синугыл (Куганакбаш авылы), З. Зәйнуллин (Стәрлебаш авылы), Р. Гөзәеров (Өч-Әсән авылы) – Башкортстан җирлегендә туып, иҗат биографиясен Казан, Үзбәкстан, Кырым, Украина, Латвия, Казакъстан белән бәйләгән шәхесләр. З. Галимов (Бузатбаш авылы), Ф. Гомәров (Хәлекәй авылы), Р. Шаммас (Хәлекәй авылы), Р. Рысаев (Тәтер-Арслан авылы), Х. Исмәгыйлев (Гөлем авылы) – Башкортстанның үзендә яшәп иҗат итүче әдипләр. Аларның иҗатын колачлап алган тема – туган җиргә дан җырлау. Үзгәрешләрне тоеп, борчылып, үз йөрәге аша кичереп яшәүче, бар өлкәдә дә иҗади сәләткә, чиктән тыш талантка ия, кыю фикерле, тәҗрибәле һәм үз көченә тулысынча ышанган З. Зәйнуллин иҗаты барысыныкыннан да аерылып тора.

Булачак галим һәм язучы 1933 елның 10 июлендә Стәрлебаш авылында колхозчы гаиләсендә унберенче бала булып дөньяга килә. «Сөннәт белән кендек» хикәясендә ул: «Мин, 1933 елның июль аенда, коры елны, яланда, арыш урагында туганмын... Өмаһани әби, минем кендек әбисе булып, урак белән кискән минем кендекне», – дип яза.

Аның үсмер чагы сугыш елларына туры килә. Сугыш чоры балалары илебезнең чын патриотлары була. Һәм патриот булу алар өчен кеше булып яшәүне аңлаткан төп кыйммәт санала. Шуңа күрә «туган ил», «туган җир», «намус», «җаваплылык» кебек төшенчәләрнең аларның әхлакый йөзен билгеләп, шәхес булып өлгереп җиткәч, яшәеш кагыйдәсенә әйләнүе – табигый күренеш.

Язучының биографиясе бай. Сугыш алды елларында Ватанга, халыкка кирәкле кеше булып яшәү адәм баласының җирдәге төп бурычы булып күзаллана һәм алар гомер буе шушы хакыйкатьне исбатларга тырыша. З. Зәйнуллин да Стәрлебаш татар урта мәктәбен

тәмамлагач, башта колхозда, аннары Куганакбаш җидееллык татар мәктәбендә математика, физика, рус теле укыта.

1952 елда гаскәри хезмәткә чакырылып, Иркутск (Өркет) шәһәрендә өчьеллык хәрби авиация-техника училищесында укый. Бу хакта ул: «Мин авылдан «бәхет эзләп» зимагурлыкка чыгып киттем. Гаиләдә ярлылык, фәкыйрьлек, ярымачлык хөкем сөрә. Гражданнар сугышы елларында Дутов казаклары приклад белән сугып, әтинең аркасын сындырганнар. Ул авыр эш башкара алмый, аңа 66 яшь. Мин шул елның җәен офицерлыкка уку исәбе белән ерак Иркутск каласын эзләп чыгып киттем», – дип яза «Чалатай бабай» хикәясендә.

1958 елда, хәрби белемен арттыру теләге белән, Ригадагы Югары хәрби ракета инженерлары училищесына янәдән укырга керә һәм 1963 елда аны уңышлы тәмамлый. Анда укыган еллары турында ул «Тамаша» исемле хикәясендә: «Ригада югары хәрби ракета училищесында инженерлыкка укып йөрим. Өлкән лейтенант. Унбер квадрат метрлы бүлмәдә аена 300 сум түләп торабыз», – дип искә ала.

1970–1978 елларда аның әдәби иҗат өлкәсендәге таланты ачылып китә. З. Зәйнуллинның беренче әдәби әсәрләре нәкъ менә шул Серпухов шәһәрендә языла, үз заманы өчен актуаль проблемаларны күтәргән тәүге хикәясен 1978 елда сатирик «Чаян» журналы бастырып чыгара.

1981 елда З. Зәйнуллин полковник дәрәҗәсен ала. Шәхес буларак формалашуында үзе үскән вакыттагы Стәрлебаш мохитенең, бигрәк тә Абдулла агасының йогынтысы зур булуын ассызыклый. 1991 елда «Идел» журналында аның «Полковникны озату» повесте (Н. Акмалов тәрҗемәсендә) басыла. «Мин күргән, мин белгән Латвия» дигән публистик мәкаләсендә З. Зәйнуллин мөстәкыйль Латвиянең иҗтимагый-сәяси хәлләрен, төрле милләт кешеләренең, шул исәптән үзе белән хезмәт иткән полковникларның, генералларның һ.б. тормыш-көнкүрешен яктырта.

Шулай итеп, сикәлтәле юллар узып, бай тормыш тәҗрибәсе туплап, үсеш баскычлары аша күтәрелә барып, 45 яшендә Зәки ага әдәбият мәйданына килә. Аның беренче әсәрләре киң җәмәгатьчелек, күренекле язучылар, сәнгать әһелләре тарафыннан бәяләнә. Татарстан китап нәшриятында матур әдәбият редакциясенең өлкән мөхәррире вазифаларын башкарган, әдәби тәрҗемә остасы Яхъя Мөхәммәтгали улы Халитов «Җир исе» исемле тәүге хикәяләр җыентыгын бәяләп: «З. Зәйнуллинның нәшриятка җибәргән бу кулъязмасында утыздан артык хикәя һәм парчалары тупланган. Болар – әлбәттә, эчтәлекләре белән төрле характердагы нәрсәләр. Авторның уңай яктан билгеләп китәсе сыйфаты шул: ул саф татарча итеп матур, төзек тел белән хикәяли белә (кайбер авторлар шикелле икенче телдән тәрҗемә ителгән калькалар белән язмый)», – дип, уңышлы якларына басым ясый. Һәр әсәрен конкрет бәяләп, авторның беренче уңышлары әлләни зур түгеллегенә ишарәле, хикәяләргә рецензия язган А. Яхинның фи-

керләре белән тулысынча килешүен әйтеп: «Рецензиядә авторның әсәрләренә нинди кимчелекләр хас икәнлеге турында бик конкрет һәм тәфсилле итеп әйтелгән. Аларны кабатлап торуның кирәге юк. Бу хәлендә З. Зәйнуллинның хикәяләрен китап итеп чыгарып булмый әле. Юмор һәм сатира җыентыгына да сайлап алып булмады. Менә бу тәмам эшләнеп җиткән чын юмор һәм сатира әсәре дип әйтердәе очрамады... З. Зәйнуллиннның ипле, әйбәт теле дә, каләме дә бар», – ди тәнкыйтьче [Халитов, 1987].

Дөньяның яхшысына, яманына, тормыштагы һәр җитди үзгәрешвакыйгага үз мөнәсәбәтен, фәлсәфи карашын ихластан кыю әйтә белү сәләтенә ия язучының иҗат колачы киңәя, язасы темалары, әйтәсе сүзләре күп була. Язган саен З. Зәйнуллин каләме чарлана, темасы, сюжетка алып керә белү осталыгы аны күренекле язучыларның берсе итә. «Идел», «Сөембикә», «Ялкын», «Мирас» журналларында, «Ватаным Татарстан», «Мәдәни җомга», «Татарстан яшьләре» газеталарында язучының туганягы кешеләренең самими образларын, гыйбрәтле язмышларын гәүдәләндергән, күп очракта авторның бала һәм үсмерчак хатирәләренә киң урын бирелеп, сугыш алды, сугыш чоры, сугыштан соңгы татар авылының кырыс тормыш күренешләрен киң яктырткан һәм фронттагы канлы сугыш эпизодларын да үз эченә алган хикәяләре дөнья күрә.

1988 елда язучының «Үрләр аша» исемле беренче повесте һәм хикәяләре тупланган китабы 15 мең тираж белән Казанда Татарстан китап нәшриятында басыла. Бу җыентык укучылар игътибарын бик тиз җәлеп итә, «Үрләр аша» повесте З. Зәйнуллинны язучы-әдип буларак таныта. Ул укучылар тарафыннан яратып укыла, уңай бәя ала: «Башта үзем укыдым, аннан гаиләм белән бергәләп. Ничә мәртәбә күңелем тулып, туктап тордым. Укып бетергәч, җанга уелып калган сугыш елларын, айларын, көннәрен бөртекләп хәтердән үткәрдем... Рәхмәт, Зәки туган. Шушы повестьны гына язып, башка бер әсәр язмасаң да, Зәки Зәйнуллин дигән язучы исеме күңелләрдә сакланыр, дип уйлыйм» [Яңа әсәр укыгач, 1988, б. 186].

1989 елда З. Зәйнуллин Ригадан Казанга күченеп кайта, иҗат эшчәнлеген дә киң җәелдереп җибәрә – «Галимулла бабай күгәрченнәре» (1990), «Сугыш алды малайлары» (1991), «Зират күперен чыккач» (1991) повестьлары дөнья күрә. Алар да хуплап каршы алына. «Казан утлары» журналында «Проза турында сөйләшү» рубрикасында Ф. Галимуллин: «Мине тагын бер олы шәхесебезнең иҗаты куандыра. Ул – Зәки Зәйнуллин. Халкыбызның олпатлыгын һәм затлылыгын гәүдәләндергән бу ил агасына Ходай Тәгалә язучылык талантын да кызганып бирмәгән. Аның “Үрләр аша”, “Галимулла агай күгәрченнәре”, “Сугыш алды малайлары”, “Урам” повестьлары һәм хикәяләре күпләрнең игътибарын җәлеп итәләр. Аз гына мәйданда кеше холкын ачу осталыгы, халыкчан теле, хикәяләүне җиңел алып баруы – авторның төп өстенлеге», – дип яза [Галимуллин, 1993].

Иҗат эшчәнлеге белән бергә З. Зәйнуллин Татарстандагы иҗтимагый-сәяси вазгыять белән таныша, татар зыялылары арасында шактый көчәеп барган милли-азатлык хәрәкәтенә кушылып китә, шул ук елның 15 ноябрендә Ш. Мәрҗани исемендәге җәмгыятьнең президенты итеп сайлана. Татарстанның мөстәкыйльлеге өчен көрәштә актив катнаша. 1991 елның 14–26 май көннәрендә Ирек мәйданында сәяси ачлык игълан итүчеләрнең дә берсе ул була. Ачлык мәйданындагы тәэсирләрен ул соңыннан «Тынгысыз көннәр, котылгысыз уйлар...» дигән публицистик язмасында яктырта. 1992 елның 1–2 февралендә Казанда үткән БТИҮ корылтаенда Милли Мәҗлес оештырыла, аның рәисе итеп Татарстанның халык депутаты Т. Абдуллин, беренче урынбасары итеп З. Зәйнуллин сайлана.

З. Зәйнуллинның җәмәгать һәм иҗат эшчәнлеге бергә үрелеп бара. 1995 елда «Идел» журналында «Кулак малае» дип исемләнгән повесте басыла. Әсәрдә авыл кешеләренең башына төшкән бәла-казалар, төрмәгә утыртулар кебек күңелсез хәлләр бәян ителә. Әлеге әсәр турында Мансур Вәли: «...Зәки Зәйнуллинның “Идел”дә басылган “Кулак малае” исемле повесте мавыгып укыла. Гомумән, татар халкының бу олы шәхесе нинди генә эшкә тотынса да, бик тиз арада беренчеләр сафына килеп чыга. Әдәбиятта дә шулай булыр, ахрысы... Әлбәттә, урыны-урыны белән аңа документальлек бераз комачаулап та куя. Әмма “Вачута...”дагыча булса – вакыйгалар тыгызлыгы белән табигый иркенлек һәм сулыш киңлеге матур аралашса, – авторны әле тагын да зуррак уңышлар көтә. Бирсен Ходай, чөнки соңгы елларда прозабызның әдәбилеге, сәнгатьлелек дәрәҗәсе бик тә аксый башлады», – дип яза [Вәлиев, 1995].

З. Зәйнуллиның «Ат каракларры» романын Р. Сверигин 1996 ел прозасының бик үзенчелекле һәм яңа казанышы дип саный: «Халкыбыз үткән юлда, чыннан да, билгеле эз калдырган, аннан да бигрәк, күптөрле риваятьләр-әкиятләр, уйдырмалар, шомлануларга сәбәпче булган ат урлау, ат каракларры темасына, әлбәттә, теләсә кем (мәсәлән, мәктәп, ВУЗ эскәмияләреннән килеп, хәзер биек йортлардагы кабинет тәрәзәләреннән карап тормышны өйрәнүче, анализлаучы каләмдәшебез) тотына алмый. Беренчедән, материал үзенең хәвеф-хәтәрлеге белән әллә каян өркетеп тора. Икенчедән, күзләреңне йомып алынсаң да, күп нәрсә майтара алмаячагың көн кебек ачык – тормыш тәҗрибәсе җитенкерәми. Биредә каләм усал айгырларны иярләрлек, гаярь, дуамал холыклы ир-егетләр кулында гына бии ала! Интеллигент табигатьле, тәртипле-инсафлы әдипләребез үпкәләмәсеннәр. Чөнки әдәбиятта һәркемнең үз темасы була. Бу – алар темасы түгел. Бу – З. Зәйнуллинның темасы» [Сверигин, 1997, б. 122]. «Ат каракларры» романында күренешләр, искитәрлек характерлар, башкисәр геройлар бар. Кайберәүләр өчен төп максатка әверелгән шөгыльнең үсеше-тарихы, эволюциясе, һәлакәте һәм ат урлау романтикасы турында гына түгел әсәр. Аңарда бер тыелгысыз омтылыш, ирек даулау, беркемгә дә баш бирмичә,

үзенчә яшәү теләге дә бөркелеп тора. Тәнкыйтьче З. Зәйнуллинның язу осталыгы әсәрдән-әсәргә камилләшә һәм чарлана баруына игътибар итеп: «Мондый камиллеккә материалны, теманы яратып, бирелеп язганда гына ирешеп була», – ди [Сверигин, 1997, б. 122].

1997 елда З. Зәйнуллинның «Ат караклары» романын һәм «Ата нигезе» повестен берләштергән китабы, 1998 елда өч повестен («Үрләр аша», «Каршы таулар», «Урам») һәм «Ник ямансу бу күзләр?» исемле моңсу хикәясен үз эченә алган һәм шул хикәя исеме белән аталган җыентыгы, 1999 елда «Агыйделнең аръягында...» роман-кыйссасы дөнья күрә. Р. Батулла әлеге китапларга нисбәтән бер мәкалә-бәяләмә яза һәм ул анда З. Зәйнуллин иҗатының тел үзенчәлегенә дә мөнәсәбәтен белдерә: «...Зәки ага үз әсәрләрендә Казан якларындагы татарларда булып та онытылган яки типтәрләргә генә хас сүзләр куллана. Бездән олырак буын мөхәррирләре җирле сөйләм сүзләрен яшь язучыларның әсәрләреннән сызып ташлый торган иде, янәсе, Казан арты теле генә – әдәби тел. Бу – тамырыннан зарарлы караш. Ана теле бөтен җирле телләрдәге сүзләр белән баетылырга тиеш. Андый сүзләр җөмлә агышында аңлашыла, аңлашылмаган очракта, астөшермә биреп кулланырга кирәк. Мишәр, керәшен, себер туганнарыбыз, типтәрләр, кырым татарларының сүзләрен җае туры килгән саен, җөмлә агышында аңлашылырлык итеп куллану зарури. Язучы Зәки Зәйнуллинның соңгы елларда иҗат иткән өч әсәре укучы кулына килеп ирешге, һәм бу китап соңгы еллардагы татар прозасының уңышы булып тора» [Батулла, 2001].

Филология фәннәре докторы, профессор Илидә Бәширова язучы иҗатына күзәтү ясап: «З. Зәйнуллинның роман, повестьлары темаларының ачылуы белән генә түгел, ә бәлки теленең камиллеге ягыннан да аерылып тора [...]. Соңгы 10–15 еллар эчендә без күргән, без белгән Зәки Зәйнуллин татар халкының танылган әдибе, публицист һәм җәмәгать эшлеклесе булып җитешкән, туган халкы, туган туфрагы аңа ныклы нигез булган икән! Без аның укучылары, яшьтәшләре, каләмдәшләре, бу хәлгә бик шатланабыз, куанабыз..», – дип яза [Бәширова, 2008].

Исеме белән, материалы, формасы белән дә оригиналь «Татар ир-егетләре» исемле китабы татар халкының талантлы һәм батыр йөрәкле ирләре турындагы «Кави Нәҗми дигән язучы», «Армия генералы Алексей Антонов», «Мәүлет гусар», «Йә атыгыз, йә аклагыз!», «Һаваларда ялгыз торна...», «Гарасатлы юллар» повестьларын колачлый. Соңгы повесте без белеп һәм аңлап бетермәгән 1939–1940 еллардагы совет-фин сугышының гыйбрәтле хәлләре, кызыклы һәм фаҗигалы язмышлар хакында тарихның өр-яңа сәхифәләрен ача. Сугыш манзараларын тасвирлаудан бигрәк, автор игътибарны бер кавем кешеләренең мөнәсәбәтләренә юнәлтә: «Ленин – Сталин эше өчен көрәшкә әзер булырга» кайчандыр тантаналы вәгъдә биргән татар солдаты финнарга әсирлеккә эләгә, аңа үлем куркынычы яный.

Бәхетенә милләттәше фин армиясендә булып чыга. Язучы кыска-кыска штрихлар һәм диалоглар ярдәмендә фаҗигалы ситуацияне бик оста һәм укучы күңелен тетрәндерерлек итеп сурәтли.

Әдипнең, нигездә, үз башыннан кичкән гыйбрәтле хәлләрне тасвирлаган хикәяләре тупланган «Наган» дип исемләнгән китабы, соңгы елларда язылган гыйбрәтле дә, шул ук вакытта шаян да хикәяләрен туплаган «Йөз дә бер хикәя», «Агай-эне, таныш-белеш...», « Кеме генә юк татарның?» китаплары туган ягы Стәрлебаш, аның асыл кешеләре, армия тормышы, фән дөньясы, көрәштәшләре, сәяси вакыйгалар турында мемуарлар формасында язылып, татарда бестселлер китап булып тарихка керде.

Халык язучысы, Татарстан язучылар берлеге рәисе Ркаил Зәйдулла: «Ул кайчагында чаманы да югалтып җибәрә торган туры сүзле кеше иде. Ләкин аны беркайчан да хөсетлектә гаепләп булмый. Ул олыгайган көнендә безнең әдәбиятта яңа сүз әйтте. Чөнки аның биографиясе бай иде – ул дөнья күргән. Әдәбиятта бай биографияле булу бик кирәкле сыйфат, ул бер шарт та булып торадыр. Язмышы кызыксыз кешенең әсәрләре дә кызыксыз була. Зәки аганың язмышы, үзенең язуларына караганда, бик кызыклы булган, әсәрләре дә кызыклы», – дип искә ала.

З. Зәйнуллинның милләтчелек карашлары иҗатын сыйфатлаучы төп билгеләмә булып үсеш ала, әсәрләрендә күтәрелгән тема-проблемалар актуальлеген югалмый, укучыга көчле тәэсир итеп, татар халкының җәмәгатьчелек фикерен, иҗтимагый аңын үстерүдә дә зур роль уйный.

Менә шушы һәркайсы гаять зур тырышлык, аң-белем, рухи җегәр, йөрәк көче таләп иткән һәм олы җаваплылык, ярату тойгысы белән башкарылган эш-гамәлләре өчен дә З. Зәйнуллин чиксез ихтирамга лаек. Әмма аның хезмәтләре болар белән генә чикләнми. Йөрәгендәге гамен һәм моңын, образлар аша тылсымлы көчкә төреп, укучыларына җиткерә ул. Һәр әсәре хәтердә кала, уйландыра, сискәндерә. Үткән һәм киләчәк, яшәү һәм үлем, ата-бабаларыбыз тарихына гаять зур ихтирам, рухи кыйммәтләребезнең кадерсезләнүе җәһәтеннән борчылу безне уйланырга мәҗбүр итә. Аның әсәрләренең үзәгендә – кеше, аның язмышы, бүгенгесе һәм киләчәге, Ватан төшенчәсенең асылын тәшкил иткән туган җир, туган тел, туган авыл. Тирән фәлсәфәле әсәрләренең җаны менә шулардан гыйбарәт. Югарыда телгә алынган «Үрләр аша» повестенда да автор психологик кичерешләрне оста сурәтләүче булып таныла.

«Арбалы хатыннар» пьесасын беренчеләрдән булып режиссёр Нурия Рәхмәтуллина җитәкчелегендәге Стәрлебаш халык театры сәхнәләштерде. Зәки ага тарафыннан икенче гомер бирелгән таныш персонажларны күреп, Стәрлебаш тамашачысы пьесаны бик җылы кабул итте. Театр 2005 елда «Алтын тирмә» республика бәйгесендә беренче урын алды.

Әсәр тормышчан булуы белән бик күп драматургларның, режиссёрларның да игътибарын яулады. Бөек Җиңүнең 65 еллыгын каршылаган көннәрдә, 2010 елның 22 июне көнне, Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры «41 нең арбалы хатыннары» пьесасының премьерасын Казан тамашачысына тәкъдим итте. З. Зәйнуллин әсәре буенча эшләнгән спектакльне татар җәмәгатьчелеге көтеп алды һәм яратты. Авторның идеяләрен тамашачыга җиткерүдә режиссёр Фәрит Бикчәнтәев, рәссам, артистлар кызыклы алым-формалар кулланып, аерым күренешләр, мизансценалар ярдәмендә татар театрына яңалык алып килделәр.

Язучы, галим, җәмәгать эшлеклесе З. Зәйнуллин 2021 елның 4 мартында 87 яшендә вафат булды һәм Стәрлебаш зиратында җирләнде. Әдипнең дистәдән артык күләмле әсәре басылып чыкмый, татар халкының бөек шагыйре, җәмәгать эшлеклесе, иганәче Закир Рәмиев турындагы романы тәмамланмыйча калды. Алга таба аның бай мирасы татарның XXI гасыр рухи тормышында да үзенең әһәмиятен югалтмас; милли рухи-мәдәни үсешебезгә, алгарышыбызга һәрдаим йогынты ясап торыр, иҗаты халкыбызга хезмәт итеп, тагын да тирәнрәк өйрәнелер дип ышанабыз.

**Әдәбият**

*Бәширова И.* Без белгән, без без күргән Зәйнуллин... // Мәдәни җомга. 2008. Июль.

*Вәлиев М.* «Кулак малае» исемле повестьны укыгач // Шәһри Казан. 1995. № 22.

*Галимуллин Ф.* Проза турында сөйләшү // Казан утлары, 1993. № 2. Б. 153–158.

*Зайнуллин З.* Проводы полковника: докум. повесть. Казань: Татар. кн. изд-во, 1992. 111 с.

*Зайнуллин З.Л.* Научная борьба в ракетных войсках. Документальное издание. Казань, 2016. 680 с.

*Зәйнуллин З.* Агай-эне, таныш-белеш...: хикәяләр. Казан, 2015. 700 б.

*Зәйнуллин З.* Агыйделнең арьягында // Казан утлары. 1999. № 1. Б. 18–65; № 2. Б. 11–67.

*Зәйнуллин З.* Арбалы хатыннар. Пьесалар. Казан, 2015. 524 б.

*Зәйнуллин З.* Ата нигезе // Мирас. 1997. № 9–11.

*Зәйнуллин З.* Йөз дә бер хикәя. Казан: Илһам, 2011. 190 б. 13 б.

*Зәйнуллин З.* Наган: хикәяләр. Казан, 2010. 176 б.

*Зәйнуллин З.* Кеме генә юк татарның?: хикәяләр. Казан, 2016. 312 б.

*Зәйнуллин З.* Кулак малае // Идел. 1995. № 3. Б. 15–20; № 4. Б. 22–26.

*Зәйнуллин З.* Мин күргән, мин белгән Латвия // Мәдәни җомга. 2008. № 12–14.

*Зәйнуллин З.* Полковникны озату // Идел, 1991. № 3–4.

*Зәйнуллин З.* Сугыш алды малайлары: повестьлар. Казан: Татар. кит. нәшр., 1991. 200 б.

*Зәйнуллин З.* Татар ир-егетләре: повестьлар. Казан: Татар. кит. нәшр., 2010. 478 б.

*Зәйнуллин З.* Тынгысыз көннәр, котылгысыз уйлар... // Идел. 1992. № 7. Б. 17–22; № 8. Б. 12–18..

*Зәйнуллин З.* Үрләр аша // Казан утлары. 1987. № 10. Б. 7–44.

*Зәйнуллин З.* Үрләр аша: повесть һәм хикәяләр. Казан: Татар. кит. нәшр., 1988. 128 б.

*Сверигин Р.* Проза турында сөйләшү // Казан утлары, 1997. № 5. Б. 122.

*Халитов Я.* Зәйнуллинның «Җир исе» хикәяләр җыентыгына бәяләмә. ТР ФА Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма мирас үзәге. Ф. 224.

Яңа әсәр укыгач // Казан утлары. 1988. № 5. Б. 186–187.

***Насыйбуллина Нуридә Шәйдулла кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел,*
*әдәбият һәм сәнгать институтының Язма мирас үзәге*
*өлкән фәнни хезмәткәре*

УДК 821.512.145

***А.Р. Мөбарәкшина***

# ТАТАР ҺӘМ ТӨРЕК МАТБУГАТЫНДА ФАТИХ КОТЛЫНЫҢ ТӘРҖЕМӘ ЭШЧӘНЛЕГЕ

Татарско-турецкие литературно-культурные взаимосвязи имеют богатую многовековую историю. Роль периодической печати в освещении литературы, культуры, просвещения, социально-политической ситуации стран двух тюркских народов всегда была велика. В современной татарской и турецкой прессе публикуются многочисленные статьи, рецензии, беседы о литературных переводах Фатиха Кутлу на турецкий язык. В Турции современная татарская литература на научном уровне изучается в основном через переводы Ф. Кутлу.

**Ключевые слова:** татарско-турецкие взаимосвязи, диалог культур, переводческая деятельность, Фатих Кутлу, Габдулла Тукай, Аяз Гилязов, татарская пресса, «Казан утлары».

Tatar-Turkish literary and cultural interrelations have a rich centuries-old history. The role of the periodical press in the coverage of literature, culture, education, socio-political situation of the country of the two Turkic peoples has always been great. Numerous articles, reviews, and conversations about the literary translations of Fatih Kutlu into Turkish are published in the modern Tatar and Turkish press. In Turkey modern Tatar literature is studied at the scientific level through the translations of F. Kutlu.

**Keywords:** Tatar-Turkish relations, dialogue of cultures, translation activities, Fatih Kutlu, Gabdulla Tukay, Ayaz Gilyazhov, Tatar Press.

Бүгенге көндә төрки халыкларның даими үзара аралашуында, рухи байлыклары белән уртаклашуында телләр белү әһәмиятле фактор булып тора. Нәтиҗәдә, әдәбият өлкәсендә тәрҗемә эшчәнлеге киң җәелә һәм ул төрки әдәбиятлар арасындагы багланышларны көчәйтү ысулына әверелә. Бер төрки мәмләкәттә иҗат ителгән әсәрләр башка төрки халыкларның милли хәзинәсенә әйләнә һәм тәрҗемә әсәре шул халыкның теленә, аның милли закончалыкларына, тәрбияви бурычларны үз эченә алган потенциалына яраклашырга мәҗбүр була [Ханнанов, б. 10]. Бу юнәлештә татар матбугаты кардәш әдәбиятларның милли әдәби хәзинәсенә зур урын бирә. «Казан утлары» журналында даими рәвештә казакъ, кыргыз, үзбәк, карачай-балкар, комык халыкларының классик әсәрләре татарчага тәрҗемәдә басылып килә. Анда «Кардәш халыклар әдәбияты» рубрикасы даими эшли. «Безнең мирас», «Идел» журналлары, «Ватаным Татарстан», «Мәдәни җомга», «Шәһри Казан» газеталары битләрендә дә татар әдәбиятының чит илдә тәрҗемәдә дөнья күрүен, чит мәдәнияттә аның ничек кабул ителүен, тәрҗемәнең уңышлы һәм кимчелекле якларын яктырткан тәнкыйди-публицистик мәкаләләргә урын бирелә. Бу – билгеле, журналистиканың тәрҗемәчеләр, галимнәр, мат-

бугатны һәм тәрҗемә китапларны укучылар, мөхәррирләрнең үзара аралашып, мәдәни-әдәби дискуссиядә эшләвен таләп итә торган катлаулы, җанлы бер юнәлеше. Тәрҗемәче, публицист-язучы Фатих Котлы (1974 елда туган) эшчәнлеге – төрки халыклар арасындагы тыгыз мәдәни элемтәләрнең якты үрнәге. Ул бигрәк тә төрек-татар әдәби бәйләнешләре юнәлешендә зур эш башкара. Тәрҗемәче татар әдәбияты тарихында аерым бер чорга гына тукталмый, ә тулы бер гасырны өйрәнеп, XX гасыр башы, Совет чоры татар әдәбиятын да, хәзерге заман язучыларның әсәрләрен дә җентекләп тикшерә һәм аларны төрек укучысына җиткерү өчен зур хезмәт куя. Аның тәрҗемәләре төрекләр тарафыннан җылы кабул ителә, тиз арада фәнни әйләнешкә кереп китә, галимнәрнең фикерләре, тәнкыйть мәкаләләре Төркия матубгатында һәм татар газета-журналлары битләрендә дә дөнья күрә. Сөембикә Кашапова, Рәшит Минһаҗ, Диләрә Батыршина кебек күренекле татар журналистлары Ф. Котлының тәрҗемә эшчәнлеген татар вакытлы матбугатында даими яктыртып бара. Публицистның әдәби тәрҗемәчелек эшчәнлеген татар галимнәре дә өйрәнә. Аерым алганда, профессор Ф.С. Сәйфуллина, А.З. Вәлиеваның инглиз, рус, татар телләрендәге мәкаләләрен күрсәтү мөһим [Сәйфуллина, Вәлиева, б. 43–64]. Басылып чыккан хезмәтләр тәрҗемәченең әдәбиятчы галимнәр Х. Миңнегулов, М. Хәбетдинова, Ә. Закирҗанов, Ә. Сибгатуллина белән тыгыз элемтәдә эшләве турында сөйли. Ф. Котлының татар җирлегендә яшәп иҗат итүе тәрҗемә эшчәнлегенә уңай йогынты ясый. Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы буларак, ул хәзерге заман әдипләре белән турыдан-туры элемтәдә тора, аерым бер әсәрне тулы бер әдәби барыш, әдәбият тарихы яссылыгында күзаллый, татар укучысының теге яисә бу әсәрне ничек кабул итүен үз күңеле аша кичереп төшенә. Тәрҗемәгә әсәр сайлаганда, татар укучысының бәясен, тәнкыйтьче галимнәрнең фикерләрен истә тотып эш итә.

Иң беренче чиратта, Фатих Котлының Габдулла Тукай фәненә керткән өлешен аерып күрсәтү зарур. Ул Тукайның «Су анасы» әкиятен тәрҗемә итеп, 2015 елда Төркиядә басылган «Abdullah Tukay şiirleri» җыентыгында бастыра. Әлеге басма дөнья күргәч, татар матбугаты төрек укучылары һәм галимнәренең фикерләрен яктырта [Кутлу, 2015, б. 9]. Шагыйрьнең тууына 130 ел тулу уңаеннан Әнкарадагы Евразия Язучылар берлеге нәшриятында чыккан «Кардәш каләмнәр» журналының тулы бер саны Г. Тукайның тормыш һәм иҗат юлын яктыртуга багышланган. Әлеге басмага рецензия «Казан утлары» журналының 2016 елдагы июль санында бирелгән [Мөбарәкшина, б. 145].

Фатих Котлы – сиксәннән артык татар әдибенең иҗатын төрек укучысына таныткан тәрҗемәче, язучы-публицист, җәмәгать эшлеклесе. Аның тәрҗемә эшчәнлегендә татар әдәбияты классигы, прозаик Аяз Гыйләҗев әсәрләренә аеруча зур урын бирелә. Ф. Котлы А. Гыйләҗев белән якыннан таныш була, аның «Өч аршын

җир» повестен төрек телендә күрергә теләвен язучының васыяте сыйфатында кабул итә. Бу тәрҗемәченең яшәеш фәлсәфәсе, кеше психологиясе белән сугарылган мәңгелек темаларны аеруча якын итүе белән дә бәйле. «Өч аршын җир» әсәре төрек телендә нәшер ителүгә (2008), Төркия матбугатында галим-язучыларның фикерләре күренә башлый. Шуларның кайберләрен «Идел» журналы да бастырып чыгара. Бу татар укучысына милли әсәрләрнең башка чит мәдәнияттә ничек кабул ителүен аңларга, ике мәдәниятнең охшаш һәм аермалы якларын күрергә мөмкинлек бирә [Төркиядә танылу, б. 64]. «Өч аршын җир» повестеның тәрҗемәсе (2008, 2013) Евразия Язучылар берлегенең төрки телләрдән төрекчәгә иң яхшы тәрҗемә әсәре номинациясендә дә җиңү яулый. Соңрак тәрҗемәче дүрт ел дәвамында «Җомга көн кич белән» әсәре өстендә эшли, аның тәрҗемәсе 2013 елда А. Гыйләҗевның тууына 85 ел тулу уңаеннан басылып чыга. Ул «Мәдәни җомга» газетасы хәбәрчесе С. Кашаповага биргән интервьюсында тәрҗемәне нәшриятка тапшырганчы төрек галимнәренә, әдәбиятчыларына укытуын, аларның киңәш-фикерләренә колак салуын, үз остазларыннан хәер-фатиха алгач кына, киң җәмәгатьчелеккә чыгаруын билгеләп үтә. «Нәшриятка тапшырганчы, Төркиядәге остазым, мөгаллим Әхмәт Йүзәроглуга күрсәттем. Ул – күп кенә роман-хикәяләрнең редакторы да. Укытучым әсәрне бик зурлады: «Әйтерсең, бу повесть Төркиядә язылган. Йөрәгем аны үзебезнеке кебек кабул итте», – дип, шатлануын белдерде. Шунда өстемнән тау төшкән кебек булды» [Кутлу, 2012, б. 5]. Ф. Котлы Аяз Гыйләҗевның «Өч аршин җир», «Җомга көн кич белән», «Яра», «Язгы кәрваннар»ын тәрҗемә итеп, төрек милли җирлегенә аерым җыентыклар рәвешендә дә, журналлар аша да кабат-кабат тәкъдим итә. Ул татар язучысының әсәрләрен генә түгел, аның хакындагы тәнкыйтьне, публицистик мәкаләләрне дә өйрәнә, замандашларының хатирәләрен, фотосурәтләрне барлый. 2020 елда Төркиянең «Тәмрин» журналы 4 нче санын тулысынча А. Гыйләҗевның тормыш һәм иҗат юлына багышлый [Tatar Edebiyatının..., б. 3–64]. Журнал басылып чыгуга, татар газеталарында бу турыда хәбәр-мәгълүмат һәм фикер алышулар башлана [http://www.antat.tatar/tt/news/9776/; http://beznenmiras.ru/torkiyada-gyjlazhevka/]. Шулай итеп, тәрҗемәче тырышлыгы белән татар әдибенең тормыш һәм иҗат юлы бер басмада тәкъдим ителә.

Ф. Котлы эшчәнлеге аша төрек фәнендә татар әдәбиятына багышланган диссертацияләр яклана. Абдулкадир Чәкич «Аяз Гыйләҗев әсәрләрендә культура көрәше» дигән темага гыйльми хезмәт яза [Аяз Гыйләҗев..., б. 5]. А. Чәкич һәм Айшәнур Чәкич, Ф. Котлы тәрҗемәсенә нигезләнеп, 2021 елда Американың «Амазон» нәшриятында «Өч аршын җир» повестен «Three Yards Ofland» исеме белән бастыра. Төрек язучысы Т. Танәр дә татар халкының классик язучысы иҗаты белән Ф. Котлы тәрҗемәләре аша танышып, аны французларның Стендалена тиңли [Төркиядә танылу, б. 64].

Ф. Котлы искәртүенчә, А. Гыйләҗев әсәрләренең төрекчәгә уңышлы тәрҗемә ителүендә әдипнең хатыны һәм аның иҗади мирасын барлаучы Нәкыя ханымның да өлеше бик зур. Ул тәрҗемә эше барышында язучының гаиләсе, дуслары, иҗатташлары белән очраша-күрешә, фикер алыша, татар галимнәренең киңәшләрен тыңлый, массакүләм мәгълүмат чараларында тәрҗемә эшчәнлегенең актуаль мәсьәләләре турында чыгышлар ясый. Шул рәвешле, аның тәрҗемә эше түгәрәк өстәл, семинар, очрашулар, фәннидәби-мәдәни чаралар белән үрелеп бара. Нәтиҗәдә, оригиналь өслүбле һәм эчтәлекле, төрек халкының күңеленә якын әсәрләр тәрҗемә ителә. Шуңа күрә А. Гыйләҗевның төрекчә проза китаплары тиз арада үз укучысын таба, кат-кат басыла һәм чит ил югары уку йортларында өйрәнелә. Әдипнең әсәрләрендә очраган канатлы сүзләрне төрек укучылары аерып ала, аларны махсус әдәбият сайтларына урнаштыра һәм бу гыйбарәләрнең мәгънә тирәнлеге турында фикер алыша [https://1000kitap.com/yazar/ayaz-giylecev/alintilar]. Үз эшенең һәм төрек, һәм татар җирлегендә яратып кабул ителүе, укылуы, матбугатта фикер алышуларны күрү тәрҗемәчегә илһам һәм көч өсти. Ул А. Гыйләҗевның бай мирасын төрки халыклар гына түгел, бөтен дөнья белергә тиеш, дигән фикердә тора. Бүгенге көндә татар язучысының «Берәү», «Мәхәббәт һәм нәфрәт турында хикәят» повестьлары һәм «Йәгез, бер дога!» романы караламада тәрҗемә ителеп беткән.

Фатих Котлы – хәзерге татар әдәбиятына да зур игътибар биргән тәрҗемәче. Аның Төркиядә чыга торган төрле әдәби журналлар өчен хәзерге заман татар прозасына, шигъриятенә һәм әдипләренә багышланган махсус дүрт сан әзерләве билгеле. 2022 елның августында Әнкараның атаклы «Һәҗә» нәшриятында «Хәзерге заман татар хикәяләре антологиясе – XXI гасыр» дигән хрестоматия Ф. Котлы тәрҗемәсендә дөнья күрде. Антологиягә кереш сүзне Татарстан Язучылар берлеге рәисе Р. Зәйдулла язган [Татар хикәяләре..., 2022]. 30 язучының хикәяләре кергән хезмәт басылып чыгуга ук, төрек матбугатында язучы һәм галимнәрнең уй-фикерләре, рецензияләре күренә башлый. Галимә һәм тәрҗемәче А. Рәхимова шулар арасыннан Ибраһим Демирҗинең кайтавазын татарчалаштырып, Татарстан Язучылар берлеге сайтына, «Татар-информ» электрон матбугат басмасына һ.б. куя [https://tatar-inform.tatar/news/torek-zurnalynda-tatarstan-yazucylar-berlege-raise-rkail-zaidulla-belan-angama-cykty-5860952]. Р. Батулла, Л. Зөлкарнәй, Ә. Гаффар, Р. Мөхәммәдиев, Л. Лерон, Р. Рахман һ.б.ның хикәяләре урын алган антология хакында төрек язучысы И. Демирҗи: «Аларны укыганда... мөселманлыкның һәм ислами гореф-гадәтләрнең татар җәмгыятенә, аның иң вак тамырларына кадәр үтеп кергән булуын, көчле нигез тәшкил иткәнен әледән-әле хис итәсең», – дип яза [https://sptatar.com/t-rkiyad-tatar-hik-yal-re/]. Төркиянең «Һәҗә» журналы 2022 елның октябрь санын тулысы белән хәзерге татар шигъриятенә багышлый.

Ф. Котлы бу сан өчен 20 татар шагыйренең шигырен әзерли. Басма Ф. Котлының Р. Зәйдулла белән «Татар шигыренең үткәне, бүгенгесе, киләчәге» дип аталган әңгәмәсе белән ачыла. Бу турыда «Татар-информ» электрон матбугат басмасында Төркиядә яшәүче татар журналисты Рушания Алтай язып чыга. Шул рәвешле, Ф. Котлы көче белән татар әдипләренең әсәрләре төрекчәгә тәрҗемә ителә, төрек матбугатында дөнья күрә, хәбәрләр, кайтавазлар, рецензияләр Татарстан газета-журналларына килеп ирешә – җанлы татар-төрек әдәби багланышы дәвам итә.

Публицистның милли мәгариф системасына керткән өлеше дә зур. Аның тәрҗемәсендәге татар әдәбияты үрнәкләре Төркия Мәгариф министрлыгы тарафыннан балалар мәҗбүри укырга тиешле дип расланган йөз китап арасында да бар (шул исәптән Ә. Еникинең «Әйтелмәгән васыять» һәм «Матурлык» хикәяләре дә). Моннан кала, мәктәп балаларына адресланган тагын ике җыентык чыга. Беренчесе – XX гасыр башында иҗат иткән унбиш татар әдибенең унҗиде хикәясеннән торган «Филдиши чакы» (Сөяк саплы пәке) китабы (Әнкара, 2013). Һәм бүгенге көндә иҗат белән шөгыльләнгән 28 татар әдибенең башлангыч мәктәп балаларына адресланган хикәяләрен үз эченә алган «Алтын синҗап» (Алтын тиен) антологиясе (Әнкара, 2014).

Ф. Котлының тәрҗемәләре һәм сыйфат, һәм сан ягыннан игътибарга лаек: 99 хикәя, 4 повесть, 1 пьеса, 1 роман һәм күпсанлы шигырьләр Төркиядә – 13, Татарстанда 3 китап булып дөнья күргән. Хәзерге вакытта басмага әзерләнүче хезмәтләр дә бар. Ф. Котлы татар әдипләренең иҗатын тәрҗемә итү барышында милли җирлеккә генә хас гыйбарәләрне, тирән яшерен мәгънәләргә ия метафора, символларны тәрҗемә итү процессында төрки телләр әдәби-мәдәни диалогы яссылыгында актуаль көнүзәк мәсьәләләрне, шулар рәтендә татар теленең аңлатмалы сүзлеген төрекчәгә тәрҗемә итү зарурлыгын еш күтәреп чыга һәм әлеге мәсьәләләрне телевидение, радио, газета-журналларда яктырта. Тәрҗемәченең татар әдәбияты һәм мәдәниятенең хәзерге торышын күзәтеп баруы, татар вакытлы матбугатында аңа турыдан-туры бәя бирү мөмкинлегенә ия булуы аны төрекчәгә камил тәрҗемәче итеп танытты. Ул кайсы гына язучының әсәренә алынмасын, татар милләтенә генә хас үзенчәлекләрне, чыганак хезмәткә хилафлык китермичә, үз әсәр буларак кабул итәрлек дәрәҗәдә төрекчә тудыруга ирешә.

**Әдәбият**

*Ханнанов Р.Г.* Төрки драматургия контекстында татар сәхнә әдәбияты (XIX гасыр ахыры – XX йөз башы). Казан: ТДГПУ, 2010. 193 б.

*Мөбарәкшина А.Р.* Тукай турында «Кардәш каләмнәр» // Казан утлары. 2016. № 7. Б. 145–149.

*Сәйфуллина Ф.С., Вәлиева А.З.* Фатих Кутлу тәрҗемәче һәм Төркиядә татар әдәбиятын танытучы буларак // Татарика. 2017. № 2. Б. 43–64.

*Кутлу Ф.* Татарга да тылмач кирәк: [тәрҗемәче белән әңгәмә /язып алды Сөембикә Кашапова] // Мәдәни җомга. 2012. 28 сент. (№ 39). Б. 5.

Кутлу Ф. Тукай шигырьләре – төрекчәдә // Мәдәни җомга. 2015. 23 окт. Б. 9.

Аяз Гыйләҗев юбилеена // Мәдәни җомга. 2016. 21 окт. Б. 5.

Tatar Edebiyatınnın Şanlı Bekçisi Ayaz Gıylecev // Тәмрин. 2020. Апр. (№ 102) Б. 3–64.

http://www.antat.tatar/tt/news/9776/ (мөрәҗәгать көне: 25.04.2024).

http://beznenmiras.ru/torkiyada-gyjlazhevka/ (мөрәҗәгать көне: 25.04.2024).

Төркиядә танылу // Идел. 2012. № 4. Б. 64–65.

Татар хикәяләре төрек телендә // Мәдәни җомга. 2022. 19 авг.

https://tatar-inform.tatar/news/torek-zurnalynda-tatarstan-yazucylar-berlege-raise-rkail-zaidulla-belan-angama-cykty-5860952 (мөрәҗәгать көне: 25.04.2024).

https://sptatar.com/t-rkiyad-tatar-hik-yal-re/ (мөрәҗәгать көне: 25.04.2024).

https://1000kitap.com/yazar/ayaz-giylecev/alintilar (мөрәҗәгать көне: 25.04.2024).

***Мөбарәкшина Алия Раиф кызы,***
*Казан шәһәре Идел буе районының 186 нчы күппрофильле «Перспектива» лицееның татар теле һәм әдәбияты укытучысы*

УДК 398.22

*Г.Р. Хөсәенова*

# XIX ГАСЫР БАСМА КИТАБЫ «ҖӘҮҺӘР ТАҖ КЫЗ»: ӘСӘРНЕҢ ЖАНР КОМПОНЕНТЛАРЫНА КЫСКАЧА КҮЗӘТҮ

В данной статье представлен общий обзор рассказа «Джаухар таж кыз», хранящегося в отделе рукописей и редких книг Национальной библиотеки Республики Татарстан. Автор подчеркивает близость данного рассказа к жанру дастан, наличие в тексте мотивов, свойственных эпосу; определяет идейно-тематику произведения; исследует систему образов. По мнению автора, рассказ «Джаухар тадж кыз» – произведение, которое следует отнести к книжным дастанам.

**Ключевые слова:** фольклор, литература, кыйсса, дастан, образ, герой, стиль, мотив.

This article provides a general overview of the story “Jauhar tazh kyz” stored in the department of anuscripts and rare books of the National Library of the Republic of Tatarstan. The author emphasizes the proximity of this story to the genre of “dastan”, the presence in the text of motifs peculiar to the epic, defines the ideological theme of the work, explores the system of images. According to the author the story “Jauhar tazh kyz” is a work that should be attributed to the field of folk art and written literature.

**Keywords:** folklore, literature,kyissa, dastan, image, hero, style, motive.

Татарстан Республикасы Милли китапханәсенең кульъязмалар һәм сирәк китаплар бүлегендә гарәп графикасында басылган «Җәүһәр таҗ кыз» кыйссасы саклана. Басылу датасы 1897 елга карый. Авторы билгесез.

Әлеге кыйсса дастан жанры билгеләрен үз эченә алуы белән кызыклы. Мәгълүм булганча, татар халкының күп кенә эпос-дастаннары башка жанр атамалары белән сакланып калган. Әйтик, «намә», «рисалә», «китаб», «хикәят», «дастан» терминнары уртак жанр буларак каралырга мөмкин булган әсәрләргә карата әйтелеп йөртелгән [Мухаметзянова, https://cyberleninka.ru/article/n/knizhnye-dastany-povolzhskih-tatar-problema-granitsy-zhanrovyh-nazvaniy-v-narodnom-tvorchestve]. Төрле тематикага нигезләнгән дастан текстларының «кыйсса» сүзе белән дә аталган булуы мәгълүм. Ул да – дастан, хикәят кебек, Көнчыгыш әдәби термины. «Татар энциклопедия сүзлеге»ндә аңа билгеләмә түбәндәгечә: «Кыйсса – гарәп сүзе, хикәя, тарихи вакыйга, риваять дигәнне аңлата. Шәрык әдәбияты һәм фольклорында эпик, кайвакытта лиро-эпик жанр. Кыйсса формасы һәм тематикасы белән дастанга якын, китаби һәм фольклор чыганакларына нигезләнә, героик, фантастик, әкияти һәм тарихи эчтәлектәге вакыйгаларны үз эченә ала...» [Татар энциклопедиясе.., 2002, б. 380]. Әлеге билгеләмәне нигез итеп

алып, безнең очракта кыйсса термины дастан төшенчәсе белән күпмедер дәрәҗәдә туры килә дип нәтиҗә ясарга мөмкин.

Әлеге көнгә кадәр татар фольклоры һәм әдәбияты өлкәсендә «Җәүһәр таҗ кыз» кыйссасына охшаш сюжетлар очравы билгеле булмады, шул сәбәпле, язма ядкәрнең таралуы, вариантлар күплеге турында мәгълүмат бирү шактый кыен эш. Безнең фикеребезчә, сюжетның башка халыклар иҗатында яшәве, сакланып килүе турында шик юк, бары танылу дәрәҗәсе түбән булганлыктан, кыйсса киң таралыш алмаган һәм җитәрлек дәрәҗәдә өйрәнелмәгән. Алга таба, әлеге ихтыяҗны истә тотып, әсәрнең вариантларын, төрле телләрдәге версияләрен табу бурычы куела.

Гаять мавыктыргыч сюжетка корылган әлеге кыйсса 15 биттән гыйбарәт. Әсәрдә «Пишәвәр», «Бинәрис» кебек географик атамалар телгә алынганлыктан, вакыйгаларны Пакистан иленең Пишәвәр *(Пишавер)* һәм Һиндстанның Бинәрис *(Варанаси)* шәһәре җирлекләрендә баруын фаразларга мөмкинлек туа.

Кыйсса Пишәвәр шәһәрендә яшәүче Хидыр Фадил исемле патшаның байлыгын бәян итү белән башланып китә. Зур мөлкәткә ия булган бу шаһның бер хәсрәте бар – үзеннән соң калдырырга нәсел дәвамчысы юк. Дөньяга килгән һәр сабыйның кыска гомерле булып, озак тормый үлеп китүеннән зар булган ата белән ананың көннәрдән беркөнне тагын бер балалары туа. Патша барлык вәзирләрен җыеп, «Бу кызыма гомер бирелеп, балигълыкка ирешсә, кызым кемне үзе яратса, һичбер сүз әйтмәстән, шул адәмгә никах итеп бирәм», диеп нәзер әйтеп, балага «Җәүһәр таҗ» дип исем куша. Хидыр Фадилның бу баласы гомерле булып чыга. Җәүһәр таҗ үсеп, 14 яшенә җиткәч, төрле җирлекләрдән, кызны хатынлыкка сорап, яучылар килә башлый. Патша әйткән сүзендә нык тора – кызын бары яраткан кешесенә генә бирәчәге турында җиткереп, яучыларны Җәүһәр таҗ янына җибәрә. Кыз барлык яучыларны да кире кагып, фәкать үз һөнәре булган адәмгә генә никахланачагы турында хәбәр бирә.

Бу заманда Бинәрис шәһәрендә Синан исемле яшь патша яшәгән. Көннәрдән беркөнне ул Җәүһәр таҗга яучы җибәрергә була, тик кыз аларны да элек әйтелгән сүзләр белән борып кайтара. Синан патша кызның «һөнәрле кешегә генә никахланам» дигән сүзен ишеткәч, үзе дә шул шәһәргә юл тота. Пешекче киемнәренә киенеп, Хидыр Фадил патша катына килә. Үзен яхшы пешекче буларак танытып, Җәүһәр таҗ белән никахланып, үз шәһәренә кайтырга юл ала. Синан шаһ бик зирәк, хикмәтле егет булып чыга – патша кызын төрле кыенлыклар аша үткәреп, яңа һөнәрләргә өйрәнергә мәҗбүр итә. Кыйсса ахырында егет «Сафаның[1] кадерен белмәссең дип, сиңа шундый эшләр кылдым» дип, Җәүһәр таҗга үзенең бу гамәлләренең сәбәбен аңлата. Әсәр шул рәвешле тәмамлана.

[1] Сафа – рәхәт.

Кыйссаның атамасы бары Җәүһәр таҗ исеме белән генә йөртелсә дә, әсәрнең төп геройлары – Җәүһәр таҗ кыз белән Синан патша. Бу яктан кыйсса ике төп геройлы романик дастаннарга охшаш. Шулай да әсәрнең тематикасы мондый төр дастаннардан бик нык аерыла. Биредә егет белән кыз арасында булган мәхәббәт хисләренә урын бирелми. Мәхәббәт сюжетына корылган дастаннарда геройлар ярату төшенчәсен тормыш мәгънәсе буларак кабул итсә, «Җәүһәр таҗ кыз» кыйссасы геройлары тормышка җитди күзлектән карый. Бу геройлар өчен яраткан кешенең тормышка әзерлекле, зирәк булуы бик мөһим. Тормыш иптәшен дә алар нәкъ шушы таләпләрдән чыгып сайлыйлар.

Кыйссаның төп идеясе китапның титул битендә язылган борынгы мәкальдә чагылыш таба:

*Мәшәкать чикмәгән адәм – сафаның кадерен белмәс,*

*Мәшәкать беләдер кем – грифтар улмаян[1] белмәс* [Кыйссаи Җәүһәр таҗ кыз хикәяте, 1897, б. 1].

Мәгънәсе: гомерен мәшәкать күрми үткәрүче адәм баласы рәхәтнең кадерен аңламас, фәкать күп михнәтләр кичергәнә генә мул, тыныч тормышның кыйммәтен белеп яшәр. Шул сәбәпле, алар, иң элек, бер-берсен кыенлыклар белән сыныйлар.

Кыйссада образлар системасы шактый җыйнак итеп бирелгән. Төп каһарманнарның берсе – Җәүһәр таҗ − әтисе Хидыр Фадилның яклавына сыенып, авырлыклардан имин булып үскән патша кызы. Җәүһәр таҗ һәм Синан шаһның «һөнәр» төшенчәсенә карашлары күпмедер дәрәҗәдә аерыла. Җәүһәр таҗ яучыларны борып җибәрүен түбәндәгечә аңлата: *...бән гаҗәпкә каламын, бу вакытга (вакытта) егетләргә: яучы йибәреп йөриләр, үзләренең һөнәрләре юк, – диде.* Синан шаһ һөнәрнең нәрсәдән гыйбарәт булуын сорагач, кыз: *Алтын каритәгә[2] алты артлы ат җигеп, ул егет үзе каритәгә утырып чабып, туры бәнем дворисемә килеп, баскычтан менеп, двориskә[3] кереп, бәнем янымга килеп утырса, бән шул егеткә барамын, – ди* [Кыйссаи Җәүһәр таҗ кыз хикәяте, 1897, б. 5].

Контексттан күренгәнчә, Җәүһәр таҗның идеаль егет образын күзаллавында балаларга хас беркатлылык сизелә. Шулай да кызны «фикерсез» дип әйтеп булмый. Әгәр кыйссаның башлам өлешендә төп героиня җир йөзендә байлыктан да кыйммәтрәк рухи төшенчәләрне бары белгән хәлдә генә яшәсә, кыйсса дәвамында авырлыкларны үз җилкәсендә татып караган, берничә төрле һөнәргә өйрәнгән булдыклы, сабыр хатын-кыз образы буларак формалаша.

Шунысы кызык, әгәр охшаш сюжетка корылган дастаннарда кызның матурлыгын тасвирлауга зур урын бирелсә, биредә геройларның кыяфәте бөтенләй тасвирланмый.

[1] Грифтар улмаян – дучар булмаган.

[2] Каритәгә – каретага.

[3] Двориskә – дворецка.

Синан патша, яшь булуына кармастан зирәк, максатчан герой буларак күзаллана. Алдан язылып үткәнчә, Җәүһәр таҗның шартын үтәп, аңа өйләнү бәхетенә ирешкәч тә, тукталып калмый – хатынын төрле кыен хәлләрдә калдырган булып, аны чын мәгънәсендә тәрбияли. Зирәк Җәүһәр таҗ үзе дә хәләл җефетенең бу адымыннан дөрес нәтиҗә ясап, шөкер итеп яшәвен дәвам итә.

«Җәүһәр таҗ кыз» кыйссасы – төрки эпик мотивларны һәм Борынгы Шәрык әдәбияты билгеләрен үз эченә алган әсәр. Сюжет тамырлары борынгы фольклор мотивына барып тоташкан баласызлык мотивы белән башланып китә. Бирედә Хидыр Фадил патша хатыны карынындагы баланың озын гомерле булуын теләп, җыелыш җыеп, бөтен вәзирләре каршында нәзер әйтә. Нәзер әйтү (итү) – берәр эш башкару алдыннан, ул эш уңышлы барып чыкса, кемгә дә булса берәр нәрсә бирергә яки берәр йөкләмә үтәргә үз күңелеңнән вәгъдә бирү [Нәзер: URL: https://tatar_explanatory.academic.ru/12867/%D0%BD%D3%99%D0%B7%D0%B5%D1%80]. Патшаның нәзер әйтеп, Аллаһ Тәгаләдән ярдәм көтүе – кыйссаның ислам дине белән тыгыз бәйләнешен күрсәтә. Шунысын әйтергә кирәк: «нәзер әйтү» – «вәгъдә» төшенчәсенә бик якын. Баласызлык мотивы урын алган романик характердагы дастаннарда ата кеше (гадәттә, хан яки падишаһ) кызын билгеле бер егеткә ярәшәчәге турында вәгъдә бирә. Тик иҗтимагый тигезсезлек нигезендә, падишаһ әйткән сүзләренә тугры калмый, нәтиҗәдә, әсәр фаҗигалы төстә тәмамлана. Әйтик, 1984 елда Арча районы Ишнарат авылында табылган кульъязмада моның ачык мисалы чагылыш таба. *Көн туып килгәндә, җыелып, сөйләшеп утыруда бер вәзир кереп: «Сүвенче, падишаһым!» – дип хәбәр бирде. Падишаһ әйтте: «Бунчә сүвенчедер» – диде. Вәзир әйтте: «И падишаһым, хатының угыл тугырды! Падишаһ әйтте: «Ир угланмы, йә кыз угланмы?» Вәзир әйтте: «Кыз угландыр!» – диде. Падишаһ сорады: «Аты ни торыр?». Вәзир әйтте: «Аты – Зөһрә дип атадылар!* [Әхмәтҗанов, 1989, б. 71].

Алга таба падишаһ вәзиргә, балалар киләчәктә дус һәм бергә үссеннәр өчен, улын алып килергә куша. Безнең фикеребезчә, падишаһның балаларның бергә үсүе, дуслашуы, ә киләчәктә өйләнешүе турында теләк белдерүе (ул малайның падишаһ нәселенең варисы булмавына карамастан) аның күңел киңлегеннән түгел, ә көткән баласын табудан килгән шатлык фонында ашыгыч, уйламыйча кабул ителгән карар булып тора. Билгеле булганча, Зөһрәнең кияүгә чыгу вакыты җиткәч, падишаһ вәзиргә биргән вәгъдәсен аңлы рәвештә үтәми. Шуңа күрә аның ниятенең җитдилегенә шик туа: падишаһ, мөгаен, беркайчан да үз кызы өчен хезмәтче улын тиң дип санамагандыр. Зөһрәгә ир итеп, әтисе бай Карамучны сайлый [Хусайнова, 2022].

«Җәүһәр таҗ кыз» кыйссасында баласызлык проблемасының дәвамы башка төрле борылыш ала. Тантаналы рәвештә барлык вәзирләре алдында нәзер әйткән Хидыр Фадил бирелгән вәгъдәсенә тугрылык саклый, шул рәвешле, кызга төрле җирлекләрдән яучылар ки-

леп, падишаһ каршына баскач, ата кеше 14 ел элек әйтелгән сүзләрен яучыларга да җиткереп, аларны Җәүһәр таҗ янына җибәрә.

Алда карап үтелгән дастан мисалыннан аермалы буларак, әлеге кыйсса геройларның бергә, бәхетле яшәп калулары белән тәмамлана. Бу урында шуңа игътибар итәргә кирәк, ата кешенең әйткән нәзеренә (вәгъдәсенә) тугры калуы вакыйгаларның үстерелешендә, ә бигрәк тә чишелешендә зур роль уйный. Әсәрләрнең ислам дине белән тыгыз бәйләнешен истә тоткан хәлдә, биредә вәгъдәгә тугрылыклы кала белү морале үткәрелә, дип нәтиҗә ясарга мөмкин.

Кыйссаның ислам дине белән бәйләнеше моның белән генә төгәлләнми. Текстта мөселман шәригатенә кагылышлы шактый күп төшенчәләр урын алган. Әсәрдә кич җитүен белдерү өчен «ахшамнан соң» сүзтезмәсе кулланыла. «Ахшам» мөселманнар тарафыннан кояш баткач укыла торган намаз буларак билгеле. Вакыт чигенең намаз вакытлары белән аталып йөртелүе дастан жанрына караган күпчелек әсәрләрдә киң таралу алган.

«Җәүһәр таҗ кыз» кыйссасының башлам өлеше күпмедер дәрәҗәдә фәнни әйләнешкә яңа гына килеп кергән «Дастане җайә» әсәре белән аваздаш. Бу ике сюжетта да кыз бала белән ата арасында булган ярату, кайгыртулы мөнәсәбәт чагылыш таба. Күпчелек кыйсса-дастаннарда кызның үзенә иптәш сайларга хокуксыз булып, бу мәсьәләне тулысы белән атасы башкаруын күрсәк, без караган әсәрләрдә, киресенчә, кыз балага «үзе сайлаган кешесенә» никахланырга мөмкинлек бирелә. «Дастане җайә» әсәренең башлам өлешен карап үтик:

*Рум шәһәренең патшасы Гасаран, балалары булмагач, Кәгъбәгә барып кырык корбан чалып, Аллаһы Тәгаләдән үзенә бала бирүне сорап ялвара. Аллаһы Тәгалә аның теләген кабул итә. Өенә кайтуына бер кызы дөньяга килә, аңа Мәликә дигән исем куя. Гаять акыллы, зирәк һәм чибәр бу кыз кебек белемле кеше булмый. Атасы кызын җир астында яшереп, 20 яшенә хәтле гыйлем өйрәтә. Кияүгә бирү вакыты җиткәч, кыз үзе кебек белемле кешегә генә чыгачагын шарт итеп куя* [Дастане җайә, ед. хр. 2221-Т].

Без караган мисалларда хатын-кызның үзенә хәләл җефет сайлавы белән беррәттән, аларның егетләр белән бер дәрәҗәдә гыйлемле, күп һөнәрләргә ия була алуларына басым ясала.

Кыйссаның тел-стиль үзенчәлекләренә килгәндә, әсәр гади, сөйләмә характерда язылган, тел-сурәтләү чаралары очрамый диярлек. Текстта сүзләр яки кушымчалар төшеп калу нәтиҗәсендә, җөмләнең мәгънәви бөтенлеге сакланмаган урыннар бар. Борынгы төрки, гарәп, фарсы теленнән кергән сүзләр иркен файдаланылган.

Кыйссада гарәп теленнән кергән *бәгъдә*[1], *хәмед*[2], *кадим*[3], *әүләд*[4] сүзләре берничә урында файдаланылган:

[1] Бәгъдә – шуннан соң.

[2] Хәмед – мактау.

[3] Кадим – иске.

[4] Әүләд – балалар.

Бәгъдә Синан шаһ үзе янә вәзирләренә чыгып әйтте: «Бән өч айлык сәфәргә чыгам».

*Кадим заманда Пишәвәр шәһәрендә бер мәшһүр байлык илән бер падишаһ бар иде...*

*Бу шаһның әүләде булмаганлыктан, күп хафа иде. Әүләде булса да, бер яшендән озакка калмыйлар иде.* Безнең фикеребезчә, бу борынгы сюжет телдән телгә сөйләнелеп яки күчерелеп йөртелә торгач, тел ягыннан шактый зур үзгәреш кичереп, гади сөйләмә тел белән язылган кыйсса буларак формалашкан.

Татарстан Республикасы Милли китапханәсендә сакланган «Җәүһәр таҗ кыз» кыйссасы – әдәбият һәм фольклор чигендә торучы борынгы кулъязма ядкәр. Кыйссада «дастан» жанры билгеләре чагылыш табу сәбәпле, әлеге әсәрне дастан тексты буларак кабул итү дә дөреслеккә туры килер иде. Сюжет кайчандыр индивидуаль иҗат буларак барлыкка килеп, соңрак, «авторсыз» әсәр булып формалашып, китап булып басылып чыккан. Әлеге фактлардан чыгып, кыйссада китабилык билгеләре урын алган, дип нәтиҗә ясарга мөмкин. «Җәүһәр таҗ кыз» кыйссасы рухи мирасыбызның зур өлеше язма хәлдә сакланып калуга ныклы дәлил булып хезмәт итә.

**Әдәбият**

*Мухаметзянова Л.Х.* Книжные дастаны поволжских татар: проблема «Границы» жанровых названий в народном творчестве // URL: https://cyberleninka.ru/article/n/knizhnye-dastany-povolzhskih-tatar-problema-granitsy-zhanrovyh-nazvaniy-v-narodnom-tvorchestve (мөрәҗәгать көне: 10.04.2024).

Татарская энциклопедия: [в 6 т.] / гл. ред. М.Х. Хасанов (т. 1–5); А.М. Мазгаров (т. 6); [отв. ред. Г.С. Сабирзянов]. Казань: Ин-т Татар. энцикл., 2002–2014.

Кыйссаи Җәүһәр таҗ кыз хикәяте. Санкт-Петербург: Чирков типографиясе, 1897. 15 б.

Нәзер [Электронный ресурс] // URL: https://tatar_explanatory.academic.ru/12867/%D0%BD%D3%99%D0%B7%D0%B5%D1%80 (мөрәҗәгать көне: 10.04.2024).

*Әхмәтҗанов М.* «Таһир белән Зөһрә»нең тагын бер билгесез кулъязмасы // Эзләнүләр, уйланулар, табышлар. Казан: Татар. кит. нәшр., 1989. Б. 67–72.

*Хусайнова Г.Р.* Взаимовлияние фольклора и литературы в татарских романических дастанах: дис. … канд. филол. наук: 10.01.02 и 10.01.09. Казань, 2022. 171 с.

Дастане жәйә // Отдел рукописей и редких книг Национальной библиотеки Республики Татарстан. Ед. хр. 2221-Т.

***Хөсәенова Гөлнирә Рәзиф кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, Татарстан Республикасы Милли китапханәсенең кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлеге хезмәткәре*

УДК 392+398

*Д.Р. Галиуллина*

# XIX ГАСЫРДА УФА ГУБЕРНАСЫНДА ЯШӘГӘН ТӨРКИ ХАЛЫКЛАРНЫҢ ГОРЕФ-ГАДӘТЛӘРЕ ТУРЫНДА
## (Казан университеты каршындагы Археология, тарих һәм этнография җәмгыяте хәбәрләре материаллары буенча)

В статье рассматриваются материалы по обрядовой традиции и народной медицине тюркских народов Уфимской губернии, опубликованные на страницах Известий Общества археологии, истории и этнографии при Казанском университете. Материалом для исследования послужили статьи С.М. Матвеева, священника, члена-сотрудника ОАИЭ (с 1896 г.) и Н.Ф. Катанова – учёного, председателя ОАИЭ (1898–1914, 1919 гг.), которые опубликовали результаты исследований разных лет по фольклору тюркских народов.

**Ключевые слова:** тюркские народы, фольклор, обряд, заговор, поверье.

The article reveals the customs of the Turkic peoples of the Ufa province published on the pages of the Proceedings of the Society of Archaeology, History and Ethnography at Kazan University. The paper analyzes the articles of N.F. Katanov who was a Russian Turkologist, ethnographer, folklorist, chairman of the SAIE (1898–1914, 1919) and S.M. Matveev, a priest, a member of the staff of the SAIE (since 1896), who in their materials publish the results of research from different years on the ritual folklore of the Turkic peoples.

**Keywords:** Turkic peoples, folklore, customs, spell, superstition.

Фольклористика – гасырлар дәвамында һәрдаим үзенең тарихына мөрәҗәгать итә торган фәннәрнең берсе. Бүгенге көндә рус фольклористикасы тарихы фәнни яктан җитәрлек дәрәҗәдә тикшерелгән булса да, татар фольклор фәнендә аның үсешенә анализ ясаган хезмәтләр бик аз [Каримуллин, 1999; Ямалтдинов, 2016; Ярми, 1967]. Бу өлкәдә үткәрелгән эзләнүләрдә фәнни юнәлешләр, аерым шәхесләр һәм аларның хезмәтләре игътибар үзәгенә алынса да, фольклористика фәненең үсешенә зур тәэсир ясаган һәм үткән гасырларга караган матбугат чараларында, фәнни оешмаларда даими басылып килә торган журналларда дөнья күргән мәгълүматлар исә махсус тикшеренүләрне таләп итә. Төбәк фольклоры фәнни әйләнешкә чагыштырмача аз җәлеп ителә, аерым алганда, губерна һәм епархия, фәнни җәмгыятьләр хәбәрләрендә, төрле губерналарның «истәлек китапларында», туган якны өйрәнү җыентыкларында һ. б. урнаштырылган текстлар бер ноктага тупланып, фәнни проблема җәһәтеннән өйрәнелми диярлек.

XIX гасыр ахыры – XX гасыр башында дөнья күргән мондый басмаларда Көнчыгышны өйрәнүчеләр, археографлар, этнографлар, тарихчылар татарларның һәм шул исәптән Россиядә яшәгән башка

халыкларның теле, тарихы, мәдәнияте өлкәсендәге мәгълүматларга таянып, фәнни терминологияне, алга таба алып барылачак тикшеренүләрнең базасын булдыру өлкәсендә беренче адымнарын ясыйлар. Әлеге юнәлештә эш алып барган мөһим басмаларның берсе булып, 1878 елда ачылган Археология, тарих һәм этнография җәмгыяте (алга таба – АТЭҖ) каршында нәшер ителгән «Археология, тарих һәм этнография җәмгыяте хәбәрләре» (алга таба – АТЭҖХ) тора. Җәмгыять тугандаш гуманитар дисциплина галимнәренең көчләрен туплауда һәм илебез халыкларын, шул исәптән Россия территориясендә гомер итүче төрки халыкларны фәнни өйрәнүне көчәйтүдә, гомумән алганда, төрки халыкларның этнографиясе өлкәсендә үткәрелгән тикшеренүләр кысасында фольклористика фәненең үсешендә зур роль уйный. Әлеге басмада Россиядә яшәүче төрки халыкларның теле, тарихы, традицион мәдәнияте буенча күптөрле материаллар дөнья күрә. Галимнәр, тикшеренүчеләр бу юнәлештә дәвамлы эш алып баралар, төрки халыклар яшәгән төрле төбәкләргә экспедицияләр оештырыла, махсус тикшеренү программалары төзелә, җыелган материаллар һәм алар нигезендә ясалган фәнни күзәтүләр һәрдаим дөнья күреп бара.

Этнография һәм фольклор өлкәсендә мәгълүмат җыю һәм эшкәртү белән төрле елларда үз заманының күренекле галимнәре шөгыльләнә, мәсәлән: С.К. Кузнецов, Г.Н. Потанин, В.А. Казаринов, В.К. Магницкий, Н.Ф. Катанов һ.б. Н.А. Фирсов һәм башка галимнәр тарафыннан фәнни тикшеренүләрнең махсус программасы эшләнә. Әмма этнографик һәм фольклор истәлекләрен җыючылар буларак еш кына Җәмгыятьнең әгъза-хезмәткәрләре (укытучылар һәм руханилар арасыннан) чыгыш ясый.

XIX гасыр ахырында төрки халыклар яшәгән төрле регионнар өйрәнелә, шул исәптән татар һәм башкорт халкы көн күргән Уфа губернасы да игътибар үзәгенә алына. Әлеге территорияне үз эченә алган эзләнүләр 1895 елның җәендә Казан университеты каршындагы АТЭҖ рәисе Н.Ф. Катанов тәкъдиме буенча башланып китә. Уфа губернасының Бәләбәй өязе Дияш авылы рухание Степан Матвеевич Матвеев тарафыннан Уфа губернасында яшәүче керәшеннәрнең рухи мәдәнияте буенча материаллар җыю башлана. Шулай ук Н.Ф. Катанов үзе дә 1897–1898 елларда Уфа губернасының Бәләбәй өязендә булып, татарларда һәм башкортларда таралыш тапкан дәвалау ысулларын туплый. 1895–1899 елларда АТЭҖХ битләрендә басылган мәкаләләр циклы бу эшнең нәтиҗәсе булып тора.

С.М. Матвеев эзләнүләре барышында Уфа губернасының Минзәлә һәм Бәләбәй өязләрендәге утыздан артык торак пунктында була. Әлеге сәфәр нәтиҗәләре нигезендә АТЭҖХнең XIII томында «Свадебные обычаи и обряды крещёных татар Уфимской губернии» дигән мәкалә басылып чыга. Әлеге мәкаләдә туй йоласының, яучылаудан башлап, кияүнең кыз йортына кунакка төшүе белән тәмамлана торган һәр этабы җентекләп тасвирлана.

Әлеге урынчылыкта таралыш тапкан туй йоласы, нигездә, бүгенге көндә сакланып калган традиция белән туры килә. XIX гасырда туй, җиденче гыйнвардан алып Олы ураза (Великий пост) башланганчы үткәрелгән һәм еш кына берничә атна дәвам итә торган булган. Беренче этап – яучылау, ягъни яучы (*җаучы)* билгеләүдән башланып киткән. Билгеле булганча, яучылар кәләшнең әти-әнисе янына алдан сөйләшү-киңәшләшү өчен җибәрелгән. Еш кына яучыларга кәләш йортына берничә кат килергә туры килгән, чөнки кәләшнең туганнарына да, үзенә дә билгеле бер карарга килү өчен вакыт бирелгән. Шунысы кызыклы: С.М. Матвеев әйтүенә караганда, соңгы сүзне кәләш әйткән, әти-әнинең мәҗбүр итүе аркасында никахлашуны җәмәгатьчелек гаепләп чыга торган булган.

Әлеге сөйләшүләр барышында ике гаилә дә *калым* һәм *бирнәнең* күләме турында уйлана. Әгәр кәләш һәм аның туганнары тарафыннан кияү хупланса һәм бүләкләрнең күләме буенча үзара килешү булса, алдагы очрашуга кәләш йортына яучы кияүнең туганнарын да алып килә. Аш вакытында яучылар әти-әниләрдән кәләшнең шушы кияү белән никахлашырга әзер булу-булмавын сорыйлар. Кәләш тә очрашуда катнаша, әмма кеше күзенә күренми, чаршау артына яшеренә. Әти-әнисенең соравын җавапсыз калдырса, бу аның ризалык бирүен аңлата. Шуннан соң кәләш әнисе яки килен аша кияүгә дигән бүләкләрен тапшыра. Бүләкләр үзләре – *ак,* ә бу йола *аклашау* дип атала. Бу вакыйгадан соң биш яисә ун көн үткәннән соң, аларның ярәшүләре *(җәрәшү)* турында игълан ителә [Матвеев, 1895].

Ярәшүдән алып туйга кадәр (ун көннән алып, ике айга кадәр) дәвам иткән икенче этапта кәләш кияү һәм аның туганнары өчен бүләкләр һәм үзенә киемнәр әзерли. Киленгә еш кына дуслары һәм туганнары ярдәм итә. Кияү бу вакытта кәләш өчен өске кием, тун, җилән һәм аяк киеме әзерләү белән шөгыльләнә. Бу әйберләр тупланып беткәннән соң, кияү аларны кәләшенә илтеп бирә һәм әти-әнисе сайлаган туй көнен атый [Матвеев, 1895].

Өченче этап – кәләш йортындагы туй. Кияү белән кәләшнең әти-әниләре һәр ике яктан иң якын туганнары арасыннан 2–3 гаиләне сайлап ала. Алар туйны оештыруда актив катнашалар, бу очракта матди чыгымнарны күтәрешү дә күздә тотыла. Һәр йорт каршы яктан килгән кунакларны чират буенча кабул итәргә тиеш була. Иң элек кунаклар кәләш йортына төшәләр, бүләкләр алмашалар, мәҗлес үткәрәләр. 5–6 сәгать дәвам иткән мәҗлестән соң, кодалар кәләшнең туганнары ягыннан беренче йортка һәм шулай тәртип буенча калганнарына китәләр. Һәр йортта кунаклар берничә сәгать мәҗлестә утыра, тәүлеккә якын йөреп, туй кортежы кәләш йортына әйләнеп кайта.

Бу вакытка кәләшнең барлык туганнары кәләшне озату йоласына чакырыла. Иң яхшы киемнәрен кигән кызны аның кыз туганнары һәм дуслары чолгап ала, алар аерылышу турында моңсу җырлар җырлыйлар:

*Оло жулнын такыры,*
*Кӧмӧш акчанын бакыры…*
*Айырылмабыз дигян эйек,*
*Айырылышабыз акыры…*

*Оло жулнын буйында*
*Сыуырылыб ӱся бер жыуа;*
*Жылашмагыз кызлар жырлашыгыз,*
*Айырылыша торган бер жола.*

*Ишек алды шау нарат,*
*Ник шаулый икян бер нарат;*
*Шауламасыйы ул нарат,*
*Айырылыб китя бер канат.*

*Бура да бура ак борчак,*
*Тюкмей чячмей тотогыз;*
*Инде бездян айырыла,*
*Какмый, сукмый тотогоз...* [Матвеев, 1895].

Кызның әти-әнисе фатиха биргәннән соң, кәләшне япма белән каплыйлар, кодалар янына чанага утырталар һәм туган-үскән йортыннан алып чыгып китәләр. Кәләшнең туганнары һәм якыннары туй кортежын басу капкасына кадәр озата бара. Яшьләр исә чиркәүгә китә. Чиркәүдән соң кәләшне *кыяматлык*[1] йортына алып китәләр һәм аның хатыны кулына тапшыралар. Биредә яшь хатынның кашларын, чигә һәм маңгай чәчләрен йолку йоласы башкарыла. Аннары кәләш юына һәм *кыяматлык ана* ярдәмендә яшь килен киемнәрен кия. Шул рәвешле киенгән кәләшне кияү йортына алып китәләр, анда *килен керту* йоласы үтәлә. Көн мәҗлес белән тәмамлана [Матвеев, 1895].

Икенче көнне кияү өенә кәләш ягыннан кодалар килә, һәм кәләш йортында башкарылган йолалар циклы тулаем кабатлана. Кодаларны озатканнан соң, икенче көнне иртән кияү йортында *килен токмачы* пешерелә. Кияүнең туганнары кунакка чакырыла, алар килүгә токмач һәм пилмән әзерләнә.

Туй тантаналарына нокта куйган соңгы йола – *кияу кайтармасы*. Туйдан соң 2–3 атна үткәч, яшьләр бабай (иргә карата хатынның атасы) йортына кунакка киләләр. Бу очрашу шул ягы белән үзенчәлекле: бабасы йортына кергәч, кияү өстәлгә тәңкә яки яулык куярга тиеш була, шуннан соң ул хатынының туганнары арасында үз кешегә әйләнә [Матвеев, 1895].

Шулай итеп, С.М. Матвеев мәкаләсендә туй йоласы комплексы системалы рәвештә тәкъдим ителә, аның терминологиясе, сүз компоненты, йола вакытында башкарылган гамәлләр барысы да тәфсилләп

[1] *Кыяматлык* (гарәп теленнән кергән кыямәт сүзеннән ясалган) – гаиләнең никахына кыямәт көнендә (ягъни үлеп яңадан терелгәч) шаһит булып торырга тиеш дип исәпләнгән. Кыяматлыкка кияү ягыннан туган тиешлерәк хатын-кыз һәм аның ире сайлап алына. Ул гомер буе бу ир белән хатынның иң ышанычлы дусты, киңәшчесе һәм таянычы булырга тиеш.

тасвирлана. Бу материаллар туй йоласының XIX гасырда үткәрелү рәвешен өйрәнү өчен генә түгел, ә бәлки әлеге йола комплексының тарихи үсеш-үзгәрешен дә күзәтергә мөмкинлек бирә.

С.М. Матвеевның чираттагы күләмле мәкаләсе 1899 елда гына дөнья күрә, чөнки бу вакытта ул Минзәлә өязеннән Уфа губернасының Бәләбәй өязенә күчена. Аңа кадәр Степан Матвеевич 1897 елда «Гадание, посредством веретена у крещёных татар Уфимской губернии» дигән кыска гына язма бастыра, анда эшнең уңышлы яки уңышсыз чыгуына бәйле күрәзәлек итү процессы тасвирлана [Матвеев, 1897].

1899 елда нәшер ителгән XV томда ул «Погребальные и поминальные обряды крещёных татар Уфимской губернии» мәкаләсен тәкъдим итә. Туй йолалары турындагысыннан аермалы буларак (анда барлык тантаналар этаплап тасвирлана), бу материал тормыштагы хорафатларга һәм ышануларга нигезләнгән төрле хикәяләр белән баетылган. Керәшеннәрдә җирләү өчен кирәкле барлык әзерлек эшләренең православие традицияләренә туры китереп башкарылуы – билгеле күренеш. Әмма соңгы юлга озату йолалары вакытында актуальләшкән ышанулар, нигездә, татар халкының гомумтрадициясендә таралыш тапкан ышанулар системасы белән тәңгәл килә. Мәсәлән, үлгән кешенең җанына тәннән чыгу җиңелрәк булсын өчен, аңа кашык белән су бирү гадәте булган һәм бүгенге көндә дә гамәлдә. Татарлар күзаллавы буенча, әгәр бу эш эшләнмәсә, суны шайтан бирәчәк һәм кешенең җанын үзенә алачак. Татарларның төрле этник төркемнәре арасында җанның кешедән күбәләк кыяфәтендә чыгуына ышану керәшеннәрдә дә булып, җанның мич басмасына менеп утыру формасын алган. Керәшеннәрдә үлеме якынлашкан кешеләрне, аларның үтенече буенча, ишегалдына алып чыгу традициясе дә кызыклы, бу гамәл – кеше йорты белән хушлаша алсын өчен эшләнгән, югыйсә аның җаны тәннән чыга алмый интегәчәк, дип ышанганнар [Матвеев, 1899].

С.М. Матвеев мәкаләсендә шулай ук турыдан-туры үлемгә кагылышлы ышанулар да бәян ителә. Мәсәлән, автор кешенең тирән йокыга, ягъни *мәрткә киту* кебек халәтенә зур игътибар бирә. Керәшеннәрдә мәрткә киткән кешеләр теге дөньяның серләрен ача ала торган изгеләр дип саналган. Степан Матвеевич мисалга тумышы белән Минзәлә өязе Сәвәләй авылыннан[1] булган Федот Леонтьев хикәясен китерә, әмма үзе үк аның дөреслегенә шикләнеп карый. Аның өчен шунысы мөһим: әлеге текстлар керәшеннәрнең теге дөнья турындагы күзаллауларын чагылдыра һәм күпләр мондый хикәяләрне реаль чынбарлык дип кабул итә. Әлеге территориядә таралыш тапкан бу хикәяләрне уртак сюжет берләштерә. Зират астында авыл урнашкан, анда һәр үлгән кеше өчен йорт әзерләнгән, әгәр йорт якты һәм чиста икән, димәк, бу кеше тәкъвалык белән яшәгән, әгәр йорт тузган һәм каралмаган булса, кешегә җаны турында уйлый башларга һәм, тәүбәгә килеп, гөнаһларын ярлыкауны сорарга кирәк. Мондый авылларның

---

[1] Хәзерге Татарстан Республикасы Зәй районы Сәвәләй авылы.

читендә казаннар торган, аларда гөнаһлары зур булган кешеләрне пешергәннәр яки «җәһәннәм»дә авыр эш башкарырга мәҗбүр иткәннәр [Матвеев, 1899].

Уфа губернасында яшәүче керәшеннәрнең күмү йолалары структурасында үлгән кешене искә алу мәҗлесләре аерып күрсәтелә. Үлгәннең өченче *(өчесе – третины),* җиденче *(җидесе – седьмины),* кырыгынчы *(кыркы – сорочины)* көннәрендә, бер ел узгач *(елы, аш уздыру)* үткәрелә торган искә алу мәҗлесләре беренче төргә керә. Һәр пәнҗешәмбе *(кече-атна, атна-кич), Симек көндә* (Кичерешү көне алдыннан килгән пәнҗешәмбедә) *Пукрауда* (Покрау), *Уле чыккан көндә* (әрвахлар чыгу көне, азап атнасында пәнҗешәмбе көнне билгеләп үтелә) исә гүр иясе булган туганнарның барысы да искә алына.

Үлем-күмү йолалары турында сүз алып барганда, С.М. Матвеев шулай ук йола фольклоры үрнәкләрен дә китерә. Мәсәлән:

*Минем атым кюк журга*
*Менеб китте тауга ӱргя;*
*Кюзебез туя кюрмей калдык,*
*Кереб китте, туганай, тар гюргя.*

*Без жӧрӧйбез ат белян,*
*Ауыр булмаса ыйы ӱрляре;*
*Ӓтекяй безгя бахиллек бирде,*
*Тар булмасын жаткан гюрляре.*

*Кюккя меняр эйем бачкыч жук,*
*Менгяч тӧшяргя чылбыр жук,*
*Сагынсак ничек итейек,*
*Барыб кюрешергя жола жук* [Матвеев, 1899].

Мәкаләнең ахырында Степан Матвеевич үлем килүен белдергән сынамышларны һәм төш юрауларны терки. Мәсәлән, тавык әтәч булып кычкырса; тавыкның койрык ягына салам бөртеге иярсә; кибән яисә чүмәлә ишелсә, үлемгә юраганнар. Төштә яңа бина төзү; агач кисү, бал яисә ит ашау; чаң тавышын ишетү дә үлем турында хәбәр иткән.

1900 елда АТЭҖХнең XVI томында, С.М. Матвеевның керәшеннәр турындагы мәкаләләр циклының дәвамы буларак, Николай Федорович Катановның «Народные способы лечения у башкир и крещённых татар Белебеевского уезда Уфимской губернии» дигән мәкаләсе басыла, анда әлеге ике халыкның төрле авыруларын дәвалау ысулларына чагыштырма анализ ясала, аларның берничә төре аерып күрсәтелә: берсе дин күрсәтмәләренә нигезләнсә, икенчесе – кешенең тормыш тәҗрибәсенә һәм өченчесе мифологик ышануларга таянып барлыкка килә дип билгеләнә.

Н.В. Катанов фикеренчә, башкортларда авыру барлыкка килүнең төп сәбәпчесе явыз рухлар булганга күрә, кешенең саулыгына зыян китермәү ысуллары да әлеге мифологик персонажларның гамәлләре

белән бәйләп карала. Мәсәлән, кич белән җиргә егылырга ярамый, юкса егылган кеше өстенә я йорт иясе, я абзар иясе утырачак та, бу кеше авырый башлаячак. Зиратта, бигрәк тә мәетне җирләгәннән соң, йөрергә ярамый, чөнки анда кешеләрнең җаннарын утка яга торган сихерче утыра һ.б. [Катанов, 1900].

XIX гасыр ахырында яшәгән башкортларның бизгәк чирен дәвалау ысуллары да кызыклы:

– явыз рухны куып җибәрү өчен, йоклап яткан кешенең өстенә салкын су сибәләр (чөнки бизгәк үзе – явыз рух ул);

– курчак ясыйлар (хатын-кызга – малай курчак, ир-атка – кыз курчак), аны авыруга бәйләп куялар, һәм бизгәк, курчакны кеше дип уйлап, аңа күчкәнче, бер-ике көн тоталар. Аннан курчакны ташлыйлар, кеше савыга;

– ярканатның канатларын кисеп, тукымага төрәләр һәм күлмәк астына тыгып куялар. Бизгәк, ярканаттан куркып, кешедән чыгып китә. Керәшеннәрдә дә моңа охшаш чара кулланылган [Катанов, 1900].

Кызганычка каршы, Н.Ф. Катанов бу мәкаләсендә башкортларның дәвалау ысулларына артык игътибар бирми, чөнки элегрәк «Деятель» журналында чыккан (1898) «Врачебные средства у башкир» язмасын шуларга багышлый. Шул ук вакытта ул бу мәкаләсендә Казан татарларының төрле авыруларга каршы кулланылган догаларны дистәләрчә мең данәдә бастыруларын ассызыклый һәм, күрәсең, шуңа күрә дә аларны бу мәкаләсенә кертми.

Н.Ф. Катанов билгеләвенчә, керәшеннәрдә дә мифологик ышануларга нигезләнеп барлыкка килгән авырулар зур урын алып тора, шуңа мисал итеп, ул үзенең мәкаләсендә авыруларны кисәтү максатыннан кулланылган гамәлләрне китерә. Мәсәлән, кыр эшләре вакытында буразнага да, ызанга да ятып йокларга ярамый, югыйсә авырып китүең ихтимал. Берәр кешенең балалары еш авырса яисә үлеп торса, алар озак яшәсен өчен, бала сату йоласын үткәргәннәр. Моның өчен баланы тәрәзә аша атасына биреп: «Бала сатам! Аласыңмы?», – дип сораганнар. Ата кеше баланы «сатып бирүче» әбигә өч яисә биш тиен түләгәннән соң, йорт иясе баланы башкача азапламый дип ышанганнар [Катанов, 1900].

Галим күрсәтүенчә, керәшен татарларында еланнар ярдәмендә дәвалау ысулларын да еш очратырга мөмкин, чөнки алар кайбер авыруларны еланнар патшасы җибәрә дип ышанганнар. Мәсәлән, күз авыртуын авыруның күзләренә елан тиресе бәйләп дәвалаганнар һәм җиде тапкыр: «Алла исеме белән, түгәрәк елан, бакыр елан, синнән китүеңне сорыйм! Әгәр дә китмәсәң, сиңа миннән эләгәчәк!» – дип кабатлаганнар. Авыру елан тиресенә күчкән һәм кеше терелгән. Авыру кеше, бизгәктән котылсын өчен, аның куенына көтмәгәндә яңа үтерелгән елан салганнар, авыру, бик нык куркып, терелгән, чөнки бизгәк рухы еланнар патшасы рухыннан курка дип саналган [Катанов, 1900]. Шул рәвешле, Н.Ф. Катанов хезмәтендә ике халыкта да кулланылышта булган дәвалау ысулларының уртак һәм аермалы яклары

күрсәтелә. Шул ук вакытта бүгенге көндә дөнья күргән материаллар белән чагыштыру [Давлетшина, 2022] Николай Федорович язып алган ышану һәм йолаларның күбесе өлешчә булса да саклана һәм татар халкының башка этник төркемнәрендә дә шул ук формада гамәлдә йөри, дип әйтергә мөмкинлек бирә.

Күрүебезчә, Уфа губернасында яшәгән төрки халыкларның гореф-гадәтләренә багышланган мәкаләләр циклы традицион мәдәниятнең төрле өлкәләренә карый һәм этнографик мәгълүматлар белән беррәттән фольклор материалларын да системалы рәвештә тәкъдим итүгә нигезләнә. Әлбәттә, биредә китерелгән язмалар галимнәр башкарган эшнең бер өлеше генә. Казан университеты каршындагы АТЭҖ әгъзалары региональ этнографик тикшеренүләр алып барганга күрә, бу аларга әлеге төбәкләрдә яшәүче төрки халыкларның көнкүрешен, мәдәниятен, фольклорын өйрәнергә, аларның традицион мәдәниятен киң җәмәгатьчелеккә җиткерергә мөмкинлек биргән. Тикшеренүләр этнография кысаларында алып барылуга карамастан, биредә фольклорның төрле жанрлары (тыюлар, җырлар, ышанулар, им-том итү һ.б.), шулай ук бүген фольклористика эчендә каралган йолаларның тасвирламалары да урын алган. XIX гасыр ахыры – XX гасыр башы галимнәре материал җыеп кына калмаганнар, ә үз эшләренең нәтиҗәләрен АТЭҖХ битләрендә дә бастырганнар, бу журналны кыйммәтле чыганак иткәннәр. Бу эш аларга гына түгел, төрки халыклар мәдәнияте белән кызыксынган барлык галимнәргә дә чагыштырма тикшеренүләр үткәрү мөмкинлеге бирә һәм бүгенге көндә дә үзенең әһәмиятен югалтмый.

**Әдәбият**

*Давлетшина Л.Х.* Современная татарская проза в контексте актуальной мифологической традиции: монография. Казань: ИЯЛИ, 2022. 312 с.

*Катанов Н.Ф.* Народные способы лечения у башкир и крещённых татар Белебеевского уезда Уфимской губернии // ИОАИЭ. 1900. Т. XVI. Вып. 1. С. 1–14.

*Каримуллин А.Г.* Татарский фольклор: Аннотированный указатель литературы 1612–1981. Казань: Таткнигоиздат, 1993. Ч. 1. 134 с.; Ч. 2. 134 с.

*Матвеев С.М.* Гадание посредством веретена у крещеных татар Уфимской губернии // ИОАИЭ. 1897. Т. XIV. Вып. 3. С. 365.

*Матвеев С.М.* Погребальные и поминальные обряды крещёных татар Уфимской губернии // ИОАИЭ. 1899. Т. XV. Вып. 3. С. 242–272.

*Матвеев С.М.* Свадебные обычаи и обряды крещеных татар Уфимской губернии // ИОАИЭ. 1895. Т. XIII. Вып. 5. С. 317–353.

*Ямалтдинов И.И.* Татарская фольклористика 20–60-х гг. XX века. Собирание, публикация и научное изучение фольклора. Казань: ИЯЛИ, 2016. 184 с. (Сер. «Библиотека журнала «Фәнни Татарстан»; 8-я кн.).

*Ярми Х.* Татар халкының поэтик иҗаты; СССР ФА. Г. Ибраһимов исем. ТӘТИ. Казан: Татар. кит. нәшр., 1967. 308 б.

***Галиуллина Диана-Мария Рәшит кызы,***
*ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты аспиранты*

УДК 93/94

***Р.Р. Ибраһимов,***
***Г.М. Габделхакова***

# ТАТАРСТАН ҺӘМ КЫРГЫЗСТАН АРАСЫНДА МӘДӘНИ-ИКЪТИСАДИ ЭЛЕМТӘЛӘР

Статья посвящена истории и современным тенденциям в татарстанско-киргизских отношениях. Авторами публикации рассмотрены этапы установления культурно-экономических связей между татарами Волго-Уралья и народами Центральной Азии. Выявлены факторы, обусловившие актуальность торгово-экономических и культурных связей между Татарстаном и Киргизией в конце XX – начале XXI в., показаны механизмы их выстраивания и формы реализации.
**Ключевые слова:** Татарстан, Киргизия, культура, экономика, татарская диаспора, межрегиональные связи.

The article is devoted to the history and modern trends in Tatarstan-Kyrgyz relations. The authors of the publication examined the stages of establishing cultural and economic ties between the Tatars of the Volga-Ural region and the peoples of Central Asia. The factors that determined the relevance of trade, economic and cultural ties between Tatarstan and Kyrgyzstan at the end of the 20th – beginning of the 21st centuries are identified, the mechanisms of their construction and forms of implementation are shown.
**Keywords:** Tatarstan, Kyrgyzstan, culture, economy, Tatar diaspora, interregional relations.

Татарстан белән Кыргызстан арасындагы мөнәсәбәтләрнең бай тарихы бар. Кыргызстан Республикасы территориясендә татарлар XIX гасырның беренче яртысында яши башлыйлар. Бу чорда күченеп килүчеләр арасында сәүдәгәрләр, тәрҗемәчеләр, муллалар күп була. Күченүчеләр агымы XIX гасырның 60–70 нче елларыннан, Урта Азия Россия империясе составына кергәч, шактый арта. XX гасыр башында татарлар Сөлүктә күмер карьерларында, Ошның эре сәүдә йортларында, Пишпәкнең сәнәгать предприятиеләрендә һ.б. эшлиләр. XIX гасыр ахыры – XX гасыр башында татарлар Урта Азия халыкларының милли мәдәниятен һәм мәгарифен үстерүгә зур өлеш кертәләр [Бартольд, с. 169]. Күченгән татарларның балалары бу төбәктәге җәдит мәдрәсәләрдә белем алалар (мәсәлән, Пржевальскида татар мәктәбе эшләгәнлеге билгеле) [Мурадымов, с. 62].

1917 елгы революция һәм аннан соңгы Гражданнар сугышы вакыйгалары Урта Азия төбәгендә татар диаспорасы формалашуда мөһим этап булып тора. Тарихчы, этнограф А.Р. Бикбулатова сүзләренә караганда, «татарлар Кыргызстанда совет власте урнаштыруда актив катнашканнар» [Бикбулатова, с. 72]. Гомумән, совет чорында татарларның Кыргызстанга күчеп килүләре Бөек Ватан

сугышы һәм 1950–1980 елларда бу төбәктә яңа сәнәгать объектлары төзелеше белән дә бәйле.

Совет дәүләте тарихында 1980 еллар ахыры җәмгыять тормышының барлык өлкәләре дә диярлек кризис кичерү белән характерлана. Социаль-икътисади проблемалар кискенләшү һәм үзәк хакимиятнең көчсезләнүе аркасында милли мәсьәләләр өлкәсендә дә тискәре тенденцияләр күзәтелә башлый. Шуңа бәйле рәвештә СССРның күп кенә милли республикаларыннан халыклар тарихи ватаннарына әйләнеп кайта башлый. Бу күренеш Кыргызстан татарларына да хас иде. Шул ук вакытта, билгеле булганча, әлеге катлаулы чорда Кыргызстан җитәкчелеге үзләрендәге татарларның милли-мәдәни яшәеше өчен уңай шартлар тудырырга тырыша.

1980–1990 елларда илебездә милли-мәдәни өлкәдә яңалыклар күп була. Яңа күренешләр халыкның туган теленә, тарихына, мәдәниятенә кызыксынуы артуда, урыннарда милли-мәдәни үзәкләр оешуда чагылыш таба. Мондый процесслар Кыргызстанның татар диаспорасына да хас. Мәсәлән, бу чорда Бишкәк шәһәрендә «Туган тел» татар-башкорт милли-мәдәни үзәге, Ош шәһәрендә «Илкәем» татар-башкорт милли үзәге оештырыла.

Шунысын да билгеләп үтәргә кирәк, бу чордан башлап Кыргызстандагы татар диаспорасы белән мәдәният өлкәсендәге хезмәттәшлекне Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитеты алып бара. Ул Кыргызстан татарларын үзләренең тарихи Ватаннары белән бәйләүче мөһим үзәк булып тора.

Совет дәүләте таркалу элеккеге СССР республикалары өчен принципиаль яңа үсеш моделен формалаштыруга юл ача. Шул рәвешле, элекке милли республикалар тышкы икътисади эшчәнлекләрен мөстәкыйль алып бара башлый. Яңа шартларда федераль үзәктән шактый гына вәкаләтләргә ия булган Россия субъектлары хакында да шуны ук расларга мөмкин. Әлеге шартларда көчле сәнәгать базасы булган Татарстанның үзенең тышкы икътисади потенциалын тормышка ашыру өчен дә зур мөмкинлекләр ачыла.

Кыргызстан Татарстан өчен үтә перспективалы икътисади-сәүдә партнёры булып тора. XX гасыр башында әлеге төбәк белән икътисади яктан ныклы бәйләнеш, нигездә, аграр өлкә булса, совет чорында исә 300 дән артык сәнәгать предприятиесе һәм электр станциясе сафка кертелә, яңа промышленность тармаклары булдырыла. Гомумсоюз хезмәт бүленешендә Кыргызстан төсле металл (сөрмә, терекөмеш), авыл хуҗалыгы машиналары, электротехник әйберләр һәм приборлар, йон һәм ефәк тукымалар, шикәр комы, төзелеш материаллары һ.б. җитештерүче өлкә буларак катнаша, шулай ук анда металл кисү станоклары, машина төзелеше өчен автомат линияләр, медицина приборлары җитештерү дә шактый үсеш ала [Киргизия].

1993 елның 18 декабрендә Кыргызстан һәм Татарстан республикалары арасында сәүдә-икътисади, фәнни-техник һәм мәдәни хезмәттәшлекнең төп принциплары турында килешүгә кул куела.

Бүгенге шартларда, Россия белән Көнбатыш илләр арасында хәлнең катлаулануы сәбәпле, Россия һәм аның төбәкләренең тышкы икътисади эшчәнлегендә Азия илләре, шул исәптән Кыргызстан Республикасы да әһәмиятле урын алып тора. Бу уңайдан ике дәүләт арасында, шулай ук федерация субъектлары дәрәҗәсендә дә, сәүдә-икътисади һәм фәнни-мәдәни элемтәләрне көчәйтү максатын күздә тотып, Россия һәм Кыргызстан арасында хөкүмәтара элемтәләр шактый көчәйде. Бу өлкәдә татар һәм кыргыз мәдәниятләренең якынлыгын һәм туганлыгын, ике арадагы сәүдә-икътисади һәм мәдәни элемтә традицияләрен исәпкә алып, Татарстанга зур роль бирелә.

Бу уңайдан, 2015 елның мартында Бишкәк шәһәрендә Татарстан министрлыклары һәм ведомстволары җитәкчеләре, «КАМАЗ», «Казан вертолёт заводы», «Серго исемендәге завод», «Гипронииавиапром», «Инвент», «Эйдос» кебек әйдәп баручы компания вәкилләре, шулай ук югары технологияләр өлкәсендәге технопарк – IT-парк, Татарстан мәгариф учреждениеләре катнашында «Кыргызстан-Татарстан» бизнес-форумы узды. Кыргызстанга Татарстан делегациясе визитының максаты «сәүдә-икътисади, фәнни-техник һәм мәдәни хезмәттәшлекне киңәйтү»дән гыйбарәт иде. Татарстан делегациясен җитәкләгән Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов сүзләренә караганда, әлегә «ике як та булган потенциалны тулысынча кулланмый» [Рустам Минниханов...]. Бизнес-форумда энергетика, автомобиль һәм вертолёт төзелеше, нефть химиясе, автокомпонентлар җитештерү үзара хезмәттәшлекнең өстенлекле юнәлешләре дип билгеләнә. Әлеге чарада катнашкан Татарстанның сәнәгать потенциалын тәкъдим итеп чыгыш ясаган Премьер-министр урынбасары – Татарстан Республикасы сәнәгать һәм сәүдә министры Р.Х. Зарипов фикеренчә, Татарстанга Кыргызстанның җиңел сәнәгатьне үстерү тәҗрибәсе кызыклы. «Кыргызстанда тегелгән кием-салым югары сыйфатлы, һәм, нигездә, ул Россиягә экспортлана. Без сезнең бу өлкәдәге тәҗрибәгезне өйрәнергә теләр идек», – диде ул. Равил Зарипов шулай ук Татарстан делегациясенең Кыргызстан ирекле икътисади зоналарында салым һәм таможня ташламаларының ничек эшләве белән кызыксынуы хакында әйтте [Рустам Минниханов...].

Кыргызстанның энергетика һәм сәнәгать министры урынбасары А.Р. Калиев үзләрен Татарстанның машина төзелеше өлкәсенә кагылышлы проектлар кызыксындыруын ассызыклады [Рустам Минниханов...].

2021 елның ноябрендә ике яклы сөйләшүләрдән соң Р.Н. Миңнеханов һәм Кыргызстан Хөкүмәте Рәисе урынбасары А.Р. Калиев «Татарстан – Кыргызстан» эшлекле форумында катнаштылар. Анда ике республиканың иң эре предприятиеләре вәкилләре җыелды. Форумда катнашучыларны сәламләп, Татарстан Республикасы Президенты 2020 ел нәтиҗәләре буенча Татарстан белән Кыргызстан арасында товар әйләнеше 41 млн доллар тәшкил итүен билгеләп үтте. Бу күрсәткечне тагы да арттыру өчен, Р.Н. Миңнеханов товарлар белән тәэмин

итү һәм хезмәт күрсәтү күләмен арттыру мәсьәләләре буенча активлыкны арттырырга тәкъдим итте. Ул билгеләп үткәнчә, Татарстанны Кыргызстанга күбрәк нефть химиясе продукциясен, авыл хуҗалыгы техникасын, компрессорлар һәм суыткыч җиһазларын, автомобиль шиннарын, көнкүреш химиясен һәм башка товарларны җибәрүне киңәйтү кызыксындыра.

А.Р. Калиев, үз чиратында, Кыргызстанның гидроэнергетика, «КАМАЗ» автотехникасы һәм башка машина төзелеше продукциясе белән аеруча кызыксынуын белдерде. Вице-премьер Кыргызстанда Татарстан бизнесы өчен уңайлы шартлар тудырылачак, дип ышандырды.

Форум нәтиҗәләре буенча берничә килешү имзаланды; аерым алганда, «КАМАЗ» тышкы сәүдә компаниясе җитәкчелеге «ШЫДЫРЖОЛ KG» компаниясе белән лицензия килешүе төзеде. Ул Кыргызстанда газ ягулы түбән төпле «КАМАЗ» автобуслары җитештерүгә кагыла. Җыю производствосын Токмак шәһәрендә җайга салу планлаштырыла [Бизнесмены Татарстана...].

Р.Н. Миңнеханов Бишкәк шәһәренә эшлекле сәфәре вакытында язучы Чыңгыз Айтматовның «Ала-Арча» дәүләт резиденциясендә урнашкан музей-йортында булды. Анда язучының шәхси әйберләре, кульъязмалары саклана. Экспозициянең бер өлеше Ч. Айтматовның эшчәнлеген бәяләп тапшырылган күпсанлы бүләкләргә багышланган. Татарстанлылыр музейга архив документлары – Кукмара районыннан Ч. Айтматовның әнисе ягыннан ата-бабалары – Үтәмешевлар нәселенең шәҗәрәсен бүләк итте [Бизнесмены Татарстана...]. Татарстан Республикасы Президенты шулай ук Казан федераль университетының Кыргызстандагы Мәгарифне үстерү үзәге эшчәнлеге белән танышты.

Татарстан белән Кыргызстан арасындагы элемтәләрнең активлашуын фән, мәдәният һәм мәгариф өлкәсендә дә күзәтергә мөмкин.

Татарстан һәм Кыргызстан мәдәниятара багланышлар кысаларында 2023 елның 9–10 июлендә Ч. Айтматов исемендәге Кино йортында узган Татарстан киносы көннәре әһәмиятле чарага әйләнде [Дни татарстанского кино...]. 2021 елда Татарстан Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты хезмәткәрләренең археографик экспедициясе оештырыла. Алар Кыргызстан татарлары тарихы белән турыдан-туры бәйле зур язма чыганакларны өйрәнәләр. Институтның эш нәтиҗәләре һәм шулай ук Кыргызстан галимнәре тикшеренүләре Институтта 2022 елда басылып чыккан монографияләрдә чагылыш тапкан [Прошлое татар Кыргызстана..., 2022; Татарская эпиграфика Кыргызстана..., 2022; Бикбулатова, Абдрахманов, 2022; Кубатова, 2022]. 2023 елдан М. Хәсәнов исемендәге Татар энциклопедиясе һәм төбәкне өйрәнү институтында бу ил татарларының тарихына һәм бүгенге яшәешенә багышланган «Кыргызстан татарлары» фәнни-белешмә басманы булдыру буенча эш алып барыла. Казан федераль университеты үзара килешүләр нигезендә Кыргызстанның 20 фәнни-белем бирү оешмасы

белән хезмәттәшлекнең төрле формаларын һәм юнәлешләрен гамәлгә ашыра [Ректор КФУ...].

Татарстан-Кыргызстан хезмәттәшлегенең бер нәтиҗәсе буларак, 2023 елның маенда Кыргызстан Президенты С.Н. Жапаров «Россия Федерациясенең Казан шәһәрендә Кыргызстан Республикасы Генераль консуллыгын булдыру турында»гы Указны имзалады. Документтан күренгәнчә, консуллыкның төп бурычлары – икътисади һәм мәдәни хезмәттәшлекне киңәйтү өчен уңай шартлар тудыру, шулай ук Казан шәһәрендә кыргызстанлыларга, шул исәптән, Башкортстан Республикасы, Марий Эл Республикасы, Мордовия Республикасы, Татарстан Республикасы, Удмуртия Республикасы, Чувашия Республикасы һәм Ульяновск өлкәсе территорияләрен үз эченә алган округларда консуллык хезмәте күрсәтү [В Казани и Санкт-Петербурге...].

Татарстан Президенты Р.Н. Миңнеханов Татарстан белән Кыргызстан арасындагы элемтәләрне ныгыту һәм үстерү өлкәсендә нәтиҗәле хезмәте өчен 2022 елда Кыргызстан Республикасының «Данакер» (Дуслык) ордены белән бүләкләнде. «Бөтен халыктан хөрмәт билгесе буларак иң югары бүләк» булган орденны Р.Н. Миңнехановка Кыргызстанның Россиядәге гадәттән тыш һәм тулы вәкаләтле илчесе Г.-К. Самат тапшырды [Османалиева].

Нәтиҗә ясап, түбәндәгеләрне билгеләп үтәргә мөмкин: Татарстан – Кыргызстан мөнәсәбәтләре күптәнге традицияләргә нигезләнгән. Бу традицияләр, һичшиксез, Татарстан белән Кыргызстан республикалары арасында икътисади-сәүдә һәм мәдәни элемтәләрнең ныгуына һәм хезмәттәшлекнең актив үсешенә ярдәм итә; соңгы елларда алар арасындагы элемтәләренең киңәюе һәм тирәнәюе Россия Федерациясенең Үзәк Азия төбәгендәге тышкы икътисади эшчәнлегенең активлашуы нәтиҗәсе булып тора.

**Әдәбият**

*Бартольд В.В.* История культурной жизни Туркестана. Л., 1927. 256 с.

*Мурадымов М.* Республика Киргизия // Татарская энциклопедия: в 6 т. / гл. ред. М.Х. Хасанов, отв. ред. Г.С. Сабирзянов. Казань: Институт Татарской энциклопедии АН РТ, 2010. Т.5. 736 с.

*Бикбулатова А.Р.* Татары Кыргызстана. Казань: Татар. кн. изд-во, 2020. 239 с.

*Бикбулатова А.Р., Абдрахманов Б.Дж.* Политические репрессии в Кыргызстане (1920–1953): судьбы татар / под ред. Т.К. Чоротегина. Казань: Институт языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова АН РТ, 2022. 300 с.

Киргизия // Большая российская энциклопедия [Электронный ресурс]. URL: https://old.bigenc.ru/geography/text/2065934 (мөрәҗәгать көне: 17.04.2024).

Рустам Минниханов: Надеемся, что в ходе нашего визита татарстанские и кыргызские бизнесмены откроют новые направления для взаимовыгодного сотрудничества [Электронный ресурс]. URL: https://prav.tatarstan.ru/index.htm/news/398775.htm (мөрәҗәгать көне: 2.05.2024).

Бизнесмены Татарстана приехали в Кыргызстан. Хотят работать и сотрудничать [Электронный ресурс]. URL: https://www.tatar-inform.ru/news/osobye-otnoseniya-osnovannye-na-partnyorstve-o-cem-dogovorilis-minnixanov-i-zaparov-5843797 (мөрәҗәгать көне: 25.05.2024).

Дни татарстанского кино пройдут в Бишкеке [Электронный ресурс]. URL: https://24.kg/obschestvo/269353_dni_tatarstanskogo_kino_proydut_vbishkeke/ (мөрәҗәгать көне: 7.04.2024).

В Казани и Санкт-Петербурге будут генконсульства Кыргызстана: указы президента [Электронный ресурс]. URL: https://24.kg/vlast/265034_vkazani_isankt-peterburge_budut_genkonsulstva_kyirgyizstana_ukazyi_prezidenta/ (мөрәҗәгать көне: 13.05.2024).

*Кубатова А.Э.* Татарское просветительство и реформаторское движение в Кыргызстане (конец XIX – начало XX века) / под ред. А.Р. Бикбулатовой. Казань: Институт языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова АН РТ, 2022. 256 с.

*Осмоналиева Б.* Глава Татарстана награжден орденом «Данакер». [Электронный ресурс]. URL: https://24.kg/obschestvo/234311_glava_tatarstana_nagrajden_ordenom_danaker_/

Прошлое татар Кыргызстана в архивных документах (конец XIX – начало XX в.) / сост., текст, комп. подгот.: А.Р. Бикбулатова, А.М. Ахунов, И.Г. Гумеров. Казань: ИЯЛИ, 2022. 192 с. (Серия: Культурно-историческое наследие татар зарубежья. Книга 7).

Татарская эпиграфика Кыргызстана (конец XIX – начало XX в.) / И.Г. Гумеров, А.М. Ахунов, А.Р. Бикбулатова, В.М. Усманов, Т.Т. Сырдыбаев. Казань: ИЯЛИ, 2022. 160 с. (Серия: Культурно-историческое наследие татар зарубежья. Книга 8).

***Ибраһимов Руслан Рөстәм улы,***
*тарих фәннәре кандидаты, Казан федераль университеты доценты,*
*ТР ФА М. Хәсәнов исемендәге Татар энциклопедиясе*
*һәм төбәкне өйрәнү институтының Татар диаспорасын өйрәнү үзәге*
*әйдәп баручы фәнни хезмәткәре*

***Габделхакова Гөлшат Мансур кызы,***
*ТР ФА М. Хәсәнов исемендәге Татар энциклопедиясе*
*һәм төбәкне өйрәнү институтының Татар диаспорасын өйрәнү үзәге*
*фәнни хезмәткәре*

УДК 93/94

***А.А. Исокбоев***

# МӘГЪРИФӘТЧЕ ШАКИР МОХТАРОВНЫҢ ТӨРКЕСТАНДАГЫ КҮПКЫРЛЫ ЭШЧӘНЛЕГЕ ТУРЫНДА

В статье описывается деятельность известного татарского просветителя Шакира Мухтарова по организации процесса развития новометодных школ в Туркестане, его выступления в мусульманской печати Туркестана и Центральной России, участие в деле организации национальной печати и типографии, а также раскрывается роль Ш. Мухтарова в политических процессах в Туркестанском крае в 1917–1920 гг.

**Ключевые слова:** Шакир Мухтаров, национальная печать, газета «Тараккий», «Молодая партия», новометодная школа, журнал «Шура», газета «Мехнаткашлар товуши» (газета «Голос трудящихся»), газета «Шуълаи инкилоб» (газета «Луч революции»).

The article describes the activities of the famous Tatar educator Shakir Mukhtarov in organizing the process of development of new method schools in Turkestan, his speeches in the Muslim press of Turkestan and Central Russia, participation in the organization of the national press and printing house and also reveals the role of Sh. Mukhtarov in political processes in the Turkestan region in 1917–1920.

**Keywords:** Shakir Mukhtarov, national press, newspaper «Tarakkiy», «Young Party», new method school, magazine «Shura», newspaper «Mekhnatkashlar tovushi» (newspaper «Voice of the Workers»), newspaper «Shulai inqilob» (newspaper «Ray of Revolution»).

Шакир Мохтаров (Шакир Мохтари) – XX гасыр башында Төркестанда иҗтимагый-сәяси процессларны тизләтү буенча эшчәнлек күрсәткән татар мәгърифәтчеләренең берсе. Аның яңа типтагы мәктәпләр оештыру буенча тәкъдимнәре, матбугат эшен җайга салуда турыдан-туры катнашуы, мәгърифәтчелек фикерләрен алга сөрүе тәфсилләп бәян итүгә лаек.

Архив документларыннан һәм вакытлы матбугат материалларыннан күренгәнчә, Ш. Мохтаров Сембер губернасының Буа өязендә туган, Оренбургтагы «Кәрвансарай» мәдрәсәсен тәмамлаган. Ул Коканд шәһәренә 1906 елда килгән [Хожи Муин, с. 50]. 1906 елның 20 июлендә «Тәрәккый» газетасына җибәргән мәкаләсенең ахырында Ш. Мохтаров үзе турында: «Шокир Мохторуф, Нугайкурган мөгаллиме», – дип язып куйган [Шокир Мухторуф, 1914]. Бу документтан Ш. Мохтаровның, Кокандка килеп җиткәнче, Ташкент өязе Зангиат волостеның Нугайкурган авылында укытуы ачыклана. Әмма туган елы һәм Төркестанга килү вакыты билгеле түгел.

1910 елның 7 гыйнварында Коканд өязе җитәкчесенең Фирганә өлкәсе идарәсенә юллаган хатында Коканд шәһәренең Исфара

Гузар мәхәлләсендә Ш. Мохтаровның 2 ел дәвамында 40 укучыны яңа ысул белән укытуы билгеләп үтелә [Үзбәкстан Милли архивы, ф. И. 19, тасв. 1, эш 35019, б. 7–7]. Ул вакытта Коканд шәһәрендә Ш. Мохтаровтан кала Сәләхеддин Мәҗитов, Хабулла Донской, Ариф Клевлеев, Мөхәммәтҗан Абдухаликов, Билал Байбәков, Сәед Агакши углы кебек татар мөгаллимнәре дә эшләгән.

«Тәрҗеман» газетасының 1910 елның 16 июль санында хәбәр ителгәнчә, Кокандта 15 тән артык җәдит мәктәбе исәпләнеп, шулар арасында Сәләхеддин Мәҗитов һәм Ш. Мохтаров укыткан мәктәпләрнең репутациясе югары булган [Милли хол ва...].

Ш. Мохтаров 1906 елда җәдит мәктәбендә мөгаллимлек итә, милли матбугатны барлыкка китерүдә актив катнаша, шулай ук Төркестанда үзен сәясәт өлкәсендә дә таныткан күренекле җәмәгать эшлеклесе була.

Билгеле булганча, 1906 елның 27 июнендә Ташкентта Исмаил Абиди редакциясендә танылган прогрессив «Тәрәккый» газетасы чыга башлый. Бу газетаның 20 саны гына чыгып калса да, милли матбугат барлыкка килүдә аның роле зур була. Зыя Сәед үзенең «Үзбәк вакытлы матбугаты тарихы буенча материаллар» дигән китабында Ш. Мохтаровның әлеге газетага язышкан автордашларның берсе булуын әйтә [Зиё Саид, б. 46].

Ш. Мохтаровның 1906 елның 22 маенда басылган мәкаләсендә Фәттахеддин әфәнденең ысулы кадим (иске ысуллы) мәктәбендә һәм Исмәгыйль әфәнденең ысулы җәдит (яңа ысуллы) мәктәбендә имтиханнар үткәрү тәртибе чагыштырылган. Бу имтиханнарны алуда Ш. Мохтаров үзе дә катнашкан.

Ә 1906 елның 20 июлендә «Тәрәккый» газетасының унынчы санында Ш. Мохтаровның «Бокият ал имтихон» исемле мәкаләсе басылып чыккан.

Фәттахеддин әфәнде тарафыннан иске ысул белән укытылган мәдрәсәдә үткәрелгән имтиханнар хакында Ш. Мохтаров болай ди: «Аңарда мәктәпләрне реформалауга һәм укучыларның белемен үстерүгә омтылыш юк, бу – әллә аларның Россиядә иске тәртиптә эшләгән мөселман мәдрәсәләрендә укуларыннан, әллә башка бер сәбәптән».

Исмәгыйль әфәнде турында: «Исмәгыйль әфәнде авыр, хәтта изге мәгърифәтчелек эшенә энтузиазм белән тотынды һәм, уку процессы башланып, өч-дүрт айдан соң, шәһәр халкын җыеп, укучыларыннан имтихан алды. Шул рәвешле халыкка уку һәм укытуның торышын күрсәтергә теләде. Кыска гына вакыт эчендә ул халыкка ислам дине кагыйдәләрен, уку һәм язуны менә дигән итеп укыта алуын дәлилли алды, һәм халык аңа рәхмәтен белдерде», – дип яза Ш. Мохтаров, ватандашының хезмәтен хуплап. Аның сүзләренә караганда, укучыларның ел саен халык алдында имтихан тотуы мөгаллимнең репутациясен бик нык күтәргән, уңай нәтиҗәләр биреп, белем алуга омтылыш тәрбияләгән [Шокир Мухторуф, 1906].

Исмәгыйль әфәнде мәктәбендә укучылар, барлык фәннәр буенча югары нәтиҗәләр күрсәтеп, катнашучыларның хуплавына ирешкәннәр. Ш. Мохтаров болай дип дәвам итә: «Имтиханнан соң сынауда катнашкан җирле халык, Исмәгыйль әфәнденең берничә шәкертенең Коръән аятьләрен һәм хәдисләрне яттан укуларын күреп, елап ук җибәрделәр һәм: “Афәрин, афәрин, шәп, бик шәп”», – дип кычкырдылар. Исмәгыйль әфәнденең унбер яшьлек шәкерте, урыныннан торып басты да, барысын да гаҗәпкә калдырып, нотык сөйләде. Җыелган кешеләр бу балага: «Улым, гомерең озын булсын!» – дип фатиха бирделәр». Ш. Мохтаров мөгаллимнең уңышы турында горурланып һәм сокланып яза.

Автор мәкаләсендә Фәттахетдин әфәнденең шәкертләрдән шәхсән үзенең дә имтихан алуын ассызыклый: «Мин укучылардан бик күп фәннәр буенча сорау алдым, мөгаллимнең белем бирү өлкәсендәге кимчелекләрен, җитешсезлекләрен таптым һәм, беркемнән дә курыкмыйча, үз фикеремне әйтеп бирдем».

Ш. Мохтаров фикеренчә, имтиханнарның нәтиҗәләре бер генә төрле булмаса да, ике мөгаллим дә хөрмәткә лаек. Ул укытучылар эшен яңача оештыруның өстенлеген ассызыклый, һәм әлеге имтиханның ысулы җәдит мәктәбенең өстенлекләрен ачык күрсәтүен билгеләп үтә [Шокир Мухторуф, 1906].

Шунысын да әйтергә кирәк: Ш. Мохтаров Коканд шәһәренең иҗтимагый-сәяси тормышында да актив катнашкан. Төркестан генерал-губернаторы каршындагы Төркестан районы жандарм бүлегенең 1906 елгы яшерен мәгълүматында әйтелгәнчә, Кокандта Шакир Мохтаров, Закир Абиханов һәм Мөхәммәдзариф Мөхәммәдьяров тарафыннан «Яшь партия» дип аталган «татар фракциясе» оештырылган. Төркестан районы жандарм бүлеге мәгълүматлары буенча, фирка әгъзалары баштан ук Төркестанда да, Россиядә дә татар яшьләре арасында капиталистик мөнәсәбәтләр урнаштыруны, шулай ук җәдитчелек хәрәкәте идеясен яклап чыкканнар.

Баштарак фирка әгъзаларының саны җирле татарлар исәбенә генә арткан. Бу фирка әгъзалары җәдитчелек хәрәкәтендә катнашмаган татарларга дошман итеп караган. Исмәгыйль Сөләйман улы Аитов (Казаннан. – *И.А.*) партияне оештыручы татарлар арасында иң белемлесе булган. Аны «Яшь партия»нең башлыгы итеп сайлаганнар. И. Аитов инициативасы белән фиркага татарлар белән беррәттән яшь үзбәкләр дә кабул ителгән [Үзбәкстан Милли архивы, ф. И. 461, тасв. 1, эш 1168, л. 113].

Партия эшчәнлегендәге бурычларның берсе – акча җыю, шул исәптән кирәкле әдәбиятны сатып алу өчен дә, чөнки мәгариф идеяләрен таратуда китап сүзенең булышлыгы зур булган. «Яшь партия» акчалары исәбенә Ташкентта үзбәк телендә чыккан «Шухрат» газетасы да финансланган. «Шухрат» газетасы ябылганнан соң, «Осиё» газетасына акчалата ярдәм күрсәтелгән. «Яшь партия» Төркестан җәдитләре лидеры Мәхмүдхуҗа Биһбуди һәм «Шухрат» газетасы

мөхәррире Мөнәввәр Кари Абдурашидханов белән тыгыз элемтәдә булган, ул Ташкент җәдитчеләренең «фикри атасы» саналган [Үзбәкстан Милли архивы, ф. И. 461, тасв. 1, эш 1168, л. 113].

Генерал-губернатор канцеляриясе 1911 елның 22 маенда Төркестан һәм Төркестан районы жандарм бүлеге хәбәрендә телгә алынган затлар белән кызыксына башлаган. Коканд өязе башлыгына аларның эшчәнлекләрен җитди күзәтү астына алу турында күрсәтмә бирелгән [Үзбәкстан Милли архивы, ф. И. 461, тасв. 1, эш 1168, л. 111–112].

1912 елның 27 февралендә Төркестан районы жандарм бүлеге начальнигы Сизых Кокандтан «Яшь партия» турында, ике фотосурәт тә теркәп, Төркестан полиция департаментының махсус бүлегенә яшерен хат юллаган. Фотосурәтләр 1908 елның маенда Сәетбәк Рөстәмбаев бакчасында һәвәскәр фотограф Рәхмәтулла Мифтахетдинов тарафыннан Кокандтан ике чакрым ераклыкта Лотфулла Касыймов (күмер сату белән шөгыльләнгән) оештырган кичәдә төшерелгән булган. Фотосурәтләрдәге илле кеше җирле татар бергәлеге әгъзалары булып торган.

Алар барысы да революция тарафдарлары булып, яңа ысулы җәдит мәктәпләр ачу, мөселман хатын-кызларын укыту кебек идеяләрне яклаганнар. Гәрчә алар барысы бер партиягә берләшмәсәләр дә, өлкән буын аларга «Яшь партия» дип исем биргән [Үзбәкстан Милли архивы, ф. И. 461, тасв. 1, эш 1168, л. 115].

Ш. Мохтаров шулай ук 1914 елның 3 апрелендә Кокандта Абиджан Мәхмүтов нәшриятында чыга башлаган «Садаи Фирганә» газетасының иң актив оештыручылары һәм публицистларының берсе була.

Ш. Мохтаров «Садаи Фирганә» газетасының беренче санында «Ислохни нимадан бошларга?» дигән баш астында мәкалә бастыра. Анда автор мәгариф системасы реформасының зарурлыгы турындагы фикерен дәлилли. Аның алгарышның (аерым алганда, Европа прогрессының) төп факторы булып торуын билгеләп, болай ди: «Мин Европа халыклары прогрессының сәбәпләрен озак эзләдем һәм аңа мәктәпләр һәм башлангыч белем бирү реформасыннан кала бернинди нигез дә таба алмадым».

Ш. Мохтаров үзенең күпьеллык мөгаллимлек итү тәҗрибәсенә таянып, илнең алгарышына илтүче ышанычлы юлның бөтен мәктәп системасы реформасы аша гына булуын ассызыклый. «Минем анализларыма караганда, Европа һәм башка мөселман булмаган илләр халыкларының шундый көчле эволюция кичерүенең сәбәбе – мәктәптә белем бирүнең иң камил дәрәҗәдә җайга салынганлыгында. Шуңа күрә мин дә җәмгыять реформасын мәктәпләрдән башларга кирәк, дигән фикергә килдем», – дип нәтиҗә ясый ул. Мәкаләнең мөһимлеге шунда ки, Ш. Мохтаров мәктәп, мәдрәсә, уку йортлары белән җитәкчелек итү формалары һәм укучылар турында фикер алышуга чакыра.

Үзен «А.А.» дип билгеләгән аноним автор «Садаи Фирганә» газетасында бастырган материалында Ш. Мохтаровның югарыда телгә

алынган мәкаләсе белән килешми, һәм Төркестанда күп кенә ысулы җәдит мәктәпләр төзелүне, мәктәп белеменең хәле яхшы булуны раслый (аңа матди ярдәм күрсәтүне исәпкә алмаганда). «Әлхәмдүлилләә... милләтебезнең перспективалары турында уйлаган берничә интеллектуалның тырышлыгы белән һәр районда яңа ысуллы мәктәпләр ачылды. Моңа сөенергә кирәк. Матди ярдәм һәм акча җитәрлек булганда мәктәпләрне тиз арада реформалау мөмкин түгел» [А.А., 1914], ди «А.А.». Шул ук вакытта үзгәртеп коруларга тотынырга иртәрәк булуын ассызыклый.

Ш. Мохтаров Төркестанда күренекле җәдитче мөгаллим, публицист кына түгел, үз заманы проблемаларын үзәккә куйган шагыйрь буларак та танылган. Оренбургта чыккан «Шура» журналында Ш. Мохтаровның Россия мөселманнарының проблемаларын чагылдырган күпсанлы шигырьләре басылган. Аның «Тәгълим» [Шура, 1909, № 3, б. 87], Кайдан килгән» [Шура, 1910, № 6, б. 189–190], «Сабырлык һәм әхлак» [Шура, 1917, № 12, б. 272], «Әхлак» [Шура, 1917, № 14, б. 331–332], «Үпкәләгәндә» [Шура, 1917, № 19, б. 446], «Тәэсир» [Шура, 1917, № 20, б. 476], «Татар кызының елавы» [Шура, 1917, № 21, б. 494–495] һәм «Безнең хатын-кызлар турында» [шунда ук, б. 495] кебек шигырьләре Төркестанның төрле шәһәрләрендә иҗат ителгән.

Ш. Мохтаров Коканд шәһәрендә 1917 елга кадәр яшәгән. 1917 елгы Октябрь инкыйлабыннан соң, ул гаиләсе белән Сәмәркандка күченеп киткән. Аның шуннан соңгы эшчәнлеге турыдан-туры совет хакимияте белән бәйле. 1917–1918 елларда ул Сәмәркандта урнашкан 7 нче укчылар полкында хезмәт иткән. Ш. Мохтаров 1918 елның октябреннән «Эшче» тәхәллүсе астында «Социализм нима?», «Ер тугрисида икки хил фикр», «Судья ким булиши керак» «Бохара инкыйлабы», «Турк тилидан бүләк бериш методикаси» брошюраларын бастырып чыгарган [Самарканд тарихи, б. 87].

Сәмәркандта Ш. Мохтаров китаплар нәшер итү белән дә шөгыльләнгән. 1918 елның июнь башыннан ул (ун ай дәвамында) Сәмәркандта чыга башлаган «Мехнаткашлар товуши» газетасының мөхәррире вазифаларын башкарган. 1919 елның 10 апреленнән ул Сәмәркандта Сәид Реза Ализода редакциясендә таҗик телендә басылган «Шөгъләи инкыйлаб» журналының эшен җайга салу өчен бөтен көчен куйган [Самарканд тарихи, б. 95].

Сәмәркандта 7 нче укчылар полкында хезмәт иткәндә Ш. Мохтаров туберкулёз йоктырган [Вадуд Махмуд, 1970]. Моны танылган тәнкыйтьче һәм публицист Вәдүд Мәхмүд тә (1898–1976) раслый. Авыруына карамастан, Ш. Мохтаров әле күпмедер вакыт студентлар укыткан. Әмма чире көчәя барып, ул Сәмәрканд хастаханәсенә яткан. 1920 елның җәендә, дусларының киңәше һәм ярдәме белән, кымыз эчеп дәвалану өчен, Җизакка күчеп киткән. 1920 елның 26 декабрендә шунда вафат булган [Хожи Муин, б. 51]. Аның ике улы һәм ике кызы булып, алар Сәмәркандта яшәделәр.

Төркестанның прогрессив карашлы зыялыларын Ш. Мохтаровның вафаты тирән кайгыга салган. Атаклы мәгърифәтченең үлеме турында Хаҗи Муин болай ди: «Ул талантлы мөгаллим, үткен каләмле мөхәррир иде. Төркестанда без бик нык көткән вакыт килгәч кенә, шундый кирәкле кешене югалту безнең өчен зур фаҗига булды» [Хожи Муин, 2005]. Ш. Мохтаровны сагынып, Вәдүд Мәхмүд: «Синең эшләрең һәм нәтиҗәле хезмәтең беркайчан онытылмас. Мин синең кебек кешеләрнең күбрәк булуын теләр идем. Хәзер әгәр синең кебек үз халкы өчен яши торган кешеләр күбрәк булса, без максатыбызга тизрәк ирешер идек. Һәрхәлдә, син буыннар хәтерендә калачаксың», – дип язган [Вадуд Махмуд, 1921].

Ш. Мохтаров Төркестан халыклары тарихында Кокандтагы җәдит мәктәбен оештыручы, илдәге беренче җәдит басманы («Тәрәккый») һәм Фирганә өлкәсендәге беренче җәдит газетаны («Садаи Фирганә») оештыручы, мәгариф системасы реформаторы, танылган публицист, мөхәррир һәм шагыйрь буларак тирән эз калдырган.

**Әдәбият**

*Зиё Саид.* Узбек вактли матбуоти тарихига материаллар (1870–1927). Тошкент; Самарканд: Узбекистан давлат нашриёти, 1927. 180 б.

Самарканд тарихи. Иккинчи том / масъул мухаррир И. Муминов. Тошкент: Фан, 1970. 496 б.

*Хожи Муин.* Мархум Шокир Мухторий / Танланган асарлар. Тошкент: Маънавият, 2005. 176 б.

*А.А.* Идорага мактуб // «Садойи Фаргона». 1914. 10 апрель.

*Вадуд Махмуд.* Мархум Шокир Мухторий // «Мехнаткашлар товуши». 1921. 12 февраль.

Миллий хол ва маишат // «Таржимон». 1910. 16 июль.

*Шакир Мохтари.* Әхлак // «Шура». 1917. № 14.

*Шакир Мохтари.* Кайдан килде? // «Шура». 1910. № 6.

*Шакир Мохтари.* Безнең хатын-кызлар турында // «Шура». 1917. № 21.

*Шакир Мохтари.* Сабырлык вә әхлак // «Шура». 1917. № 12.

*Шакир Мохтари.* Тәгълим // «Шура». 1909. № 3.

*Шакир Мохтари.* Тәэсир // «Шура», 1917. № 20.

*Шакир Мохтари.* Татар кызының елавы // «Шура». 1917. № 21.

*Шакир Мохтари.* Үпкәләгәндә //«Шура». 1917. № 19.

*Шокир Мухторуф.* «Бокия гал имтихон» // «Тараккий». 1906. 20 июль.

*Шокир Мухторуф.* Ислохни нимадан бошларга // «Садойи Фаргона». 1914. 3 апрель.

Үзбәкстан Милли архивы, фонд И. 19, тасв. 1, эш 35019.

Үзбәкстан Милли архивы, фонд И. 461, тасв. 1, эш 1168.

***Исокбоев Алишер Ахмаджонович***,
*тарих фәннәре кандидаты, Наманган дәүләт университетының (Үзбәкстан Республикасы) тарих кафедрасы доценты*

УДК 687.1

*С.С. Федорова*

# ПОЛЬ ПУАРЕ.
# «КАЗАН» КОЛЛЕКЦИЯСЕ

В статье на основе биографических данных Н.П. Ламановой, а также сохранившихся редких образцов гардероба Денизы Пуаре исследуется семантическое происхождение названия коллекции «Казань» 1911 года французского модельера Поля Пуаре. Рассматривается общее увлечение модельера русской историей и культурой, в том числе «Русскими балетами» С.П. Дягилева, образцами традиционного русского костюма.

**Ключевые слова:** Поль Пуаре, Н.П. Ламанова, мода, «Русские сезоны», русский костюм, татарский костюм.

In the article, based on the biographical data of N.P. Lamanova, as well as surviving rare samples of Denise Poiret's wardrobe, the semantic origin of the name of the 1911 collection "Kazan" by French fashion designer Paul Poiret is explored. The fashion designer's general passion for Russian history and culture, including S.P. Diaghilev's "Russian Ballets" and examples of traditional Russian costume, is examined.

**Keywords:** Paul Poiret, N.P. Lamanova, fashion, "Russian Seasons", Russian costume, Tatar costume.

Парижда яшәгән Поль Пуаре (1879–1944) моданың Шәрыкка йөз белән борылырга теләвен тойган беренче модельер була. Грек хитоны, һинд сарие, япон кимоносы һәм рус сарафаны… – кутюрье боларның барысы белән дә кызыксынган, һәм алар XX гасырның беренче чирегендә Европа модасында төп темага әверелгән. Модельер рус костюмына 1910 елларда – һөнәри үсеш юлында иң югары биеклеккә ирешкән вакытта – аеруча зур игътибар бирә. Бу очраклы хәл түгел: чөнки ул вакытта бөтен Европа, бер яктан, С.П. Дягилевның «Рус балетлары»на әзерләнгән сәхнә костюмнарын, ә икенче яктан, Н.Л. Шабельская, М.К. Тенишева һәм башка коллекционерлар алып кайткан борынгы костюмнарны күреп таң кала. Бу гына да түгел, XIX–XX гасырлар чигендә Франция һәм Россия арасында үзара тыгыз мәдәни диалог урнаша.

1911 елда «Рус балетлары» фантасмагориясе белән мавыккан Пуаре Россия буйлап гастрольгә китә. Әлеге сәфәр, беренче чиратта, масштаблы реклама акциясе була һәм рус аристократиясенең күренекле вәкилләре арасында яңа клиентлар эзләүне максат итә, шул ук вакытта ул «экспедиция» характерын алып, аның ярдәмендә модельер ерак илдә яшеренгән яңалыкларны таба, күрә һәм ишетә ала.

Пуаре рус мәдәнияте, сәнгате дөньясы белән хезмәттәше һәм дусты Надежда Петровна Ламанова арадашчылыгында таныша[1]. Россиядә вакытта француз ике башкалада – Мәскәүдә һәм Санкт-Петербургта була, ул Парижга үзе белән рус чигү үрнәкләрен, төрле сөлгеләр, ашъяулыклар һәм яулыклар, шулай ук башкала музей һәм ярминкәләрендә күргәннәреннән якты хатирәләр алып кайта. Әмма соңрак Парижда әлеге сәяхәттән илһамланып әзерләнгән коллекция, көтмәгәндә, Казан каласы хөрмәтенә исемләнә. Коллекциядәге бүгенге көндә дә билгеле көндез киелә торган күлмәкләр Казанны әллә ни хәтерләтми, аларда күбрәк ирләр күлмәге тибындагы традицион рус хатын-кызлар күлмәге үзенчәлекләре чагылыш таба. Әмма коллекция ничек һәм ни өчен шулай аталган соң?[2] Юкса Пуаре беркайчан да Казанда булмаган. Кызганычка каршы, рәссамның уй-ниятләрен ачардай төгәл мәгълүматлар сакланмаган.

Мондый исемгә тукталуның сәбәпләрен билгеләргә мөмкинлек бирүче төп фаразларның берсе түбәндәгедән гыйбарәт: Пуаре традицион рус костюмы үрнәкләре белән генә түгел, ә Россиядә яшәгән кече халыклар, аерым алганда татар милли костюмы үрнәкләре белән дә яхшы таныш булган. Моннан тыш, рус костюмы, даими рәвештә модификацияләнә барып, Шәрык халыклары костюмнары элементларын да үзләштергән. Әйтик, XVI гасыр уртасында рус халык костюмы ансамбле составына атаклы татар читекләре – җиңел күннән эшләнгән биек кунычлы аяк киемнәре килеп кергән. Читекләрнең уникальлеге күн мозаикасы техникасын куллануда: вак күн кисәкләре бер-берсенә ефәк, алтын яки көмеш җепләр белән тегеп беркетелгән. Читек – җиңел һәм уңайлы гына түгел, ә тышкы күренеше белән дә бик эффектлы аяк киеме. Ул башта рус аристократлары арасында, ә аннары (XX гасыр башында) бөтен Европада һәм Америкада да популяр булып китә.

Поль Пуаренең хатыны Дениза гардеробының шактый өлеше сатуга куелгач, 2005 елда Друо аукционы өчен эшләнгән сатулар каталогында да шундый бер пар читек була. Аларны, мөгаен, Пуаре үзенең Шәрык кыйммәтләре тупланмасына тагын бер хәзинә булыр дип сатып алгандыр. Көнбатышта Көнчыгыш аяк киеме массачыл популярлык казана, шул исәптән аңа трендны «Рус сезоннары»да бирә. Бу исә үзе үк, рус коллекциясенә исем сайлаганда, татар читекләре үрнәкләре модельерга турыдан-туры йогынты ясый алган, дип фаразларга мөмкинлек бирә. А. Бенуа истәлекләре буенча, 1909 елда «Кыпчак биюләре» балеты сәхнәгә чыккач, Париж модницалары кыпчак читекләрен эзли һәм бик теләп кия башлыйлар.

---

[1] Н.П. Ламанова (1861–1941) – Россия һәм совет модельеры, театр костюмы рәссамы. XX гасыр башында Россия һәм совет модасына нигез салучыларның берсе.

[2] Әдәбиятта коллекциянең тагын бер исемен очратырга мөмкин – «җитен колллекциясе».

Модельерның уй-ниятләрен аның ике башкалага барудан алган тәэсирләреннән дә эзләргә мөмкин. Әгәр ул Мәскәүне колоритлы, бәйрәмчә, төрле типажлар яшәгән, төрле чәчәкләр үскән һәм төрле зәвыклар белән тулы кала буларак кабул итсә, Санкт-Петербург аны битараф калдыра, шәһәр һәм аның халкы Император сарае һәм административ аппаратның катгый һәм формаль кагыйдәләренә артык бәйле кебек тоела аңа. Төньяк башкалада Пуаре коллекциясе һәм аның мәгърифәтчелек эшчәнлеге каты тәнкыйтькә дучар була. Көнчыгышның бөтен нәрсәсенә җаны-тәне белән тартылган француз һәм тыйнак, салкын Петербург арасында үзара симпатия тумый.

Ә менә Пуаренең Мәскәүдә булган көннәре музейларда, милли ресторуаннарда, бирeдәге базарларда йөреп, урамнардагы кешеләрне күзәтеп, башкала архитектурасы белән танышып уза. Борынгы рус архитектурасының иң әһәмиятле һәйкәлләренең берсе – Изге Алла Анасының Ровтагы Покрау соборы тарихы да модельерга әлеге мәсьәләдә билгеле бер карарга килергә ярдәм иткән булырга мөмкин. Мәскәүнең нәкъ үзәгендә урнашкан бу собор, патша Иван Грозный боерыгы буенча, 1555–1561 елларда Казан ханлыгын буйсындыру хөрмәтенә төзелгән. Чит ил кунаклары аның архитектур чишелешен еш кына төрле тосләргә төренгән һәм хикмәтле Шәрык архитектурасы белән чагыштыралар. Н. Ламанова биографиясеннән сакланып калган язмаларга караганда, француз кутюрьесы Мәскәүдә булуы турында болай дигән: «Она [Ламанова] открыла мне всю фантасмагорию того пред-Востока, которым является Москва…» [Виртуальный музей…].

Модельер, бик тырышып, Россиядә «Шәрык эзләрен» эзли, һәм аларны башкалада таба да дия алабыз. Күрәсең, ул Казан каласы турында да күп ишеткәндер, чөнки ул вакытта Казан осталарының даны чит илләргә дә барып ирешкән, ул гына да түгел, аларның эшләнмәләре дөньякүләм күргәзмәләрдә бүләкләр белән билгеләнгән. 1893 елда Чикагода уздырылган Колумб күргәзмәсенә Казан һөнәрче хатын-кызлары тарафыннан әзерләнгән коллекция җибәрелә[1]. «Казан шәһәре. 1893 ел» очеркында бу коллекциядә хатын-кызларның борынгы һәм хәзерге милли костюмнары, шул исәптән бай татар костюмының да булуы ассызыклана, аларның этнографик әһәмияте билгеләнә [Музей Е.А. Боратынского...]. Халыкара күргәзмәләрдә татар осталарының зур уңышлар яулавы нәтиҗәсендә, аларга Мәскәү һәм Санкт-Петербургтан гына түгел, ә Париждан да заказлар килә.

Чит ил модельерлары еш кына бер илгә хас социаль-мәдәни күренешләрне һәм тарихи чорларны катнаштыралар, бу – катлаулы, бай һәм матур тарихка ия Россияне дә читләтеп үтми. 1976 елда модельер Ив Сен-Лоран, элеккеге «югары мода шәркыятьчесе» Пуаре кебек үк, «Рус опералары һәм балетлары» коллекциясендә Л. Бакст эскиз-

[1] Боратынскийларның Казан өязе Шушар утарындагы һәм башка күрше авыллардагы артель турында сүз бара.

ларындагы Көнчыгыш нәзакәтлелеген һәм Пётр I гә кадәрге костюм турындагы күзаллаулар белән берләштерә. 2009 елда рус халык костюмы, совет хәрби униформасы, боярлар стиле, С. Дягилев балетлары, конструктивизм элементларын фантастик рәвештә берләштергән «Париж-Мәскәү» коллекциясен чыгарган «Chanel» мода йорты бу тенденцияне тагын да ачыграк характерлап бирә. Поль Пуаре да үз коллекциясендә Мәскәү кебек төрле һәм Санкт-Петербург кебек кырыс шәһәрләрнең түгел, ә аутентик Казан каласы атамасын куллануны өстен күргәндер, чөнки нәкъ менә Мәскәүдән дә ераграк урнашкан бу шәһәр рус Көнчыгышы әхрамы булып тора, дип уйлагандыр.

Бүгенге көндә «Казан» коллекциясе гардеробтагы төрле әйберләрдән тора, шуңа күрә аны бербөтен итеп реконструкцияләү шактый кыен. Коллекциядәге иң билгеле кием – Пуаре тарафыннан хатыны Дениза өчен тектерелгән җитен күлмәк – Киото костюм институтына карый. Тагын бер күлмәк Париж шәһәренең мода музеенда – Гальер сараенда саклана. Институцияләр урнаштырган мәгълүматта, кызганычка каршы, коллекция исеменең серле этимологиясе әлегә ачылмаган.

### Әдәбият

Казанские ведомости. Особый шов и узорные ичиги: почему татарская кожаная мозаика уже более 300 лет остается актуальной. URL: https://kazved.ru/news/ichigi-kartiny-i-sumki-gochemu-tatarskaya-kozhanaya-mozaika-uzhe-bolee-300-let-ostaetsya-aktualnoy-58307 (мөрәҗәгать көне: 18.02.2024).

Paris musees. Les musees de la ville de Paris. «Kazan». URL: https://www.parismuseescollections.paris.fr/fr/palais-galliera/oeuvres/kazan#infos-principales (мөрәҗәгать көне: 18.02.2024).

KCI. Digital archive. URL: https://www.kci.or.jp/en/archives/digital_archives/1910s/KCI_162 (мөрәҗәгать көне: 18.02.2024).

Музей Е.А. Боратынского. Шушарские девушки-вышивальщицы («Шитушки»). URL: https://boratynskiy.tatmuseum.ru/my-product/shusharskie-devushki-vyshivalshhicy-shitushki-fotografiya-a-p-vyatkinojj-kazan-1893-fotobumaga-karton/ (мөрәҗәгать көне: 18.02.2024).

Виртуальный музей Надежды Петровны Ламановой. Поль Пуаре. URL: https://lamanova.com/16_poiret.html (мөрәҗәгать көне: 18.02.2024).

***Федорова София Сергеевна,***
*Бөтенроссия декоратив сәнгать музее (Мәскәү)*
*фәнни хезмәткәре*

УДК 778.534.66

***М.Н. Самсонов***

# «ГӨЛНӘЗЕК» АНИМАЦИОН ФИЛЬМЫ МИСАЛЫНДА ЯШЬЛӘР АРАСЫНДА МӘДӘНИ ҮЗТӘҢГӘЛЛЕК ФОРМАЛАШТЫРУ

В статье рассматриваются проблемы о культурной самоидентификации в среде молодёжи и способах пробудить интерес данной социальной группы к наследию своего государства. В качестве инструмента для решения проблемы о культурной самоидентификации предлагается к анализу анимационное искусство. На примере мультфильма «Гульназек» Елены Ермолиной и Евгения Тишкина рассмотрено, как художественное произведение может стать наглядной репрезентацией национальной культуры с оглядкой на интересы социальной группы молодёжи. Сочетание формы и содержания мультфильма способно сформировать в подрастающей личности культурную самоидентификацию.

**Ключевые слова:** самоидентификация, культурный код, анимация, татарская культура, орнамент.

The article discusses problems of cultural self-identification among young people and ways to awaken the interest of this social group in the heritage of their state. Animation art is proposed for consideration as a tool for solving the problem of cultural self-identification. Using the example of the cartoon “Gulnazek” by Elena Ermolina and Evgeny Tishkin, it is examined how a work of art can become a visual representation of national culture with the attention to the interests of the youth. The combination of the form and content of a cartoon can form cultural self-identification in a growing individual.

**Keywords:** self-identification, cultural code, animation, Tatar culture, ornament.

Цифрлы технологияләр үскән һәм мәгълүмат ташкыны көчәйгән чорда үсеп килүче Z буыны яки «зумерлар» үсеше мәсьәләсе көн тәртибендә тора. Моннан тыш, глобальләшү һәм интеграция процесслары милли бердәйлек проблемасын, субъектның шәхси бердәйлеген билгеләргә мөмкинлек бирә [Kuznetsova, Goryacheva, Patenko, p. 907]. Үз-үзен, үз мәнфәгатьләрен һәм җәмгыятьтә үз урынын белгән уртача статистик бала да шундый субъект була. Хәзерге массакүләм мәгълүмат чараларыннан килгән хәбәрләр ташкыны кешегә бөтен дөньяны өйрәнү һәм аңсыз рәвештә хәтта үз иле белән бәйле булмаган мәдәният тарафдары буларак формалашу мөмкинлеге бирә. Димәк, Z буынында туган ил мәдәнияте белән үзтәңгәллекне үстерү өчен медиа каналларын куллану мәсьәләсе калка.

Традицион мәдәниятләрдә бөтен дөнья җанлы. А.В. Головнев болай дип яза: «Все видимые, мыслимые, воспринимаемые, осязаемые, создаваемые предметы и образы «живые» уже потому, что способны воздействовать на человека или запечатлевать на себе его воздействие. Понятно, что человек толкует окружающий мир как свое

подобие и прежде всего подобие в том, что этот мир живой. В диалоге со всем этим живым и складывается самоопределение человека, его место под солнцем» [Головнёв, с. 197]. Шулай итеп, мәдәниятне ачык итеп репрезентацияләү өчен милли мәдәниятнең җанлылыгын ассызыклый торган һәм шуның белән яшьләрдә үз республикасы казанышларына кызыксыну уятырдай инструментлар кирәк булачак, дип әйтә алабыз.

Анимация яки мультипликация формалашып килүче шәхестә үзен мәдәниятенең вәкиле буларак тою хисләрен тудырырга сәләтле. Анимациянең төп өстенлеге – «хәрәкәт» үзлегенә ия булуында. Башкача әйткәндә, теләсә кайсы милләтнең мәдәнияте белән бәйле статик символлар җанлана. Аерым алганда, В. Прохоров үзенең «К философии анимации» мәкаләсендә җанлануны мәдәниятнең «башланып китү» принцибы итеп карый. Ул аны мәдәниятне һәм аның барлык компонентларын кабул итүнең ниндидер уңай матрицасы сыйфатында күрә, һәм соңгысы «һәр мәдәни материалны яңа үлчәмнәр һәм сыйфатлар белән баетуга, тулыландыруга, материалны элеккегедән югарырак күтәрүгә» нигезләнгән [Прохоров].

Без анимацион әсәр үрнәген шартлы «триггер» буларак карый алабыз, ул яшьләрдә үз мәдәниятенә катнашы булу хисе формалаштыра ала. Бу исәптән, Татарстан Республикасы мәдәниятенә һәм шушы мәдәниятнең репрезентациясе булган «Гөлнәзек» анимацион фильмына мөрәҗәгать итәргә мөмкин. Әлеге әсәрнең авторлары – Елена Ермолина һәм Евгений Тишкин тарафыннан 2018 елда куелган.

Бу мультфильмның, беренче чиратта, эчтәлеге игътибарга лаек. Татар халык әкияте заманча экранлаштырылган бу проект сюжеты ягыннан хәзерге заман тамашачысының үз иле мәдәни мирасы белән диалогына корылган. Мультфильм авторлары, архетипик тарихка мөрәҗәгать итеп, аны хәзерге заман призмасы аша күрәләр, шәхси кичереш һәм кызыксынуларын да өстиләр. Мәсәлән, әкиятнең оригиналында Гөлнәзек – дошман алыпны күп тапкырлар алдаган хәйләкәр һәм тапкыр крестьян. Әкият төзелеше белән күпләргә таныш «Батыр тегүче турында әкият»не искә төшерә, анда да бит гади кеше антагонист-алыпның «күзенә төтен җибәрә». Әмма анимация интерпретациясендә, гомуми сюжет кысасы сакланган хәлдә, авторлар өстәмә мәгънәви детальләр кертәләр.

Режиссёр Е. Ермолина карашынча, Гөлнәзек һәм Дию – алар, асылда, тормыш хәлләре охшаш булган ике рәссам – «аларны өйдә аңламыйлар» [Романова]. Шул рәвешле, без әлеге фильмда сюжет үстерелеше Гөлнәзек белән Дию арасындагы мөнәсәбәтләрне яктыртуга корылган, дип әйтә алабыз. Әкиятнең оригиналыннан аермалы буларак, Дию, хатыны кушуы буенча, Гөлнәзек белән дуслашырга тырыша. Моннан тыш, төп герой белән антагонистның охшашлыгы түбәндәгечә күрсәтелгән: фильмның башында Гөлнәзек агачка ничек сокланып карап басып торса, соңгы күренештә Дию Гөлнәзекнең ишегалдында агачны нәкъ шундый позада күзәтә.

Эчтәлек ягыннан «аңланмаган даһи» темасы универсаль һәм Россиянең теләсә кайсы мәдәни юнәлешләренә – романтизмнан реализмга кадәр хас. Z буыны өчен (аның вәкилләре – нигездә, формалашып килүче шәхесләр) мондый тема якын һәм аңлаешлы. Һәм татар баласы, хәзерге заман интерпретациясендә бирелгән фольклор образларын кызганып, әлеге персонажлар язмышы белән кызыксыну хисе кичерә. Шулай итеп, без «Гөлнәзек» анимацион фильмы мәдәни мирасның репрезентациясе генә түгел, хәзерге заман тенденцияләрен күздә тотып, ул аны яңадан карап чыга, дия алабыз.

Әмма мәдәни үзтәңгәллек формалаштыру өчен сюжет компоненты яки тиешле милләт фольклоры белән турыдан-туры бәйле эчтәлекле материал белән генә танышу җитми. Эчтәлекне бирүче форма да мөһим. Тамашачыларга үз идеяләрен җиткерү өчен, авторлар мультфильмны кулдан күчерү техникасында эшләгәннәр. Анимацияләү принцибы түбәндәгедән гыйбарәт: башта персонажларны бер халәттә, аннары икенче халәттә төшерәләр, соңыннан, монтаж вакытында, әлеге хәрәкәтләр бер-берсенә ялгана. Бу техника режиссёрның персонажларның «кара-ак» дихотомиясе белән генә чикләнмәгән эчке дөньясын ассызыклауны максат итүе белән бәйле, – ә моның өчен күчерү персонажларда алмаш детальләрнең күп булуын, шулай ук йөзләрнең дә даими алмашынып торуын таләп итә. Мультфильмда артикуляция юк, әмма эмоцияләр еш алышына. Мондый персонажлар Ю. Норнштейнның «Сказка сказок» һәм «Ежик в тумане» кебек эшләренә хас.

Персонажлар анимациясеннән тыш, антуражга да игътибар бирү сорала. Режиссёр Ермолина сәнгать киңлеген ике – көнкүреш һәм фантастик өлешләргә бүлү турында болай ди: «...в начале фильма это откровенно акцентировано: сцена, персонажи. В противовес этой есть другая, сказочная, среда, не очерченная линиями горизонта, – это лес, дом дива. И у каждой локации свое художественное решение» [Романова].

Мультфильмның, аерым алганда, урманны чагылдырган фоны татар сынлы сәнгате өчен хас чәчәк орнаменты стиленә салынган. Әсәрнең башында сәнгати киңлек ниндидер яссы, төсле-төсле Шәрык келәмен хәтерләтеп ачыла, аның чуар бизәкләре эчендә [Хорихина, с. 47] Гөлнәзекнең йорты үсеп чыга, ә аннары тамашачы протагонист белән бергә искиткеч урманга эләгә. Мондый стильләштерү дөньяның бербөтенлеген, булган барлык элементларның аерылгысызлыгын ассызыклый. Һәм әлеге бизәлеш ярдәмендә авторлар Гөлнәзек һәм Дию дөньясы тышкы яктан контрастка корылуга карамастан, аларның бер-берсеннән аерылгысыз булуын күрсәтә.

Төсләргә килгәндә, без Гөлнәзек белән бәйле киңлектә өстенлек иткән сары төс һәм аның вариацияләре уңай эмоцияләр тудыруын билгели алабыз. Шул ук вакытта шартлы дошман Диюнең йорты караңгы төсләргә чорналган. Әмма, хәзерге интерпретация буенча, Дию тискәре персонаж түгел. Шуңа күрә аның дизайнында зәңгәр

төс өстенлек итә, ул, кагыйдә буларак, күңелне тынычландыра һәм шомлылыкны киметә. Моннан тыш, зәңгәр – күк, тәңре төсе, татар шигъриятендә ул еш кына матурлык, бәхет, хыял, бай эчке дөнья образларын гәүдәләндерә [Усманова]. Шуңа күрә тамашачы Гөлнәзеккә генә түгел, ә аның дошманы Диюгә дә симпатия күрсәтә, аның югары максатларын, өметләрен бүлешә.

Шулай итеп, аерым фильмнарны анализлау күрсәткәнчә, фольклор әсәрләрен хәзерге заман тенденцияләрен исәпкә алып анимацион эшкәртү яшь кешедә мәдәни үзтәңгәллек, тарихи үткәненә хөрмәт, киләчәккә өметле караш формалаштыра.

**Әдәбият**

*Головнёв А.В.* Говорящие культуры: традиции самодийцев и угров. Екатеринбург: УрО РАН, 1995. 606 с.

*Прохоров А.В.* К философии // Киноведческие записки. 1991. № 10. [Электронный ресурс]. URL: http://animalife.ru (мөрәҗәгать көне: 23.03.2024).

*Романова А.* Есть татарская псевдокультура – вся помпезная, золото, матур, и есть настоящая // [Электронный ресурс]. URL: https://m.realnoevremya.ru/articles/119453-est-tatarskaya-psevdokultura-vsya-pompeznaya-zoloto-matur-i-est-nastoyaschaya?_url=%2Farticles%2F119453-est-tatarskaya-psevdokultura-vsya-pompeznaya-zoloto-matur-i-est-nastoyaschaya&ysclid=lsjb659lwx232911274#from_desktop (мөрәҗәгать көне: 23.03.2024).

*Усманова Л.А.* Фукциональные особенности цветообозначений в русском и татарском языках (на материале языка художественных произведений) // Научный Татарстан. 2009. № 1. С. 182–186.

*Хорихина П.* О маленьком фильме с большой душой // Юный художник. 2020. № 12. С. 47–48.

*Kuznetsova E., Goryacheva O., Patenko G.* The problem of national identity. Concepts of ethnos and nation // 3rd International Multidisciplinary Scientific Conference on Social Sciences and Arts SGEM. 2016. Book 3. Vol. 2. P. 907–916.

***Самсонов Максим Николаевич,***

*ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Сәнгать белеме үзәге аспиранты*

УДК 398

*И.И. Ямалтдинов*

## ФОЛЬКЛОРЧЫ ГАЛИМ ХӘМИТ ЯРМИ

Статья посвящена анализу научной и научно-организационной деятельности первого доктора филологических наук по фольклористике, заслуженного деятеля науки Татарстана, лауреата Государственной премии Республики Татарстан имени Габдуллы Тукая, выдающего татарского фольклориста Хамита Ярми. В работе рассматриваются основные направления его исследований. Особое внимание уделяется созданию учёным собственной научной школы.

**Ключевые слова:** татарская фольклористика, Хамит Ярми, сектор фольклора, отдел народного творчества ИЯЛИ имени Г. Ибрагимова, собирание татарского фольклора, фольклорные научные экспедиции, татарское устное народное творчество, научное изучение татарского фольклора.

The article is devoted to the analysis of scientific and scientific-organizational activities of the first Doctor of Philology in folklore, Honored Scientist of Tatarstan, Laureate of the Gabdulla Tukai State Prize of the Republic of Tatarstan, outstanding Tatar folklorist Hamit Yarmi. The main directions of research are considered. Special attention is paid to the creation of scientists' own scientific school.

**Keywords:** Tatarian folklore, Khamit Yarmi, folklore sector, folk art department of the IYALI named after G. Ibragimov, collecting Tatar folklore, folklore scientific expeditions, Tatar oral folk art, scientific study of Tatar folklore.

2024 елның 5 маенда күренекле фольклорчы галим, Татарстанның атказанган фән эшлеклесе, Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләге лауреаты, филология фәннәре докторы Хәмит Ярминең (Габделхәмит Хөснетдин улы Ярмөхәммәтевнең) тууына 120 ел тулды.

Хәмит Ярми Төмән өлкәсе, Кырынкүл авылында 1904 елда туып, башлангыч белемне әтисе Хөснетдин мулладан ала, соңрак Ямбай авылындагы мәктәптә укый. Төмәндә педагогия училищесын тәмамлый. 1930–1933 елларда Казан педагогия институтында белем ала. Институтны тәмамлаганнан соң, татар теле һәм әдәбияты кафедрасында аспирантурада укырга калдырыла. 1934–1939 елларда «Кызыл Татарстан» газетасы редакциясендә мәдәният бүлеге җитәкчесе, Татарстан Язучылар берлегендә җаваплы сәркатип, Татарстан китап нәшриятендә тәрҗемәче булып эшли.

1939 елда Татар теле һәм әдәбияты фәнни-тикшеренү институты (хәзерге вакытта Татарстан Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты) ачыла. Институт оешу белән Х. Ярмөхәммәтев өлкән фәнни хезмәткәр, фольклор секторы мөдире булып эшли башлый. Фольклорчы буларак формалашкан галим сектор эшчәнлегенең төп юнәлешләрен, гомумән, фольклористикада кабул ителгәнчә, дөрес итеп, түбәндәгечә билгели: халык иҗаты әсәрләрен җыю өчен фәнни экспедицияләр оештыру; фольклор текст-

ларын әзерләп бастыру; халык иҗаты белән бәйле проблемаларны фәнни өйрәнү. Күрсәтелгән өч юнәлеш буенча эшен планлы рәвештә башлап җибәрә.

Халык авыз иҗаты әсәрләрен халыктан җыюның төп алымы булып, әлбәттә, фәнни экспедицияләр тора. Һәм 1940 елда, әлеге юнәлештә беренче адым буларак, Себергә Х. Ярми җитәкчелегендә «Академик В.В. Радлов эзләреннән» беренче комплекслы экспедиция оештырыла. Бу сәфәр вакытында 80 көйнең ноталары, 4 эпос, 136 әкият, 18 бәет, 1500 җыр һәм 200 мәкаль язып алына. Танылган фольклорчы галим Ф.И. Урманче фикеренчә, әлеге экспедициянең иң җитди нәтиҗәләреннән берсе – мәшһүр «Идегәй» дастанының аерым вариантлары язып алыну [Урманче, б. 9]. Шул ук 1940 елда Татарстанның Бондюг, Красный бор һәм Әгерҗе районнарына, эшчеләр фольклорын өйрәнү өчен, фольклор экспедициясе җибәрелә. Аның эше белән дә Х. Ярми җитәкчелек итә. 1942–1944 елларда Х. Ярмөхәммәтев институт директоры вазифаларын башкара, ләкин «җитди хаталар» җибәрүе сәбәпле, әлеге эшеннән алына. Галимнең «Идегәй» дастанын өйрәнә башлавы дәүләт тарафыннан әнә шулай бәяләнә һәм декабрь аеннан ул Институтта татар фольклоры буенча өлкән фәнни хезмәткәр булып эшли башлый (1961 елдан фольклор һәм сәнгать тарихы секторы мөдире итеп билгеләнә).

Халык иҗатын системалы рәвештә җыю һәм өйрәнү эше, Тел, әдәбият һәм тарих институты СССР Фәннәр академиясенең Казан филиалы составына кертелгәч, 1946 елда башлана.

1945–1950 елларда Институт тарафыннан 11 фольклор экспедициясе оештырыла. Фольклорчылар 200 дән артык торак пунктта булып, барлыгы 243 әкият, 20 меңнән артык җыр-такмак, 96 бәет, меңгә якын мәкаль, әйтем һәм табышмаклар, 362 җыр тексты белән халык уеннарын язып алалар [Ярмухаметов, 1957, с. 173–181].

1951–1955 елларда татар фольклоры фондын баету эше тагын да киңрәк җәелдерелә. Татарстан районнарына яңадан 5 фольклор экспедициясе һәм 4 махсус сәфәр оештырыла, һәм шуның белән республика районнарында әлеге эшкә нокта куела. Шушы экспедицияләр дәвамында галимнәр 38 меңнән артык җыр һәм такмак, 233 әкият, 515 мәкаль һәм әйтем, 87 бәет, 126 җыр тексты белән халык уеннары һәм 200 берәмлектән артык төрле характердагы материаллар (сөйләкләр, истәлекләр һ.б.) язып алып кайталар.

Татарстанда халык авыз иҗатын барлау, җыю эше, нигездә, бер тәртипкә салынгач, фольклорчыларга РСФСРның татар халкы яши торган башка өлкәләренә экспедицияләр оештыру мөмкинлеге ачыла. Һәм алар Х. Ярми җитәкчелегендә 4 республикада (Чувашия, Мордовия, Удмуртия, Марий Эл) һәм 13 өлкәдә (Киров, Пенза, Рязань, Оренбург, Әстерхан һ.б.) булалар.

Татар фольклорын өйрәнү белән беррәттән, Тел, әдәбият һәм тарих институты рус фольклорын җыю буенча да күп эшли. Бу юнәлеш белән фольклор төркеме фәнни хезмәткәре В.Ф. Павлова шөгыльләнә,

ул соңрак рус халык такмаклары (частушки) буенча кандидатлык диссертациясе яклый. Рус авылларына беренче фольклор экспедициясе 1946 елда оештырыла, ә 1950 елдан бу юнәлештәге эш планлы рәвештә алып барыла. Бу очракта М.Ф. Малкина (Юдино), М.Д. Гирдасова (Бондюг районы), Н.А. Ерохина (Алабуга районы) кебек талантлы җыр осталарының репертуарлары язып алыну игътибарга лаек, дип ассызыклый Х. Ярми [Ярми, 1940].

Шулай итеп, Х. Ярми 30 дан артык фольклор экспедициясе оештыра һәм аларның җитәкчесе була. 1920–1960 елларда халык авыз иҗаты әсәрләрен планлы рәвештә җыю нәтиҗәсендә, Институтның бай фольклор фонды булдырыла һәм төрле төр җыентыклар басмага әзерләнә.

1930 еллар ахры – 1940 еллар башыннан аерым оешмалар һәм язучылар, сәнгать әһелләре тарафыннан күпсанлы җыентыклар тупланып нәшер ителә башлый. Шулар рәтендә Х. Ярми һәм А. Әхмәт тарафыннан төзелгән һәм татар халык иҗатының төрле жанрларын үз эченә алган «Халык иҗаты» [Ярми, 1938] китабының икенче басмасы да [Ярми, 1940] дөнья күрә. Шул уңайдан язылган мәкаләсендә С. Гарипов әлеге җыентыкны, нигездә, уңай бәяли, әмма кайбер кимчелекләрне дә күрсәтә [Гарипов, б. 80–83].

1940 ел урталарына ук Х. Ярми белән Г. Бәширов ике томлы «Татар халык әкиятләре»нең беренче китабын басмага әзерләп бетерәләр, 1946 елда ул басылып чыга. Бөек Ватан сугышыннан соң Х. Ярми әлеге басмага кабат әйләнеп кайта һәм ул 1951 елда яңадан нәшер ителә. Бу китапка төп фольклор жанрларына караган халык иҗаты әсәрләре үрнәкләре кертелә һәм ул үзенә күрә югары уку йортларының филология факультетлары студентлары өчен дәреслек-хрестоматия ролен үти башлый, чөнки моңа кадәр татар фольклор жанрларының характеры, үзенчәлеге турында тулы мәгълүмат бирердәй җыентык булмый. Китапта Хәмит Ярминең тулаем татар халык иҗатына багышланган зур күләмле мәкаләсе урын алган. Аның беренче өлеше татар фольклористикасы тарихына багышланган. Анда автор шул елларга хәтле фольклорчыларның игътибарыннан читтә калып килгән чыганакларга мөрәҗәгать итә. Аннан соң Х. Ярми төп татар фольклор жанрларының һәркайсын (әкият, бәет, җыр, мәкаль-әйтемнәр, табышмаклар), Совет чоры фольклоры кебек моңарчы өйрәнелмәгән мәсьәләне фәнни яктан анализлый. Җыентыкта санап үтелгән жанр төрләренең иң яхшы үрнәкләре китерелгән, китапның фәнни аппараты да тиешле югарылыкта эшләнгән. Әлеге антология шул чор вакытлы матбугатында югары бәя ала һәм тиз арада халыкка таралып бетә [Фәттах, 1951, б. 119–125].

1954 елда Х. Ярми (баш редактор), Г. Бәширов, Х. Госман һәм А. Шамов тарафыннан әзерләнгән «Татар халык иҗаты» антологиясенең икенче басмасы дөнья күрә. Әлеге җыентык ярты гасырдан артык милли мәктәпләр, педагогия училищелары, югары уку йортлары өчен дәреслек һәм хрестоматия булып хезмәт итә.

1956 елда ике томлы «Татар халык әкиятләре»нең икенче китабы басылып чыга [Ярмухаметов, 1956]. Фольклорчы галим Ф. Урманче ассызыклаганча, әлеге басмалар татар фольклористикасында принципиаль яңа төр җыентыклар булып, үзләренең фәнни әһәмиятләрен әле бүген дә югалтмыйлар [Урманче, б. 11].

Х. Ярми алга таба да халык иҗаты әсәрләре үрнәкләреннән торган җыентыклар әзерләп бастыру эшен дәвам итә. Шундыйларның берсе – 1960 елда чыккан «Бәетләр» җыентыгы. Фольклорчы галим Х. Мәхмүтов язганча, Х. Ярми бәет жанрының теориясенә һәм тарихына караган бик күп мөһим фикерләр әйтеп калдырган [Мәхмүтов, б. 52–53].

Х. Ярми тарафыннан рус телендә әзерләнеп, Мәскәүдә нәшер ителгән (1952, 1957, 1964, 1976 елларда) татар әкиятләре җыентыклары («Гульчечек», «Татарские народные сказки», «Находчивый джигит») кытай, венгр, словен, әрмән, литва, украин, үзбәк, төрекмән, казакъ һәм башка халыкларның телләренә дә тәрҗемә итеп бастырылган [Ахметова, 1984, с. 100–101].

Х. Ярми – халык иҗаты әсәрләрен яңадан халыкка кайтаруга бик күп көч һәм хезмәт куйган зыялы зат. Аның тарафыннан яисә аның катнашында төзеп бастырылган җыентыкларның саны ике дистәдән артып китә [Надиров, 2004, б. 19].

Шул рәвешле, Х. Ярми тарафыннан әзерләп бастырылган фәнни җыентыкларны ике төргә бүлеп карарга мөмкин. Беренчесе – төп татар фольклоры жанрларының барысын да үз эченә алса, икенчесе – аерым бер жанрга гына багышланган. Бу җыентыклар – Х. Ярминең зур һәм төпле фәнни эшчәнлеге нәтиҗәсе. Һәм алар барысы да фольклор җыентыгына куелган катгый таләпләргә туры китереп эшләнгән: кереш һәм искәрмә-комментарийлары да, фәнни аппараты да бар. Материал җыю, аның өстендә киң планлы теоретик тикшеренүләр алып бару, җыентыклар төзү һәм бастырып чыгару тәҗрибәсе академик күптомлыклар әзерли башларга мөмкинлек бирә. 1960 еллар ахырында зур коллектив хезмәт – күптомлы татар фольклоры җыелмасын төзү проекты эшләнә [Ямалтдинов, 2012, 2016]. 12 томлы «Татар халык иҗаты»ның 3 китаптан торган әкият томнарының баштагы икесен Х. Ярми һәм гомере буе фольклор секторында эшләп, күпсанлы экспедицияләрдә дә, шулай ук бихисап җыентыклар әзерләгәндә дә аның беренче ярдәмчесе булган Халидә Гатина төзиләр.

1989 елда әлеге 12 томлык фундаменталь басманы әзерләүдә катнашкан бер төркем галимнәр, шул исәптән Х. Ярми дә (вафатыннан соң), Татарстанның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясенә лаек булалар.

Фольклористиканың фән буларак өйрәнелергә тиешле өлешен аның тарихы тәшкил итә. Татар фольклорына һәм фольклористика тарихына озак еллар дәвамында филологлар әллә ни игътибар бирмиләр. Татар фольклоры тарихын профессиональ дәрәҗәдә тикшергән Хәмит Ярмине, хаклы рәвештә, аны беренче өйрәнүче дип атарга

була. Әлеге мәсьәләләр аның кандидатлык диссертациясендә күтәрелә [Ярмухаметов, 1947]. Шушы юллар авторының махсус мәкаләсе нәкъ менә шуны анализлауга багышланган [Ямалтдинов, 2009, с. 91–92].

Фольклорчы галим Х. Мәхмүтов 40 ел гомерен халык иҗатын өйрәнүгә багышлаган Хәмит Ярмине «универсаль фольклорчы» дип атый [Мәхмүтов, б. 52–53]. Элгәрләреннән аермалы буларак, ул барлык жанрлар, татар фольклористиканың бөтен юнәлешләре буенча системалы тикшеренүләр алып бара. Х. Ярминең фәнни кызыксынулар диапазоны киң була, әмма галим төп игътибарын фольклорга юнәлтә. Ул гомере буена ару-талуны белмичә халык җәүһәрләрен җыючы, тикшерүче, бастырып, аларны яңадан халыкка кайтаручы була.

Хәмит Ярми бу өлкәне әзерлекле кадрлар белән тәэмин итүгә дә зур игътибар бирә. 1950 еллар ахыры – 1960 елларда аның йогынтысыярдәме белән татар халык иҗатының аерым жанрларын, фольклор һәм әдәбият бәйләнешләрен тикшерүгә багышланган кандидатлык диссертацияләре яклана.

1960 еллар ахырына кадәр татар халык иҗатының барлык жанрларын тикшерүне колачлаган теоретик хезмәт булмый. Һәм 1967 елда Х. Ярминең «Татар халкының поэтик иҗаты» [Ярми, 1967] монографиясе дөнья күрә. Бу – татар фольклоры монографик планда тикшерелгән беренче хезмәт. Галим үзенең фольклористик эшчәнлеген халык авыз иҗатын җыю, язып алудан башлап, масштаблы тикшеренүләргә таба бара, җыелган материалларны өйрәнеп һәм гомумиләштереп, билгеле бер фәнни нәтиҗәләргә килә. 1969 елны, татар фольклорчыларыннан беренче булып, Казакъстан Фәннәр академиясендә, алда күрсәтелгән тема буенча докторлык диссертациясе яклый һәм аның хезмәте фольклористика фәненә кертелгән саллы өлеш буларак бәяләнә [Ямалтдинов, 2012, № 1, с. 136–139; Ямалтдинов, 2016].

Хәмит Ярми – татар фольклоры фәнен киң ачышлар дөньясына алып чыккан галим. Язган хезмәтләре – бүгенге көндә татар фольклорчыларының инде өч-дүрт буынын берләштергән академик мәктәбе – галимнең иң зур мирасы. Һәрьяклап та беренче булган Хәмит Ярминең татар фәненә багышланган нәтиҗәле хезмәтләре һичкайчан үзенең кыйммәтен югалтмас.

**Әдәбият**

*Ахметова Ф.В.* Фольклор и современная татарская проза: автореф. дис. ... канд. филол. наук. Казань. 1968. 24 с.

*Ахметова Ф.В., Галиуллин Т.Н.* Хамид Хуснутдинович Ярмухаметов: К восьмидесятилетию со дня рождения // Советская тюркология. 1984. № 3. С. 100–101.

*Галиуллин Т.Н.* Современная татарская поэзия и народное творчество: автореф. дис. ... канд. филол. наук. Казань. 1968. 30 с.

*Гарипов С.* Халык иҗаты: шул исемдәге җыентык турында // Совет әдәбияты. 1941. № 4. Б. 80–83.

*Касимов Э.* Сатира и юмор в татарских народных сказках: автореф. дис. ... канд. филол. наук. Казань. 1966. 27 с.

*Махмутов Х.Ш.* Татарские народные загадки: автореф. дис. ... канд. филол. наук. Казань. 1969. 31 с.

*Мәхмүтов Х.* Беренче профессиональ фольклорчыбыз // Хәмит Ярми. Галим һәм шәхес: мәкаләләр, истәлекләр, хатлар / төз. Х.Ш. Мәхмүтов. Казан: Татар. кит. нәшр. 2004. Б. 52–53.

*Надиров И.* Олуг галим, хөрмәтле остаз // Хәмит Ярми. Галим һәм шәхес: мәкаләләр, истәлекләр, хатлар / төз. Х.Ш. Мәхмүтов. Казан: Татар. кит. нәшр., 2004.

*Надиров И.* Халык һәм җыр: Бөек Ватан сугышы чорында татар халык поэтик иҗаты. Казан: Татар. кит. нәшр. 1961. 192 б.

*Урманче Ф.* Хәмит Ярми һәм бүгенге татар фольклористикасы // Хәмит Ярми. Галим һәм шәхес: мәкаләләр, истәлекләр, хатлар / төз. Х.Ш. Мәхмүтов. Казан: Татар. кит. нәшр. 2004. Б. 7–16.

*Урманчеев Ф.И.* Пути развития жанров татарского советского народно-поэтического творчества: дис. … канд. филол. наук. Казань. 1968. 20 с.

*Фәттах Н.* Татар халык иҗаты җыентыгы // Совет әдәбияты. 1951. № 10. Б. 119–125.

*Ямалтдинов И.И.* Весомый вклад в фольклористику (60-е гг. XX века) // Научный Татарстан. 2012. № 1. С. 136–139.

*Ямалтдинов И.И.* Первый историограф татарской фольклористики // Актуальные проблемы современной фольклористики: материалы Междунар. науч.-практ. конф. (Казань, 29 июня 2009 г.). Казань. 2009. С. 91–92.

*Ямалтдинов И.И.* Татарская фольклористика 20–60-х гг. XX века. Собирание, публикация и научное изучение фольклора. Казань: ИЯЛИ, 2016. 184 с.

*Ямалтдинов И.И.* Татарская фольклористика 20–60-х гг. XX века: автореф. дис. ... канд. филол. наук. Казань, 2012. 30 с.

*Ярми Х.* Татар халкының поэтик иҗаты. Казан. 1967. 307 б.

*Ярми Х., Әхмәт А.* Халык иҗаты. Казан: Татгосиздат, 1938. 167 б.

*Ярми Х., Әхмәт А.* Халык иҗаты. Икенче басма. Казан: Татгосиздат, 1940. 270 б.

*Ярмөхәммәтев Х., Бәширов Г.* Татар халык әкиятләре. Казан: Таткнигоиздат. 1956. 396 б.

*Ярмухаметов Х.Х.* Татарская советская фольклористика за 40 лет // Известия Казанского филиала АН СССР: Юбилейный сборник. Казань, 1957. С. 173–181.

***Ямалтдинов Ильмир Илдар улы,***
*филология фәннәре кандидаты, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының халык иҗаты бүлеге әйдәп баручы фәнни хезмәткәре, бүлек мөдире*

УДК 82.09

***Л.Ш. Галиева***

# ГАЛИМ ҺӘМ ОСТАЗ
## (Хатыйп Миңнегуловка 85 яшь)

Данная статья является кратким обзором жизни и многосторонней деятельности известного учёного-литературоведа, доктора филологических наук, профессора Казанского государственного университета Хатипа Юсуповича Миннегулова в связи с его 85-летием. Основные труды учёного освещают татарскую литературу Средневековья. Кроме того, Х. Миннегулов большое внимание уделяет исследованию татарской литературы XIX и начала XX веков на примере отдельных авторов, татарской литературы зарубежья, литературных взаимосвязей родственных народов. Особый акцент сделан на сотрудничестве литературоведа с Институтом языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова Академии наук Республики Татарстан.

**Ключевые слова:** Хатип Миннегулов, юбилей, история татарской литературы Средневековья, литературные взаимосвязи, татарская литература зарубежья.

This article is a brief overview of the life and multifaceted activities of the famous literary scholar, Doctor of Philology, professor of Kazan State University Khatip Yusupovich Minnegulov in connection with his 85th birthday. The main works of the scientist cover the Tatar literature of the Middle Ages. In addition, H. Minnegulov pays great attention to the study of Tatar literature of the nineteenth and early twentieth centuries on the example of individual authors, Tatar literature abroad, literary interrelations of related peoples. Particular emphasis is placed on the cooperation of the literary critic with the Institute of Language, Literature and Art named after G. Ibragimov Academy of Sciences of the Republic of Tatarstan.

**Keywords:** Khatip Minnegulov, jubilee, history of Tatar literature of the Middle Ages, literary interrelations, Tatar literature abroad.

2024 елның 12 маенда күренекле әдәбият галиме, филология фәннәре докторы, Казан дәүләт университеты профессоры, Татарстанның һәм Россиянең атказанган фән эшлеклесе Хатыйп Йосыф улы Миңнегулов үзенең 85 яшьлек юбилеен билгеләп үтте. Татарстанның Зәй районы Апач авылында дөньяга килеп, ул башлангыч белемне туган авылында алганнан соң, күрше Пидәр (Федоровка) авылында җидееллык мәктәпне тәмамлый, аннан соң Сарман районының Иске Кәшер урта мәктәбендә белем ала. Фән дөньясына кереп киткәнче, Х. Миңнегулов төрле өлкәдә көчен сынап карый: Таҗикстанның Табошар шәһәре заводында эшче, мамык җыючы, туган авылында клуб мөдире булып та эшли ул.

1959 елда булачак галим Казан дәүләт университетының тарих-филология факультетына укырга керә. Соңгы курсларда, читтән торып уку бүлегенә күчеп, Пенза өлкәсе Белинский районы Качкару

(Кутеевка) авылында балалар укыта. Университетны тәмамлагач, үзе теләп, Сарман районына эшкә китә. Биредә ике ел Чукмарлы мәктәбендә директор, колхозның партоешма секретаре, аннан ел ярым КПССның район комитетында партия мәгарифе мөдире вазифаларын башкара.

1967 елның ноябрь аеннан Х. Миңнегуловның эшчәнлеге Казан дәүләт университетының татар әдәбияты кафедрасы белән бәйле. Биредә ул төрле елларда ассистент, доцент, профессор вазифаларын башкара. Әлеге уку йортында декан урынбасары, вакытлыча кафедра мөдире, 1999 елдан алып 2009 елга кадәр – татар әдәбияты тарихы кафедрасы мөдире, 2022 елдан исә – Казан (Идел буе) федераль университеты профессор-консультанты булып тора.

1972 елда яшь галим «Переводы и оригинальные произведения Саифа Сараи» дигән темага кандидатлык диссертациясе яклый. Әлеге хезмәт татар әдәбияты тарихын өйрәнү өлкәсендә билгеле бер яңа этапны башлап җибәрә дисәк тә хата булмас, чөнки Урта гасырлар әдәбиятының күп кенә авторлары, тарихи сәбәпләргә бәйле, озак еллар дәвамында күләгәдә калып килә иде. Әдәбиятчы галим М. Бакиров фәнни хезмәтне татар әдәбияты тарихында яңа бер адым буларак бәяли. Диссертация нигезендә 1976 елда «Сәйф Сараи. Тормышы һәм иҗаты» дигән монография дөнья күрә. Шушы елларда Х. Миңнегулов Урта гасырларның тагын бер шагыйре – Котб иҗатына багышлап фәнни хезмәтләр яза. Шул рәвешле, татар әдәбияты тарихында Алтын Урда дәверен торгызу буенча эш башланып китә.

1988 елда Х. Миңнегуловның «Шәрык һәм татар әдәбиятында кысалы кыйссалар» дип исемләнгән китабы басылып чыга. Биредә «Мең дә бер кичә», «Мең дә бер көн», «Мең дә бер сәхәр», «Кәлилә һәм Димнә», «Тутыйнамә» кебек «кысалы кыйссалар» өйрәнелә. Хезмәт Х. Фәезханов, Ф. Халиди, Г. Фәезханов, Ш. Рәхмәтуллин кебек күренекле татар галимнәренең тәрҗемәләрен чагыштырма планда анализлауга нигезләнә. Х. Миңнегулов, әсәрләрдән алынган мисалларга таянып, «кысалы кыйссалар»ның төрки-татар әдәбияты формалашуга һәм үсешенә табигый рәвештә керешеп киткәнен дәлилләп чыга.

1991 елда галим «Татарская литература и Восточная классика (Вопросы взаимосвязей и поэтики)» темасына докторлык диссертациясен яклый. Татарстан, Россия галимнәреннән тыш, хезмәтнең әһәмиятен чит ил белгечләре С.Г. Исаков (Эстония), К.А. Талыбзаде (Азәрбайҗан), С. Вахидов (Таҗикстан), Б. Касымов (Ташкент) һ.б. билгеләп уза. Ике елдан соң диссертация нигезендә монография басылып чыга. Шул рәвешле, Х. Миңнегулов Борынгы һәм Урта гасырлар әдәбиятларын өйрәнүдә, аларны Көнчыгыш мөселман әдәбиятлары белән бәйләп карауда үзен әйдәп баручы галим буларак таныта. Әлеге хезмәте өчен 1995 елда әдәбиятчы Фән һәм техника өлкәсендә Татарстан Республикасы Дәүләт премиясенә лаек була.

Х. Миңнегулов – XIX һәм XX гасыр татар әдәбиятын өйрәнүгә дә үзеннән саллы өлеш керткән галимнәребезнең берсе. Ш. Садретдинов

белән берлектә ул XIX гасыр татар әдәби ядкәрләрен бастырып чыгара, әлеге чорның татар хрестоматияләре турында киң планда мәгълүмат җиткерә. «Дөньяда сүземез бар...» (1999) һәм «Гасырлар өнен тыңлап» (2003) дип исемләнгән китапларында исә Котб, Хисам Кятиб, Мөхәммәдьяр, Колшәриф, Таҗетдин Ялчыгол, Ризаэддин Фәхреддин, Акмулла, Г. Тукай, Р. Гаташ һ.б. язучыларның иҗатларын өйрәнү белән беррәттән, төрек галиме Ф. Озканның эшчәнлегенә дә туктала, М. Ауэзов иҗаты турында уйлана, татар әдәбиятының дин белән бәйләнешен тикшерә.

Х. Миңнегулов 1990 елда татар телендә басылып чыккан «Әдәбият белеме сүзлеген» төзүдә дә катнаша. Аның аерым терминнарга, әдәбиятның теоретик мәсьәләләренә, әдәбият тарихына багышланган язмалары «Татар энциклопедия»сендә, «Татар халкы тарихы», Халыкара төрки академия бастырып чыгарган саллы хезмәтләрдә урнаштырылган. Галим мәктәп, югары уку йортлары өчен дәреслекләр авторы буларак та билгеле.

Х. Миңнегулов кызыксынган фәнни юнәлешләрнең тагын берсе – чит илләрдәге татар әдәбияты. 1999 елда ук ул «Исхакый мөһаҗирлектә» дигән хезмәтен киң җәмәгатьчелеккә тәкъдим итә. Әлеге китап Г. Исхакыйның эмиграциядәге чорын өйрәнү юлында шактый саллы хезмәтләрнең берсе булып санала. Монографиянең тулыландырылган варианты 2004 елда дөнья күрә. Моның өчен әдәбиятчы галимгә Татарстан Язучылар берлегенең Гаяз Исхакый исемендәге премиясе тапшырыла (2005).

Галимнең чит илләрдәге татарларның әдәбиятын өйрәнү өлкәсендә язылган фәнни мәкаләләре «Чит илләрдәге татар әдәбияты» (2007) дигән монографиядә туплап бирелгән. Биредә Хөсәен Габдүш, Сания Гыйффәт, Минһаҗ Исмәгыйли, Хәсән Хәмидулла кебек авторлар әсәрләреннән өзекләр дә китерелгән. Ул шулай ук Исфәндияр Ишгай, Әхмәд Ләбиб Каран, Шиһаб Нигъмәти, Әхмәд Гәрәй, Гәүһәр Туганай һ.б. әдипләр турында да укучыга үз мәкаләләрен җиткерде.

2010 елларда Х. Миңнегуловның тугандаш төрки әдәбиятларны өйрәнү өлкәсендәге фәнни эшчәнлеге аеруча активлаша. 75 яшьлек юбилеен билгеләп үткән көннәрдә ул рәттән берничә хезмәт чыгарып өлгерә. Шуларның «Тюркское словесное искусство» дигәне, «Төрки Академия»нең (Астана шәһәре) мөрәҗәгатенә җавап рәвешендә, Халыкара альманах өчен төрки сүз сәнгатенә күзәтү рәвешендә язылган. Хезмәттә төрки сүз сәнгате протөрки чордан алып XXI гасыр башына кадәр карала. Ягъни биредә төрки әдәбиятлар әдәби-тарихи, хронологик планда, бер-берсе белән бәйләнештә һәм иң күренекле әдипләргә басым ясап тикшерелә: Йосыф Баласагунлы, Әхмәд Ясәви, Кол Гали, Юныс Әмрә, Нәваи, Мәхтүмколый, Абай, Габдулла Тукай, Муса Җәлил, Чыңгыз Айтматов, Орхан Памук һ.б. Шушы ук елны дөнья күргән тагын бер китап «Этапы развития тюрко-татарской, античной и русской литератур» дип исемләнә. Әлеге әдәбиятларны нәкъ менә шушы тәртиптә өйрәнү, мөгаен, беренче мәртәбә тәкъдим ителәдер.

Китапның монографик өлеше әдәбиятларны чорларга бүлеп өйрәнү принциплары турында уйланудан башланып китә. Икенче бүлектә күренекле әдипләрнең иҗатларына нигезләнеп, төрки сүз сәнгате мәсьәләләре тикшерелә. Шул ук 2014 елда университет профессорының студентларга рус һәм татар телләрендә «Восточная классика и татарская литература» дигән уку әсбабы бастырыла. Биредә төрек-татар әдәби бәйләнешләре, төрек, үзбәк, азәрбайҗан, төрекмән, кырым татарлары әдәбиятларыннан аерым язучылар иҗаты тикшерелә. 2016 елда галим укучыларга «Идея государственности в тюрко-татарской литературе VII–XVI вв.» дип исемләнгән монографиясен тәкъдим итә.

Озак еллар дәвамында университет профессоры Татарстан Фәннәр академиясенең Тел, әдәбият һәм сәнгать институты белән дә хезмәттәшлек итеп килде. Аның мәкаләләре алты һәм сигез томлы «Татар әдәбияты тарихы» кебек академик басмаларда урын алды. Ул фән йорты оештырган халыкара чараларда теләп катнаша. Галим – Тукай энциклопедиясенә кертелгән 150 гә якын мәкаләнең авторы. 2014 елда, «Төрксой» Халыкара оешмасы тарафыннан Казан шәһәре төрки дөньяның мәдәни башкаласы итеп игълан ителгәннән соң, Институтта уздырылган Халыкара фәнни-гамәли конференция дә Х. Миңнегулов киңәшлегендә уза. Әлеге чара уңаеннан бастырып чыгарылган «Без – бер тамырдан» дип исемләнгән китапның К.М. Миңнуллин белән берлектә эшләнгән кереш мәкалә автордашы да, фәнни редакторы да – Х. Миңнегулов.

Галим – татар, рус, төрек, инглиз, казакъ, төрекмән һ.б. телләрдә басылган меңнән артык мәкалә авторы. Ул Мәскәү, Петербург, Уфа, Төмән, Самара, Хельсинки, Истанбул, Әнкара, Ташкент, Төркестан, Астана, Костанай, Пекин, Семей, Дүшәнбе һәм кайбер башка шәһәрләрдә лекцияләр укый, конференцияләрдә, конгресс-симпозиумнарда доклад-чыгышлар ясый. Актив җәмәгать эшлеклесе буларак, күп кенә мактаулы исемнәргә лаек була. Х. Миңнегуловның фәнни-педагогик эшчәнлегенә багышланган мәкаләләр арасында Ш. Абилов, Г. Саттар-Мулилле, М. Бакиров, Т. Галиуллин, Р. Ганиева, Ә. Закирҗанов, Ә. Сибгатуллина, Р. Гаташ, Л. Лерон һ.б. бик күп күренекле әдипләребезнең язмалары, шигъри тәлгәшләре урын ала. Әлеге мәкаләләр галимнең киң күңелле, тугры хезмәттәш булуын дәлилли. Тел галиме Ф.С. Сафиуллина аны татар гуманитар фәннәрендә иң актив шәхес дип санаса, шагыйрь Р. Гаташ «шигъри җанлы галим» дип атый. Х. Миңнегулов – татар дөньясында гына түгел, гомумән, төрки дөньяда танылган, мактауга, хөрмәткә лаек булган шәхесләребезнең берсе. Сөенечле хәл: ул әле бүген дә үрнәк булырдай эшчәнлеген дәвам иттерә.

***Галиева Ләйсән Шәүкәт кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының әдәбият белеме бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре*

УДК 93/94

***Ә.Т. Сибгатуллина***

# КАЗАКЪ-ТАТАР ГАЛИМӘСЕ
## (Клара Шәйсолтан кызы Хафизовага 85 яшь)

Статья посвящена 85-летнему юбилею известного китаеведа, доктора исторических наук, профессора, академика Казахской национальной академии естественных наук К.Ш. Хафизовой. Мать Клары Шайсултановны – татарка Гарифа Нигматуллина – уроженка Сарыкташского района Оренбургской области, её семья была сослана в казахские степи на строительство железной дороги между Карагандой и Акмоллой. В статье приводятся сведения о жизни и научной деятельности К.Ш. Хафизовой, внёсшей огромный вклад в развитие востоковедческой науки в Казахстане.

**Ключевые слова:** Казахстан, востоковедение, китаеведение, татарско-казахские связи.

The article is dedicated to the 85th anniversary of the famous sinologist, Doctor of Historical Sciences, professor, academician of the Kazakh National Academy of Natural Sciences K.Sh. Khafizova. Clara Shaysultanovna's mother is a Tatar, Garifa Nigmatullina, a native of the Saryktash district of the Orenburg region, her family was exiled to the Kazakh steppes to build a railway between Karaganda and Akmolla. The article provides information about the life and scientific activities of K.Sh. Khafizova, who made a huge contribution to the development of oriental science in Kazakhstan.

**Keywords:** Kazakhstan, Oriental studies, Sinology, Tatar-Kazakh connections.

Алма-Атада яшәүче күренекле галимә Клара Шәйсолтан кызы Хафизова белән мин узган ел гына таныштым. 2023 елның көзендә электрон почтама бер хат килеп төште, хат авторы интернет челтәреннән минем бер фәнни мәкаләмне укуы, анда телгә алынган вакыйгаларны үз күзе белән күрүе турында язган иде. Ул мәкаләдә мин 1958 елда Азия һәм Африка илләре язучыларының Ташкентта узган I конференциясе һәм әлеге форумда Төркияне бердәнбер язучы Назыйм Хикмәт тәмсил итүе хакында чыганаклар китергән идем. Клара ханым ул вакытта Ташкент университетында студент булуы, конференция эшләрендә актив катнашып йөреп, дөньякүләм танылган язучыларның чыгышларын «галерка»да тыңлавы турында хатирәләре белән бүлешкән иде. Хат азагында 1975 елда Алма-Атада узган V Азия-Африка илләре язучылар конференциясе хакында да материал сораган һәм үзләрендә шул уңайдан узачак җыелышта катнашырга чакырган иде. Исеме дә, фамилиясе дә бик татарча булып тоелган бу шәхес турында мәгълүмат эзләп, мин дә интернетка мөрәҗәгать иттем. Клара ханым Хафизова – тарих фәннәре докторы, профессор, табигать фәннәре буенча Казакъ милли академиясе академигы икән. Казакъстан-Кытай тарихи мөнәсәбәтләре

буенча олпат галимнәрнең берсе буларак, кыйммәтле фәнни хезмәтләре белән танылган шәхес. Шактый өлкән яшьтә булуына карамастан, һаман актив рәвештә фән белән шөгыльләнә, Казакъстанда русча чыга торган «Мысль» журналында даими язмалар бастырып тора икән. Язышуларыбыз дәвам итә торды, мин ул теләгән тема буенча бер мәкалә әзерләп җибәрдем һәм ул тиз арада басылып та чыкты. Гыйльми хезмәттәшлек белән беррәттән, шәхси дуслыгыбыз да арта төшкәч, мин аңа «Клара апа» дип, ул миңа исә гаять тә җылы итеп «иркәм» дип эндәшә башлады, «җан тартмаса, кан тарта» дигән әйтем никадәр дөрес, җаныма якын бу апаның әнкәсе татар икәнен дә белгәч, аңа булган игътибарым һәм хөрмәтем икеләтә арта төште бугай.

Әнисе Гарифә Гибадрахман кызы Нигъмәтуллина Оренбург өлкәсе Сарыкташ районы Кылчым авылында укымышлы гаиләдә дөньяга килә. Бик яшьли әнисез калган Гарифә үги ана тәрбиясендә үсә, 10–11 яшенә җиткәндә, аларның гаиләсе репрессиягә дучар була, барлык мал-туары, өйләре совет власте тарафыннан тартып алына, башка баерак, кулак дип игълан ителгән гаиләләр белән берлектә, теплушка вагоннарына төяп, Караганда якларына сөргенгә җибәрелә. Юлда күргән авырлыклар, яңа туган энекәшенең үлеме Гарифәгә бик авыр тәэсир итә. Әтисе Гибадрахман белән үги әнисе Сәмига Караганда-Акмолла тимер юлы төзелешенә эшкә җибәрелә, Гарифә рус мәктәбендә күпсанлы репрессияләнгән милләт вәкилләренең балалары белән бергә укый, аннан соң педагогия училищесына керә. 1938 елда казакъ егете Шәйсолтан Капезовка (соңыннан фамилиясен «дөрес»итеп, Хафизов дип теркәтә) кияүгә чыга. Укытучылар институтының тарих-география факультетын бетергән Шәйсолтан әфәндене Акыр-Түбә мәктәбенә укытучы итеп билгеләделәр. 1939 елда балалары Клара, бер елдан соң икенче кызлары Диләрә туа. Шәйсолтан Бөек Ватан сугышыннан яраланып кайткач, башта Җамбул өлкәсенең Свердлов районында Дехкан колхозында яшиләр, соңрак Михайловка авылына күчәләр, ире мәктәп директоры, Гарифә исә укытучы булып эшли. Алтмыш елдан артык авылда балалар укыткан ханым Казакъстан ССРның халык мәгарифе отличнигы исеменә лаек була.

Бөек Ватан сугышы чорында МТСта эшләгән Гибадрахман абзый, сөрген срогы беткәч тә, туган якларына кайтырга ашыкмый. 1960 елларда Гарифә апа Урта Азиядә торып калган туган-тумачасын эзләп таба, берничә тапкыр Оренбург өлкәсенә кайтып, архивлардан гаиләсенең репрессияләнүе белән бәйле документларны эзли, гомеренең азагына кадәр әтисенең аклануы өчен көрәшеп йөри.

1946 елдан башлангыч казакъ мәктәбендә укый башлаган Клара, депортациягә эләгеп, ул якларга китерелгән төрле милләт балалары белән русча аралашып үсә, алар белән берлектә колхоз эшләрендә ярдәм итә, җәйге елларда бабасы Гибадрахман янына Акыр-Түбәгә

кайтып йөри. Ул җиденче класста укыганда, гаиләләре белән район үзәгенә күченәләр һәм ул анда рус мәктәбендә укый. Кулына нинди китап яки журнал эләксә, барысы белән танышып барган Кларaның кытай телен һәм мәдәниятен өйрәнү хыялы да нәкъ менә шул балачакта укыган китаплардан башлана, күрәсең. Университетка ташламалы керү өчен ике ел эш стажы кирәк булган чорлар була ул заманнар. Клара да, урта мәктәпне бетергәч, 1956–1957 елларда урта мәктәптә ике ел пионервожатый булып эшли һәм 1958 елда Ташкенттагы Урта Азия дәүләт университетының Көнчыгыш телләр факультетына керә. Ул укыган кытай бүлегендә зур белгечләр һәм Кытайда озак еллар торып кайткан рус эмигрантлары эшли, Клара алар белән тыгыз элемтәдә яши, студентларның иҗтимагый тормышында, мамык җыю кебек дәүләткә ярдәм итү эшләрендә актив катнаша. 4 курста укыганда СССР Мәгариф министрлыгы линиясеннән Пекин университетына стажировкага бара һәм кытай халкының тормышы, культурасы белән якыннан таныша, диплом эше буенча материал җыя. 1964 елда университетны тәмамлаганнан соң, кытай теле укытучысы буларак, Сәмәркандка эшкә җибәрелә, бу чорда үзбәк һәм таҗик телләрен дә үзләштерә. Алма-Атага кайтканнан соң, башта бер фәнни институтка тәрҗемәче булып урнаша һәм техник текстларны тәрҗемә итү белән шөгыльләнә. Кияүгә чыгып, шәхси тормышын җайга салган вакытта Мәскәүдә Көнчыгышны өйрәнү институтының Кытай бүлегенә аспирантурага керү мөмкинлеге туа, укып бетергәч республикага кайту шарты белән, Мәскәүдәге чыгымнарын Казакъстан түлисе була. Беренче баласына авырлы булуга карамастан, Клара ханым, Мәскәүгә барып, керү имтиханнарын тапшыра һәм үзе теләгән фән юнәлешендә уку-эшләү мөмкинлеге таба. Бала туып, үсә төшкәч, ире дә Мәскәүдә аспирантурага кергәч, яшь гаиләнең тормышы бераз җайлана төшә. Бу СССР белән Кытай арасындагы чик буенда коралллы конфликтлар көчәйгән 1969 ел була. Һәм сәясәт, һәм мәдәният җәһәтеннән әһәмиятле булган «XVIII гасырның икенче яртысында Цин империясе белән казакъ ханлыкларының үзара мөнәсәбәтләре» дигән темага кандидатлык диссертациясен яза башлый. Моңа кадәр фәнни әйләнешкә кермәгән яки аз билгеле кытайча кулъязмаларга һәм иске китапларга, сәяси архив документларына таянып язылган бу хезмәтнең фәнни-практик әһәмияте шундадыр ки: моңа кадәр гел Россия һәм Кытай кебек ике зур держава арасындагы икътисади, сәяси-дипломатик мөнәсәбәтләргә басым ясалса, Клара ханым бу төр бәйләнешләрне турыдан-туры казакъ тарихы җирлегендә тикшерә һәм кызыклы ачышлар ясый.

1974 елда Мәскәүдә диссертациясен уңышлы яклап, туган якларына кайткач, Клара ханым Казакъстан ССР Фәннәр академиясенең Ч. Вәлиханов исемендәге Тарих, археология һәм этнография институтында, 1986 елдан уйгурларны өйрәнү институтында фәнни хезмәт-

кәр булып эшли, 1991 елда Казакъ дәүләт университетына кытай филологиясе кафедрасын җитәкли. Биш томлык «Казакъстан ССР тарихы»н язу, 220 томлык кытай чыганаклары тупланмасын эшкәртү һәм тәрҗемә итү эшендә катнаша, кытай телен укыту, яңа буын шәкертләр тәрбияләү өлкәсендә үзеннән өлеш кертә. Бу чорда аның фәнни эшчәнлеге тагын да киңәя: Кытайда яшәгән казакълар һәм уйгурлар турында күп материал туплый, казакъ халкының борынгы тарихын кытай чыганаклары буенча тикшерә, казакъ ханнарының чит өлкәләр белән бәйләнешләрен, Казакъстан-Синьцзян мөнәсәбәтләре тарихын архив чыганакларына, аеруча борынгы кытай телендәге язмаларга таянып өйрәнә. Шул рәвешле, казакъ халкы тарихын гына түгел, Казакъстанның ут күршесе Кытайны өйрәнү фәненең масштабын киңәйтү һәм тирәнәйтү эшенә үзеннән мөһим өлеш кертә. Мәгърифәтче галим һәм сәяхәтче Чокан Вәлихановның мирасын туплау эшенә катнашып, Кытай белән бәйле әсәрләренә комментарийлар яза. Казакъстан Республикасы Президенты каршындагы Стратегик тикшеренүләр институтында эшләгән дәвердә «Үзәк Азиядә Кытай дипломатиясе» исемле монографиясе нигезендә, 1995 елда Мәскәүдә докторлык диссертациясен яклый. Алга таба Казакъстанның тышкы һәм эчке сәясәтендәге стратегик проблемаларны өйрәнеп, республиканың киләчәге белән бәйле аналитик прогнозлар хәзерләү кебек дәүләт идарәсе өчен кирәкле документлар төзи. 1998–2011 еллар арасында «Кайнар» университетында халыкара мөнәсәбәтләр факультетында укыта. Казакъстанның бүгенге президенты Касыйм-Җомарт Токаевның тарих фәннәре буенча язган кандидатлык диссертациясенең рәсми оппоненты була.

К.Ш. Хафизова Казакъстанның төрле фәнни оешмаларында эшләгән дәвердә Кытай, Тайвань, АКШ, Үзбәкстан, Япония, Швеция университетларына барып, лекцияләр укый, семинарлар уздыра, Англия, Әфганстан, Иран, Кытай кебек илләрдә оештырылган фәнни конференцияләрдә катнаша. Аеруча Цин империясе тарихын өйрәнү максатында, Кытайның Халык университетында һәм Синьцзян университетында академик тикшеренүләр оештыра.

Соңгы елларда басылган хезмәтләренә килгәндә, «Степные властители и их дипломатия в 18–19 веках» исемле китабын күрсәтергә кирәк, анда XVIII–XIX гасырларда казакъ далаларындагы сәяси халәт, өч буын казакъ ханнарының тормышы катлаулы халыкара мөнәсәбәтләр фонында анализлана. Моннан кала, 2007 елда Клара Шәйсолтан кызының «Мәдәниятләр диалогында Казакъстан һәм Кытай», «Цин империясенең казакъ стратегиясе» исемле монографияләре басылып чыга. 2015 елда «Ефәк юлында мәдәниятләр диалогы» исемле китабы нәшер ителә.

Белгәнебезчә, Кытай үзенең архивларын чит ил белгечләренә бик теләп ачмый, К.Ш. Хафизова – БДБ галимнәре арасында беренчеләрдән булып, кытай императорлары яшәгән «Гугун» сарае кебек

«ябык» архивларга хәтле кереп, тикшеренүләр оештыра алган шәхес. Казакъстанда Клара Шәйсолтан кызын яраталар, хөрмәт итәләр, быел да олуг юбилее уңаеннан аның белән бәйле чаралар оештырыла. 2021 елда К.Ш. Хафизова үзенең бай шәхси китап коллекциясен Казакъстан Республикасы Милли китапханәсенә бүләк иткән иде. Быел исә Казакъстан Үзәк архивында аның шәхси фондын тәкъдим итү тантанасы булачак. Әнисе ягыннан татар кызы булган Клара ханымны без дә чын күңелдән матур юбилее белән котлыйбыз, ару-талуны белмичә фән өлкәсендә башкарган эшләренә сокланабыз, киләчәктә дә күңел күтәренкелеге, ныклы сәламәтлек телибез.

***Сибгатуллина Әлфинә Таһир кызы,***
*филология фәннәре докторы, профессор,*
*Россия Фәннәр академиясе Көнчыгышны өйрәнү институтының*
*әйдәп баручы фәнни хезмәткәре*

УДК 82.09

***Г. Сәгъди***

# ӘДӘБИЯТЫБЫЗНЫ МӘДРӘСӘЛӘРДӘ УКЫТУ

В марте этого года исполнилось 115 лет со дня рождения выдающегося литературоведа, филолога, критика и педагога Габдрахмана Саади. В настоящей публикации вниманию читателей предлагаются статьи учёного «Преподавание литературы в медресе» (Шура. 1910. № 18) и «Вопрос преподавания в мектебе (один из важнейших вопросов в программе начальной школы)» (Шура. 1917. № 14, 15). Автор выражает неудовлетворенность сложившейся системой обучения в мусульманских учебных заведениях и ставит вопрос преобразования медресе. В частности, Г. Саади выступает за немедленное введение преподавания татарского языка и литературы в национальных учебных заведениях и обосновывает значимость этого шага. Эти и другие проблемные статьи Г. Саади, опубликованные в журналах «Шура» и «Мектеп», высоко оценивались современниками.

**Ключевые слова:** Габдрахман Саади, татарская литература, литературоведение, татарская периодическая печать, национальное образование.

This March marked the 115th anniversary of the birth of the outstanding literary critic, philologist and teacher Gabdrakhman Saadi. In this publication, readers are offered articles by the scientist “Teaching literature in madrasahs” (Shura. 1910. № 18) and “The issue of teaching in mekteb (one of the most important issues in the primary school curriculum)” (Shura. 1917. № 14, 15). The author expresses dissatisfaction with the current system of education in Muslim educational institutions and raises the question of the transformation of madrasahs. In particular, G. Saadi advocates the immediate introduction of the teaching of the Tatar language and literature in national educational institutions and justifies the importance of this step. These and other problematic articles by G. Saadi, published in “Shura” and “Mektep” magazines. That publications were highly appreciated by contemporaries.

**Keywords:** Abdrakhman Saadi, Tatar literature, literary criticism, Tatar periodical press, national education.

*Татар теле һәм әдәбиятын үстерүгә гаять зур өлеш керткән әдәбият галиме, педагог, тәнкыйтьче Габдрахман Сәгъдинең (Габдрахман Гайнан улы Сәгъдиев, 1889–1956) тууына быел 115 ел тула.*

*Булачак галим Уфа губернасы Златоуст өязе Тайми авылында мөдәррис гаиләсендә дөньяга килә. 1902–1906 елларда Троицк шәһәренең «Рәсүлия» мәдрәсәсендә белем ала. Биредә ул гарәп, төрек, фарсы телләрен өйрәнә, Көнчыгыш философиясе һәм тарихы белән кызыксына. 1906 елда мәдрәсәне тәмамлаганнан соң, ике ел дәвамында рус-татар мәктәпләрендә балалар укыта. 1908–1911 елларда Истанбулның педагогика университетында белемнәрен камилләштереп*

*кайткач, кабат мөгаллимлек эшенә чума, Урта Азия һәм Эчке Россия шәһәрләрендә балалар укыта.*

*Хезмәт юлын мөгаллим булып башлаган алдынгы карашлы егеттә, әлбәттә, укыту системасы, катып калган таләп-карашлар канәгатьсезлек уята. Гомумән, «җәдит мәктәпләр ачыла башлауга ук, аларда нәрсә укыту, ничек укыту мәсьәләсе татар матбугатының игътибар үзәгенә куела» [Габдрахман Сәгъди, б. 10]. Шуңа нисбәтән Г. Сәгъди дә үзенең фикерләрен матбугатта яңгырата башлый. 1910 елда «Шура» журналында аның «Әдәбиятыбызны мәдрәсәләрдә укыту» дигән мәкаләсе дөнья күрә. Анда Г. Сәгъди мәдрәсәләрдә әдәбият, тел укытуга игътибарның бер дә булмавына ачынып яза. «Бал тәмле дигән белән авыз балланмый», дигән халык мәкален китереп, «әдәбиятымызны укыту кирәк», «һәммә милләтләр үз әдәбиятларыны укыталар» димәк илән генә мәдрәсәләрдә әдәбиятымыз тәдрис ителә (укытыла. – Л.Г., Г.Х) башланмыйдыр», ди ул. Галим бу юлда кайбер каршылыкларны да күрсәтеп үтә, шулар аркылы мәсьәләне чишү юлларын тәкъдим итә. Иң беренче – дәреслекләр әзерләү, моның өчен исә матераил туплау зарур. Әдәбиятыбызны барлау, тәртипкә салу да төп шартларның берсе булып тора. Тәрбия эше, нигездә, гарәпчә алып барылганга һәм әлегә кадәр шулай дәвам иткәнгә күрә, үз телебезнең һич тә игътибарга алынмавын ассызыклый тәнкыйтьче. Телебез, әдәбиятыбызның кагыйдәләрен, тарихын язарлык әзерлекле кешеләрнең азлыгы, алгарыш юлында акча кытлыгы, иганәчеләрнең булмавы да төп киртәләрнең берсе булып торуын күрсәтә. Алга таба әдипнең «Шура», «Мәктәп» журналларында басылып чыккан проблемалы мәкаләләре дә укучыны битараф калдырмый, замандашлары тарафыннан югары бәяләнә.*

*Г. Сәгъдинең әдәби һәм гыйльми эшчәнлеге инкыйлабтан соң тагын да күтәрелеш ала, күпсанлы мәкаләләре дөнья күрә. 1925 елдан соң Казанда фундаменталь хезмәтләре басылып чыга. Алар арасында «Кешелек дөньясында тел, әдәбият, язу һәм аларның тарихи үсүләре» (1926), «Татар әдәбияты тарихы» (1926), «Татар театр әдәбияты һәм аның үсү тарихы» исемле саллы басмалар бар.*

## Әдәбиятыбызны мәдрәсәләрдә укыту

Мәдрәсәләремездә үз әдәбиятымызның тәгълим ителмәве[1] турысында кыска-кыска гына мәкаләләр газета сәхифәләрендә сирәк-сирәк кенә күренгәли. Бу мәкаләләр асыл әдәбият тәгълиме фикеренең хәтергә төшүенә, шул фикернең тәгълим әрбабы[2] арасында сеңүенә, гомуми мәтлабларымыз[3] арасында аның да саналуына хезмәт итсәләр дә, әдәбиятымызның дәрес программына кертелүе өчен бу

[1] Тәгълим ителмәве – укытылмавы.
[2] Тәгълим әрбабы – укыту әһелләре.
[3] Мәтлабрымыз – теләкләребез.

кадәр генә тәшәббесләр[1] җитмидер. Газеталарның да бу мәсьәләдә берсе берсенә фикер ялгамыйча, әле анысын, әле монысын гына кузгатып куюлары, бинаән галәйһи[2] әдәбият тәгълиме көяз мөхәррирләргә «модный тема» гына тәшкил итеп, әсаслы бер фикер тәгъкыйб ителмәве[3] мөляхәзәгә[4] алынса, ул мәкаләләрнең гыйльми әһәмияте цифр дәрәҗәсенә төшәдер. «Бал тәмле дигән белән авыз балланмый», диләр. Шуның шикелле «әдәбиятымызны укыту кирәк», «һәммә милләтләр үз әдәбиятларыны укыталар» димәк илән генә мәдрәсәләрдә әдәбиятымыз тәдрис ителә[5] башланмыйдыр.

Мәгариф нәзаратының ибтидаи тәгълим[6] хосусында Государственная Думага керткән ляихәсендә[7] инородецлар ике фиркагә бүленгән. Берсе – үзләренең теле вә әдәбияты эшләнгән милләтләр. Моңа немецлар, поляклар, латышлар керә. Икенчесе – әдәбияты эшләнмәгән милләтләр: татарлар, кыргызлар, сартлар, ягъни мөселманнар вә чувашлар ошбу фиркаләргә керәләр. Государственная Думада мөселман фракциясенең иң мөһим хезмәтләреннән берсе – Русиядә төрк-татар милләтенең әдәбиятлы идекләрене исбат итмәкдер. Немецлар, поляклар шикелле безнең дә әдәбиятымыз барлыкны исбат итә алсак, ул вакытта мәдәният галәмендә үземезнең «милләт уларак» мәүҗүдатымызны[8] исбат иткән буламыз. Һәм дә мәдәниятле милләтнең мөстәхикъ[9] булдыгы хокукларны таләп итәргә хаклы буламыз. Бер милләтнең әдәбияты барлыгы иң элек шул милләт ифрады[10] тарафыннан игътираф ителергә[11] тиеш түгелме? Безнең мәдрәсәмез бойлә әдәбиятымызны танымый вә таныйсы килмидер. Г. Думадагы Пуришкевичларның[12] телемезне вә әдәбиятымызны барга санамадыкларына эчемез поша. Аларга ачуланамыз. Үземезнең мәдрәсәләремез исә телемезне, әдәбиятымызны юкка санауда дәвам итәләр.

Хәер! Монда тәгаҗҗеб итәрлек[13] эш юк. Мәдрәсәләремезнең әдәбиятны игътираф итмәүләре – үзләренең укымауларыннандыр. Алар шуны белмәгән өчен таяк йиймәгәннәр[14]. Әдәбиятның ләззәтен дә татымаганнар. Ләкин тәәссефле[15] җәһәт – шуның яшь нәселемездә дә дәвам итүендәдер. Хәзер дә әдәбият укытуны мәдрәсә программына

[1] Тәшәббесләр – эш башкарулар.
[2] Бинаән галәйһи – шуның өстенә.
[3] Тәгъкыйб ителмәве – күзәтелмәве.
[4] Мөляхәзәгә – игътибарга.
[5] Тәдрис ителә – укытыла.
[6] Ибтидаи тәгълим – башлангыч белем.
[7] Ляихәсендә – проектында.
[8] Мәүҗүдатымызны – барлыгымызны.
[9] Мөстәхикъ – хаклы.
[10] Ифрады – ялгызы, бу очракта: үзе.
[11] Игътираф ителергә – танылырга.
[12] Пуришкевич Владимир Митрофанович (1870–1920) – рус сәяси эшлеклесе.
[13] Тәгаҗҗеб итәрлек – гаҗәпләнерлек.
[14] Таяк йиймәгәннәр – таяк ашамаганнар. «Кыен күрмәгәннәр»мәгънәсендә.
[15] Тәәссефле – үкенечле.

кертә алмыйлар. Моның өчен кирәк булган нәрсәләр хәзер түгел. Анысы юк, монысы юк, уникенең берсе юк дигән шикелле. Әдәбият тәдрисе өчен лязем булып та, бездә табылмаган нәрсәләрне йиңел кулдан гына санап карыйк.

Иң беренче – телемезнең кагыйдәләре тиешлечә җәмгъ кылынмаган[1], әдәбиятымызның ысул вә кәвагыйде истихраҗ кылынып[2] язылмаган, әдәбиятымызның тарихы тәртиб ителмәгән булуыдыр. Бу мәүзугларда[3] дәрес китабы түгел, дәрес китабы язарлык материаллар да матбугатымызда йитешмидер.

Әгәр дә назлырак булсак, дәрес китабы тотып язарга материал һич тә хәзер түгел диярgә мөмкиндер.

Икенче – әдәбиятымызның әле бик зәгыйфь дәрәҗәдә булып, үзен гомуми дәрескә салдырырлык вә гомумнең әһәмиятен вә ихласын җәлеп итәрлек дәрәҗәгә ирешмәведер. Иске әдәбиятымыз (егерменче гасыр башларына кадәр булган матбуг әсәрләр) яисә бик кадимгеләр[4] булып, тәрәккый юлына китмәенчә туңып калганнар яисә бөтенләе рухсыз язылган нәрсәләр вә әксәрисе[5] мөстәкыйль бер фикер вә илһам нәтиҗәсе булмаган нәкълият[6], биттәкълидәттән[7] гыйбарәттер. Яңа әсәрләр исә һичберсе матбугатта әсаслы тәнкыйтьтән кичерелмәгән, әле дә күбесенең сахибләре исән булып, әдәбият тарихы өчен якүннәре[8] җыелмаган. Бинаән галәйһи, анларга истинад кавагыйде вә тарихе тәртиб итәргә вакыт өлгермәгәндер. Дөрест, элекдән әдәбиятымыз тәртиб ителеп киленгән булса, яхшы тәнкыйтьчеләремез иләктән сөзсәләр, бонларны гыйлавә кылырга[9] ярар иде. Ул вакытта бу яңа әдәбиятымызның бик мөһим урын тотачагында да шөбһә юктыр.

Өченче – мәдрәсәләремездә тәгълим өчен әсас[10] уларак гарәпчәнең кабул ителүе вә шуның дәвам итүедер. Шуның нәтиҗәсе уларак тәгълим әһле тарафыннан үз телемез һич тә игътибарга алынмаган. Вә аннан бәхәс итәргә лөзүм күрмәгәннәр. Тәгълим эшенә хуҗа булган муллалар безнең йөздә туксаны әле дә төркигә истихфаф[11] илә карыйлар. Төрки әдәбиятыны бер дәрес итеп укытуны, аңа кагыйдәләр тәгъйин итеп[12], шуларны өйрәнеп, өйрәтеп, моның назик мәсьәләләрен чокып ултыруны бушка санаячаклар. Телемезнең

[1] Җәмгъ кылынмаган – җыелмаган.
[2] Истихраҗ кылынып – нәтиҗә ясалып.
[3] Мәүзугларда – проблемаларда.
[4] Кадимгеләр – борынгылар.
[5] Әксәрисе – күпчелеге.
[6] Нәкълият – күчерү.
[7] Биттәкълидәттән – ияручелектән.
[8] Якүннәре – барысы.
[9] Гыйлавә кылырга – өстәргә.
[10] Әсас – нигез.
[11] Истихфаф – көлеп.
[12] Тәгъйин итеп – билгеләп.

«фәнне әлсинә[1]» җәһәтеннән әһәмиятен, үз әдәбиятымызны да рөшдия вә галия[2] шәкертләренә укытырга тиешлекне мәдрәсәләремезнең башында торучыларга аңлатырга берәү дә өстенә алмас дип уйлыйм.

Дүртенче – күреп иярергә «алдымызда» мисал юклыгыдыр. Хәзердә тәгълим-тәдрис эшендә булган кешеләремез үз мәдрәсәләремездән тыш Бохар күргән, Хиҗаз күргән, Мисыр күргән вә Истанбул күргәннәр. Мәзкүр урыннарда исә әдәбият тарихымызны язарлык хәзерлек алырга мөмкин түгел. Гарәб лисаны вә гарәб әдәбияты бөтен әсаслары илә безнең телемезгә башка булдыкыннан, һәм дә тәдвине[3] бик иске заманга мәнсүб улдыгыннан[4], без үз телемезне ул өслүбкә куя алмыймыз. Маташсак та бушка гына булыр. Чөнки ул тугры килми. Яңарак ысул үзрә әдәбият тарихы китаплары Мисыр вә Бәйрутта соң заманнарда гына чыксалар да, әле дә безгә тәэсир иҗраэ итәргә[5] өлгермиләр. Истанбул мәктәпләрендә кавагыйдтән[6] сарыфы төрки[7] кадәрлесене укыталар. Бу кадәрлесе бар ноксаннары[8] илә бергә безнең матбугатымызга да күчкән вә бәгъзе мәктәпләремездә шуны тәгълим дә итәләр. Ләкин бонлар әле бик күп тәрәккыйне каплыйдыр. Әдәбият тарихына киленсә, Төркиядә бу хосуста яхшы дәрес китаплары булмаса да, дәрес китаплары язарга материал күп. Ләкин төрекләрдә сәяси әхвәлнең иҗбары[9] сәбәпле, иң соң вакытка кадәр әдәбияте төркияне[10] юлга сала алмыйдыр. Вә моңа әһәмият бирүләре дә аз иде. Сарыклылар[11] гарәпчә, фарсычаны алда тотып, фәслеләр[12] французчаны алда тотып, һәр икесе төрекчәне онытырга маташып килделәр. Бәгъзе шәхесләр алай ук булмасалар да, үз телләрен әҗнәби[13] телләр дәрәҗәсендә монтазам[14] күрергә теләүчеләр аз иде. Бәлки моннан соң төрекчәгә әһәмият биреп, яңа мәкъбүл[15] ысул үзрә әдәбият кавагыйде[16] вә тарихы язарлар. Без моны көтеп тормасак та, мәйданга чыккач, бәлки истифадә итәрмез[17].

Дөрест, хәзердә дә «госманлы әдәбияты мәҗмугалары» исемендә Истанбулда мәтбуг бик күп әсәрләр бар. Күп шагыйрьләрнең әсәр-

[1] Фәнне әлсинә – лингвистика, тел белеме.

[2] Рөшдия вә галия – урта һәм югары мәктәп.

[3] Тәдвине – җыелмасы.

[4] Иске заманга мәнсүб улдыгыннан – иске заманга караганнан.

[5] Иҗарэ итәргә – ясарга.

[6] Кавагыйдтән – тел кагыйдәләреннән, грамматикадан.

[7] Сарыфы төрки – төрки морфология.

[8] Ноксанннары – кимчелекләре.

[9] Иҗбары – мәҗбүр итүе.

[10] Әдәбияты төркияне – монда: төрек әдәбиятын.

[11] Сарыклылар – «чалмалылар», Госманлы руханилары һәм аларның тарафдарлары.

[12] Фәслеләр – Госманлы зыялылары.

[13] Әҗнәби – чит.

[14] Монтазам – тәртипле.

[15] Мәкъбүл – кабул ителгән.

[16] Әдәбият кавагыйде – әдәбият теориясе.

[17] Истифадә итәрмез – файдаланырмыз.

ләрен җәмгъ кылып[1], табәкате шөгара кабиленнән[2] тарихе вафатлары хисабынча тәртип иделмешләр. Бонлар да – фән җәһәтеннән булган күпноксаннары вә әдәбият тарихыннан көтелгән максудка ирештермәүләре илә бәрабәр бу юлда бер адәмдер. Ләкин безнең мәдрәсәләремез вә тәгълим галәме бонлардан истифадә итәр дәрәҗәгә ирешмәмештер. Бу әсәрләрдә үзләреннән мисал алынырлык дәрәҗәдә рухлы вә файдалы, хәтта өслүбле вә йитешлекле тәртип ителмәмешләр. Госманлы әдәбияты тарихында бер дәрәҗә фәнгә муафыйграк тәртип ителгән әсәр – Петербург дарелфөнүнендә төрек мөгаллиме вә күп еллардан бирле мөселман китапларының цензоры булган Василий Дмитриевич Смирновның[3] «Мөнтәхәбат асаре госмания»седер.[4] Ләкин нәмунәләренең интихабында[5] господин Смирновның төрекләргә каршы булган сәяси нәзары һәм дә бу нәзарны үзенең шәкертләренә дә күчерәсе килү фикере бик роль уйнаган. Бу арзу китапны сыйрыф фәннилектән чыгарып[6], төрекләрнең әхвале рухиясен түбән вә караңгы күрсәтү өчен ясалган бер панорама сурәтенә төшергән. Вә мәга залик[7] бу әсәрнең сахибенә[8] телемез өчен тәшәккер итмәгә бурычлымыз. Чөнки үземез әдәбият тарихынча, ул дәрәҗәдә бер китап вөҗүдкә китерүдән дә еракмыз.

Бишенче – телемез вә әдәбиятымызның кавагыйден, әдәбиятымызның тарихын язарга икътидарлы[9] кешеләребезнең юклыгыдыр. Ибтидаи мәктәпләремезгә китаплар кирәкне сизгәч, бер «Карабаш»тан[10] 41 тәҗвид чыгардык. Грек Каспарның нәшер иттеге «Мохтәсар тарихы ислам» (Җәваднең) дан[11] 31 гадәд тарихы ислам, бер «Әмали»дән[12] – 50 гакаид рисаләсе, бер «Соглук» тәрҗемәсеннән[13] 100 ләп «Гыйльме халь» китаплары оештырырга «мосаннифлар»[14]ымыз та-

---

[1] Җәмгъ кылып – җыеп.

[2] Табәкате шөгара кабиленнән – шагыйрьләр төркеменнән.

[3] Василий Дмитриевич Смирнов (1846-1922) – шәркыятьче-тюрколог.

[4] Петербургда Бораганский матбагасында басылган. Бәһасе 4 сум *(Автор иск.)*

[5] Нәмунәләрнең интихабында – сайлап алынган үрнәкләр.

[6] Сыйрыф фәннилектән чыгарып – тулысынча фәннилектән чыгарып.

[7] Вә мәга залик – шуның белән бергә.

[8] Сахибенә – иясенә, хуҗасына.

[9] Икътидарлы – сәләтле.

[10] «Карабаш»тан – биредә Габдрахман Карабашиның «Карабаш тәҗвиде» исемле мәгълүм әсәре күздә тотыла.

[11] Биредә сүз Гали Җәвадның 1893 елда Истанбулда Каспар матбагасында басылган «Мохтәсар тарихы ислам» китабы турында бара булса кирәк.

[12] Биредә Гали бине Госман әл-Ушиның «әл-Әмали» дигән гакаид китабына Мөтәрҗим Гасыйм әфәнденең шул ук «әл-Әмали» китабына «Мәрахел – мәали фи шәрхел – «Әмали» исемле шәрхе (Истанбулда һиҗри 1266 һәм 1304 елларда басылып чыккан) яки Мөхәммәд Шөкри бине Әхмәд Гатаның «Кәшфел – мәали, шәрхе «Бәдьәл – Әмали» исемле шәрхе (Истанбулда һиҗри 1291 һәм 1328 елларда басылып чыккан) күздә тотыла булса кирәк.

[13] Биредә Зиләле Мөхәммәд әфәнденең ««Һәдиятес – согълүк фи шәрхе «Төхфәтел – мөлүк»« исемле китабының тәрҗемәсе күздә тотыла булса кирәк (Казанда 1873, 1895, 1902 елларда басылган).

[14] Мосаннифлар – китап төзүчеләр.

былды. Җәгърафия, хисап, кыйраәте төркиядә[1] дә кул астындагы китапларны татарчага әверелдерү бик авыр булмаган иде, ягъни бу мәзкүр китапчәләр һәммәсе җиңел кулдан әвәләнеп, гөнаһ уртагыннан эшләнеп, матур язулы, шома вә төрле төстәге кәгазьләр илә тышланып, базарга чыгарылган иде. Әмма үз телемез, үз әдәбиятымыз тугрысына килгәч, болар тугрысында мәкъбүл дәрес китаплары тәртип итәргә «мөәллиф»[2]ләремез җитешмидер. Хәзергәчә безнең телемез вә әдәбиятымыз тугрысында язылган әсәрләр булса, фән нәзарынча игътибарга алырлыклары һәммәсе руслар вә әҗнәбиләр тарафыннан тәртип ителгәннәрдер. Рус вә Гареб университетларының профессорларыннан телемез вә әдәбиятымызны тәдкыйк[3] илә шөгыльләнүчеләр аңа бөтен гомерләрен сарыф итеп, 15әр җилдкәчә китаплар язучылар бар. Бер Василий Васильевич Радловның[4] безнең тел тугрысында язган әсәрләре 30 җилддән артыктыр. Телемезнең вә әдәбиятымызның кагыйдәләре тугрысында руслар тарафыннан язылган әсәрләрне вә лөгать китапларыны үземез яза алу ихтималы кайда, әлегәчә башкалар тарафыннан язылган әсәрләрдән дә тиешлечә истифадә итә[5] алганымыз юктыр. Хәтта ки шундый китапларның җәмгысен бер татар көтебханәсендә табарга да мөмкин түгел.

Бер телнең вә бер әдәбиятның кагыйдәләренә төшенү вә боларны җәмгъ итү өчен гыйльме әлсинәдән (филология) әсаслы мәгълүмат сахибе булырга вә эшләнгән бер тел өстендә тел вә әдәбият кагыйдәләрен бик яхшы өйрәнергә вә милек хасил итәргә, хосусый истигъдад[6] вә кабилият һәм дә ихлас булып, унар-егермешәр ел шуның илә иштигаль итәргә[7], белеп вә сөеп шуның өстендә эшләргә кирәкдер. Без татарлар исә мондый кешеләремезнең күплеге илә мактана алмыймыз. Бәс, телемезне, әдәбиятымызны тәртипкә салыр өчен читтән кеше чакырырга каладыр. Руслар бервакыт үзләренә патшалык итәргә читтән кеше чакырганнар, хәзер дә Төркия вә Иранның һәрбер даирәләре өчен әҗнәбиләр чакырдыкларын күреп торамыз. Тәһранның, Истанбулның низами мәдрәсәләре әҗнәбиләр тарафыннан тәртипкә салындыгы мәгълүм. Мәктәп солтанының мөдире күп елларгача француз булып, тәгълим лисаны да французча булып килде. Һәрбер бай сәүдәгәр үз эшләрене тәртипкә салырга теләде исә, үз доверенныйларыннан үтеп, читтән бухгалтер чакырырга мәҗбүр буладыр. Без дә читтән ватандашларымыздан гыйльме әлсинә галимнәре чакырып, үз телемезне, әдәбиятымызны тәртипкә салып бирергә үтенсәк, кызык кына, бик шәп тә булыр иде. Чувашларның телләрен

[1] Кыйраәте төркиядә – төркичә уку.

[2] Мөәллиф – китап төзүче.

[3] Тәдкыйк – җентекләп тикшерү.

[4] Василий Васильевич Радлов (1837–1918) – күренекле шәркыятьче, тюрколог, этнограф һәм археолог.

[5] Истифадә итә – файдалана.

[6] Истигъдад – сәләтлелек.

[7] Иштигаль итәргә – шөгыльләнергә.

тәдкыйк итүче[1] профессорлар ул телнең кагыйдәләрен чувашларның үзләреннән артык белеп тәртипкә салалар бит. Ләкин болай кешедән тәртипкә салдыру да безнең хәлдән килми, чөнки:

Алтынчы – акча юк. Тел гыйлеме кеби эшләр милләт өчен бик кирәкле вә файдалы булуы илә бәрабәр, башта ияләренә мәгаш[2] тәэмин итми. Үз мәсарыфын[3] тиз кайтармый. Бинаәнгаләйһи, аңа башкача гомуми хаҗәтләр кеби, милләт акчасын тотарга кирәк була. Мәсәлән, терек[4] милләтләрдә бу эшне җәмгыяте гыйльмияләр, университетлар, академиклар башкаралар. Вә хосуси иганәләрдән меңнәр, йөз меңнәр, бәлки миллионнар сарыф итәләр. Киләчәк файда өчен хәзерге мәсарыфтан тартынмыйлар. Безнең исә мондый юлга тотылырга акчамыз юк. Әхмәд бай мәрхүм, китаплар нәшер итәргә дип, һәр елны 500 сум бирергә васыять итеп калдырган иде. Вафатына ничә ел үтте, бу акчадан бер тиен бирелгән юк. Бирелсә дә, кирәгемезнең күплегенә караганда, бу кадәр генә һичтер.

Югарыда мәзкүр сәбәпләргә бинаән, безнең телемез вә әдәбиятымыз дәрес программына кертелә алмыйдыр. «Җарма белән тоз булса, ботка пешерер идек тә, май юк».

Дөрес, әдәбиятның милләт өчен булган әһәмиятен аңлаган, ул гына түгел, әдәбиятның тәмене сизгән, аның абы хәятеннән[5] татыган каһарманнарымыз булса, «фәна фил-әдәбият»[6] булган заһидләремез чыкса, һәммә манигълар[7] кырылыр, әдәбиятымыз җанланыр, башка милләтләр ирешкән югарылыкка без дә ирешер идек. Ул вакытта телемезнең кагыйдәчә җиңеллеге, милләтемезнең олуглыгы ифрат арасындагы уйгану вә эзләнү, мөстәкъбәлемезнең[8] яктылыгы әдәбият хадимләремезнең рәваҗларын[9] вә мәңгелек фәхерләрен[10] тәэмин итәр, без дә, башкалар кеби, үз әдәбиятымыз вә әдипләремез илә мактанырлык хәлгә килермез.

*Сәгъди.*
*(«Шура», 1910, № 18)*

[1] Тәдкыйк итүче – тикшерүче.
[2] Мәгаш – керем.
[3] Мәсарыфын – чыгымын.
[4] Терек – тере.
[5] Абы хәяте – үлемсезлек суы.
[6] «Фәна фил-әдәбият» – әдәбиятта эрү. Суфиларның «Фәна филлаһ» (ягъни Аллада эрер дәрәҗәдә аның белән берләшү) концепцияләренә киная.
[7] Манигълар – киртәләр.
[8] Мөстәкъбәлемезнең – киләчәгебезнең.
[9] Рәваҗларын – таралу (сатуда).
[10] Фәхерлекләрен – даннарын.

**Мәктәп тирәсендә**

*(Ибтидаи мәктәп программасында иң әһәмиятле бер мәсьәлә)*

Һәрбер яңа эш, һәрбер яңа нәрсә бер халык арасына башлап килеп кергән чагында үзенә каршы ут ачылганын күрә киләдер. Бу – әлбәттә, табигый бер хәл. Шунлыктан яңа эш вә яңа ысуллар, билгеле ул мәртәбәдә үк үзләренең уйлаган эшләрен кирәгенчә башкара алмыйлар һәм аны теләмиләр дә, анларның бик табигый буларак теләгән нәрсәләре иң элек бер җиргә кереп яки бер урынга уйлап алу була. Шуның өчен алар үзләренә каршы сугыш ачкан, ут яудырган дошманнары илә артык кан түгешмичә вә үзләре тарафыннан дошманнарына күп ригая кылып, дошманнарына юл куеп (күп уступкалар[1] илә) тизрәк солых[2] ясауны кирәксенәләр. Һич булмаганда, дошманнары арасына вакытлы гына урнашып тору, дошманнарыннан үзләренә тик аз бер мөддәт[3] белән иҗарә тарикынча гына[4] урын алуга күнү кеби шартлар белән булса да, солых ясауга мәҗбүр булалар. Башта шуның өчен үзләренең күп нәрсәләрен фида итәләр.

Солых ясала. Үзләре илә дошманнары арасында дошманлык, кан кызулык беркадәр басыла. Бунларда дошманнарының үзләре яраткан ашлар белән анларны сыйлап күңелләрен таба башлыйлар. Бераз гына хәтле һаман үзләренең чын әсәрләрен, эшләрен күрсәтүгә бик ашыкмыйлар. Артык шау-шу чыгарасылары килми. Нинди генә бер хәйлә белән булса да, һаман дошманнарына яхшы күренергә, аларны үзләренә тәмам дуст кылып алырга, хасил алар яраткан буяуга буялып йөрергә тырышалар.

Менә бу – һәрбер яңа нәрсәнең, яңа вакыйга вә хадисәләрнең, үзләренең катгый вә ачык нәтиҗәләренә ирешү өчен тоткан табигый юлларыдыр.

* * *

Шул ук сәясәт белән иде ки, яңа ысул (ысулы җәдидә) илә укытуның арамызга килеп кергән чагында, яңарак башланган дәверләрендә аның чын файдасын ачык күрүгә тырышудан бигрәк, үзенә каршы сугыш ачкан халкымызның аңа карашын яхшыртуга иҗтиһад итеплә, аның белән халкымыз арасында ничек кенә булса да солых ясалу артык күрелә иде. Шуның өчен хәтта бу ысулга бөтен төбе-тамыры белән каршы вә дошман булган иске, черек ысулларны да үз-үзләрендә калдырырга тугры килә, анларны мәктәпләремездән бөтенләй чыгарып ташлауга сәясәт имкян[5] бирми иде. Хәтта яңа ысул башта күп мәктәпләремезгә тик иске, черек ысулның койрыгына тагылып йөртелү шарты яки сәясәте белән генә килеп керә алды, шул тарика

[1] *Кирилл хәрефләре белән язылган.*

[2] Солых – килешү.

[3] Мөддәт – вакыт, срок.

[4] Иҗарә тарикынча гына – вакытлыча файдалану юлы белән генә.

[5] Имкян – мөмкинлек.

гына[1] мәктәпләремездән вә хакымыз арасында үзләренә урын бирелү насыйп булды.

Буның бер мисалы шул иде: ике-өч ай милли телемезне укып, әзрәк хәрефләрне аера вә ялгыз сүзне, кыска җөмләләрне өзеп, ертып укый башлар-башламас гарәпчә уку, Коръән башлату һәм беренче ибтидаидан ук Коръән танытып чыгару беренче сыйныф программасына фарыз ителеп кертелә килде. Беренче сыйныф балаларына вә мөгаллимнәренә шуны җиренә җиткерү фарзы гайн кылынды[2]. Аңа ибтидаи беренчедән үк киң урын, киң хокук бирелде. Ә шуның бәрабәренә баланың үзенең туган теле, милли кыйраәте, милли теленең имлясы, иншасы кеби яңа укуның, яңа ысулның җаны вә бисмилләсы булган асыл маддәләр фида ителде. Милли телнең карашын таныр-танымас, үз телен ватып-кырып укый башлар-башламас бөтен әһәмият Коръән тануга бирелде. Үз телендә юньләп белмәгән, үзенең туган телендәге җиңел генә сүзләрне дә рәтләп дөрес әйтә алырлык дәрәҗәдә теле ачылмаган балаларның үзләренә олуг кешеләргә дә иң авыр гарәп теле итеп тыгылды. Шәддә вә ляме тәгъриф[3] кебиләрнең авыр вә чуалчык хөкемнәре астына алынып, бичара балаларның телләре, җаннары кыйналды. Шуның өчен шул авыр гарәп телен, гарәп әлифбасын, кыйраәттә әүвәлге елда ук танытып чыгару өчен өч-дүрт еллар буе балаларны беренче сыйныфта калдырып, аларның газиз гомерләре вәйран ителде[4], миләре имгәтелде, әгъсаблары[5] какшатылды, сеңерләре зәгыйфьләнде. Ниһаять шуның сәбәпле балаларның күбесе миңрәүләнә, аңсызлана башладылар.

Буның өстенә беренче сыйныфтан ук никадәр сүрә, нихәтле әһәмиятсез догалар ятлату кеби егетлекләремезне дә кушсак, беренче сыйныф балаларының ватылулары, имгәнүләре ни дәрәҗәгә җиткәнлек үз-үзеннән аңлашылыр.

Хәтта күп мөгаллимнәр бар иде ки, ишектән чыкканда, кергәндә, тәһарәтханәгә барганда, кайтканда фәкать ишанлык юлына аяк баскан бәндәкәйләрнең генә укый торган яңлыш-йоңлыш догалыкларны да ятлатып, балаларны кызганмыйча изәләр иде, һәм дә ысулы җәдидә исеме илә изәләр иде.

Менә бу хәлләр һәммәсе дә эшләнде. Болар һәммәсе дә мәктәпләремездә ысулы җәдидә исеме астында һаман падишаһлык сөреп килделәр. Хәзерендә дә күп мәктәпләремездә бу хәлләр үзләренең солтанлыгын итәләр, милли кыйраәтемезне һаман үзләренең каһәр көчләре астына алып яңаклыйлар ... аңа һаман ишек төбеннән югары урын бирмиләр, аны һаман ишек бусагасында тилмертеп, ятимсерәтеп тоталар.

---

[1] Шул тарика гына – шул юл белән генә.

[2] Фарзы гайн кылынды – тәмам үтәлергә тиеш табылды.

[3] Шәддә вә ляме тәгъриф – биредә сүз гарәп сарыфында кыен һәм буталчык саналган кагыйдәләр турында бара.

[4] Вәйран ителде – ватылды.

[5] Әгъсаблары – нервлары.

Буңанчы шөбһәсез шулай булып килде. Күп мәктәпләремездә әле дә шулай булып барганы мәйданда. Буңанчы шулай булмыйча, шундый бер юл белән бармыйча чарамыз юк иде. «Исагуҗи»[1], «Шәмсия»[2] вә «Җамигыр-рөмуз»[3] ысулларыннан башканы белми торган һәм тормышларын, көн кичерүләрен тәэмин итү өчен яңылашып (җәдидләшеп) яңа ысул белән укыту дәгъвасына калкышкан хәлфә әфәнделәремез бу юлны иң яхшы, иң җиңел һәм үзе белән бару хакыйкатән дә[4] фарыз булган изге, иляһи бер юл дип танып, аны шуның өчен ихтыяр итүләрендә, әлбәттә, мәгъзүрләрдер[5].

Мәгәр аңлырак мөгаллимнәремез исә, аның ярамаганлыгын, файдасызлыгын белсәләр дә, бу юл белән балаларның изелүен күреп күзләреннән яшьләрен сөртә-сөртә укытсалар да, янә шул авыр юл белән баруга мәҗбүр иделәр. Яңы ысулның иң зиннәтле вә әһәмиятле нокталарын чарасыз фида итеп, аның урынына белә, күрә, гомумга ярый торган ялган буяуга буялып йөрү, вакытына күрә бунлар өчен лязем бер хәл иде. Чөнки балалар беренче сыйныфта Коръән танырлык булмасалар яки беренче сыйныфтан ук гарәпчә тел һәм Коръән кертелмәсә, халкымызның гавам кыйсеме дә, руханилары да мөгаллимнәрнең кабыргаларын санап бирәчәк, яхуд мәктәпләрнең бүрәнәләре, ташлары урыннарыннан тузылачак иде. Яңа ысулның кара такталары, парталары, арба-чаналары... көл булып күккә очачак иде. Кыскасы, башта шундый авыр, ачы бер сәясәт йөртелмәгәндә, яңа ысул үзенең рәваҗын[6] тиз генә таба алачак түгел иде.

Инде, меңнәрчә шөкерләр булсын, һавалар алмашынды. Карт мөтәвәллиләремезнең[7] күбесе үз юлларына үз урыннарына юнәлделәр. Мәңгелек йортларына кайтып киттеләр ... Дөньяда калган кирәк гавамымызның, кирәк руханиларымызның булсын яңа ысулга карашлары башкарды, беркадәр яхшыланды. Яшь буыннарымызның да башларына рәхмәт яңгырлары сибелә башлады. Белем, аң нурлары баш түбәмездә әйләнеп, очып йөри башлады. Инде яңа ысулның арамызга килеп керүенә 25–30 еллар үтте. Шул ысулны халкымызга кабул иттерү юлында байтак кына корбаннарымыз да чалынып булды. Ниһаять аның баш каһарманы вә беренче муҗиде[8] булган изге җанымыз да арамыздан югалды. Аның да Раббысына кайтыр чаклары йитеп, Тәңресенә чакырылды. Шул юлда әллә нихәтле авыр сәясәтләр

---

[1] «Исгауҗи» – «Китабел Исагуҗи» – имам Әсиреддин әл-Әбһариның гыйльме мантыйк буенча гарәп телендә язылган хезмәте.

[2] «Шәмсия» – биредә Нәҗмеддин Гомәр бине Гали әл-Казвининың «Китабе шәмсия. Мәтен мохтәсар фи кавагыйде мантыйк» исемле китабына ишарә булса кирәк.

[3] «Җамигыр-рөмуз» – Шәмсетдин Мөхәммәд бине Хисамеддин әл-Хорасани әл-Куһистани (1555 елда вафат) язган фикъһ китабы.

[4] Хакыйкатән дә – чынлап та.

[5] Мәгъзүрләрдер – гозерлеләрдер.

[6] Рәваҗын – таралуын.

[7] Мөтәвәллиләремезнең – мәчет, мәдрәсә эшләрен башкаручыларымызның.

[8] Муҗиде – барлыкка китерүчесе.

илә шөгыльләнә-шөгыльләнә билахир[1] безнең өчен, милләте өчен үзен корбан итте. Хәзерендә, Аллаһка шөкер, шулкадәр авыр сәясәтләрнең, мәшәкатьләрнең, фидаилекләрнең, корбаннарның нәтиҗәсендә халкымыз яңа ысулга корылган мәктәпләрне үзләре теләп һәр яктан тавыш бирә башладылар. Яңа ысулның җиңел һәм тиешле бер ысул икәнен инде һәркаюсы диярлек кояш кеби ачык аңладылар.

Бунын өчен шул да ачык дәлил түгелме ки, яңа ысулны арамызга башлап кертүче, аның арамызда муҗиде һәм ибтидаи тәгълим вә ибтидаи мәктәпләремезнең беренче атасы олуг остазымыз мәрхүм Исмәгыйль Гаспринский хәзрәтләренең вафат булу кайгысы яңа ысулга иң каршы кешеләремезнең дә йөрәкләренә барып керә алды. Аларда бу олуг затның бу фидаи вә хөрмәтле җанның арамыздан күтәрелеп, Тәңресенә кайткач булса да, аның хезмәтенең бәһасен аңладылар, кайгырдылар, аңа изге догалар кылдылар.

Кыскасы, халкымызга инде яңа ысулның җимешен чын мәгънәсе белән пешкән хәлдә тәкъдим итү сәгатьләре җитте. Яңа ысулның үзенең әсәрләрен, файдаларын нәтиҗәләрен һич нәрсәдән курыкмыйча ачыктан-ачык вә бөтен көенчә мәйданга куяр заман күптән булды. Олуг муҗидемез үзенең шәкертләренә, мөридләренә йөкләтеп әманәт итеп киткән шикелле вә каберендә анардан шуның тәмам җиренә җиткерелүен көтеп ятачак булдыгы кеби бөтен халкымыз да инде аның чын мәгънәсе белән гамәлгә куеп җитүенә каршы килмәячәктер.

Шул хәлдә тәгълим һәйәтләремезгә ибтидаи беренче сыйныфларга гарәп телен, гарәп әлифбасын кертеп, Коръән башлатып, балаларымызны имгәтүдән билиттифак[2] туктарга инде күптән вакыт. Инде беренче сыйныф фәкать милли тел, фәкать милли язу гына өйрәтелә торган сыйныф булып калырга тиеш. Бу сыйныфны ничек кенә булса да милли телемезне, милли кыйраәтемезне әһәмият белән вә җитдирәк укытырга багышлау – муенымызга инде зур бурыч. Бу сүзләремездән динемезнең әсасы булган гарәп теленә хөрмәт итмәвемез аңлашылмасын. Бу сүзләремезнең ул ноктаи назардан[3] карагандa гарәп телен вә мөкатдәс Коръәнемезне гаять дәрәҗәдә хөрмәт вә тәгъзыйм итүемездән[4] сөйләнгәнлеге аз бер мөляхәзә[5] белән дә ачык аңлашылачактыр. Чөнки Тәңресен вә пәйгамбәрен яхшылап танып җитмәгән. Коръән ни, тәгъзыймнең ни икәнен дә әле аңлый алмаган бер баланың кулына аять, Коръән вә яки Һәфтияк килтереп тоттыру һәм дә килмәгән авызлары белән шунларны ваттырып тәхфиф кылдыру[6] үзе зур гөнаһ вә Коръәнгә хөрмәтсезлек булып саналачактыр.

[1] Билахир – ахырда.
[2] Билиттифак – берләшеп.
[3] Ноктаи назардан – караштан.
[4] Тәгъзыйм итүемездән – олылавыбыздан.
[5] Мөляхәзә – дикъкать белән карау.
[6] Тәхфиф кылдыру – кимсетү.

Әмма икенче сыйныфка күчкәч, балаларга беркадәр аң, ис кергән була. Анда инде Корънне тәхфиф итмәүләре[1] мөмкин.

Әгәр гарәп телен дә беренче сыйныфтан ук башлатсак, билгеле, балаларымыз йә үз телемезне, үз кыйраәтемезне яки гарәпчәне яхшылап таный алмыйча ике уртада тик каңгырап калачаклар. Берсен дә юньләп башкарып чыгара алмыйча азапланып бетәчәкләр. Тик ике эскәнҗә[2] арасында изелеп калачаклар.

Әмма ялгыз үз телемез генә укытылса, ул чагында әмин[3] булыйк ки, балаларымыз милли телемезне үз кыйраәтемезне беренче сыйныфтан ук бик яхшы өйрәнеп, мәләкәләнеп[4] чыгачаклар. Кирәк язуга, кирәк укуга булсын, бер дә артык ватылмыйча гына яхшы ук күнегә алачаклар. Буның өстенә, бу юл белән барганда, беренче сыйныфта икенче елга торып калучылар да булмаячак, булса да аз булачак. Менә бу җәһәтләре исә безнең өчен бигрәк әһәмиятле. Бу – бигрәк яңа ысулның асыл теләге. Чөнки баланы сыйныфында калдыру кеби баланың рухын изә торган бер эш юктыр.

Баланың фәкать Корън танымаганлыгы өчен беренче сыйныфта өч-дүрт ел утыртып калуларын искә алсак, йөземезне кызарта торган шул зур гөнаһымыздан, шул олуг мәсьүлиятемездән [5] ничек котылу чараларын таба алмавымызны уйлап ихтыярсызыгларга мәҗбүр булачакмыз.

Ысулы тәгълим вә фәне тәрбия буенча һичбер төрле сәбәп белән дә күчерү дә мөмкин булмаган чакта гына баланы сыйныфта утыртып калдыруга имкян[6] бар. Ул да шул шарт белән ки бер бала бер сыйныфта ике елдан артык катгыян[7] калдырылмаска тиеш. Электә тагылдыгына барырлык булса да, мотлакан[8] икенче сыйныфка күчерергә кирәк.

Без беренче сыйныфта өч-дүрт ел балаларның гомерләрен әрәм итә торган вә тәрбияле генә дигән мәктәпләремезнең хәлен белгәнлектән, бу сүзләремезне ачынып сөйләүгә мәҗбүрмез.

Беренче сыйныфта гарәпчәдән булса, тик хәрәкәләр генә күрсәтелергә, белдерелергә тиеш. Аннан башкаларына катгыян вә катгыян беренче сыйныфта урын бирүгә хакымыз юктыр. Беренче сыйныфлар өчен тәртип ителгән кыйраәт китапларымызда шул юлга муафыйк[9] тәртип ителергә тиешлеләр.

Гарәп әлифбасының, гарәп теленең беренче сыйныфы итеп ибтиади икенче сыйныфны билгеләсәк, никадәр дә гүзәл иткән вә ти-

---

[1] Тәхфиф итмәүләре – җиңелгә санамаулары.

[2] Эскәнҗә – келәшчә.

[3] Әмин – тыныч.

[4] Мәләкәләнеп – остарып.

[5] Мәсьүлиятемездән – җаваплылыгыбыздан.

[6] Имкян – мөмкинлек.

[7] Катгыян – һич.

[8] Мотлакан – һичшиксез.

[9] Муафыйк – туры китереп.

ешле юлы илә барган булачакмыз. Бу сыйныфта ул ике-өч ай гарәп әлифбасы укылып, шуннан соң гына Коръән башлату – яңа ысулның җиңеллекләреннән берседер. Икенче сыйныфта Коръәнне әкренләп кенә укый алырлык булып чыксалар, бу иң зур муаффәкыятемез[1] булачактыр. Буңа бик канәгатьләнергә тиешлемез.

Инде мәктәпләремезнең вә тәгълим һәйәтләремезнең[2] ибтидаи мәктәп программаларында шу мәсьәләгә чыннан әһәмият бирүләрен үтенер идек. Кирәк гыйльме тәрбия вә кирәк гыйльме рух вә фәне вазаифы әл-әгъза ноктаи назарыннан бу юлның ашыгычлык белән алга сөрелүе – бу көндә олуг бурычымыздыр. Без хәзерге мөгаллим вә мөгаллимә юлдашларымызга шул мәсьәләне тәкъдим вә ихтар илә[3] сүземезне кисәмез. Лөзүм күрелсә[4], аның тиешлеген күп фәнни дәлилләр белән исбат итүгә хәзермез.

*Сәгъди.*
*(«Шура», 1917, № 14, 15)*

**Әдәбият**

Габдрахман Сәгъди: фәнни-биографик җыентык / төз: Д. Заһидуллина, Ч. Гыйләҗева. Казан: Җыен, 2008. 416 б.

Әдипләребез: Биобиблиографик белешмәлек. Казан: Татар. кит. нәшр., 2009, 735 б.

*Басмага әзерләде:*
***Гарипова Ләйлә Шамил кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма мирас үзәге әйдәп баручы фәнни хезмәткәре*

[1] Муаффәкыятемез – уңышыбыз.
[2] Һәйәтләремезнең – комиссияләребезнең.
[3] Ихтар илә – искәртү белән.
[4] Лөзүм күрелсә – тиеш күрелсә.

УДК 82.09

***Г. Кәрам***

## «ТИГЕЗСЕЗЛӘР»

9 февраля 1915 г. в Казани на сцене «Нового клуба» труппой «Сайяр» была поставлена еще неопубликованная пьеса Ф. Амирхана (1886–1926) «Неравные». Спектакль был тепло принят зрителями. Произведение получило множество отзывов литературных и театральных критиков. В настоящей статье представлен отзыв известного журналиста, литературного и театрального критика Г. Карама (1878–1947). Автор рецензии оценивает не только содержание, но и даёт оценку игре актёров и постановке спектакля. Таким образом, данная рецензия представляет интерес как для литературоведов, так и для театроведов.

**Ключевые слова:** татарская литературная критика, Фатих Амирхан, Габдрахман Карам, татарское театральное искусство.

On February 9, 1915, in Kazan, on the stage of the “New Club”, the Sayyar troupe staged an unpublished play by F. Amirkhan (1886–1926) “The Unequals”. The performance was warmly received by the audience. The work has received many reviews literary and theatrical critics. This article presents a review by the famous journalist, literary and theater critic G. Karam (1878–1947). The author of the review evaluates not only the content but also evaluates the performance of the actors and the staging of the play. Thus, this review is of interest to both literary critics and theater critics.

**Keywords:** Tatar literary criticism, Fatih Amirkhan, Gabdrahman Karam, Tatar theatrical art.

*1915 елның 9 февралендә Казан шәһәренең «Новый клуб» сәхнәсендә[1] «Сәйяр» труппасы тарафыннан Ф. Әмирханның (1886–1926) «Тигезсезләр» пьесасы сәхнәгә куела. Әле басмага да китеп өлгермәгән әсәр әдипнең кулъязмасы буенча сәхнәләштерелә. Ул беренче тапкыр 1915 елда «Әхмәтгәрәй Хәсәни вә шөрәкясе» тарафыннан нәшер ителә. Шунысы игътибарга лаек, аерым китап булып чыккан бу басмада спектакль күренешләреннән фоторәсемнәр дә бирелгән.*

*Спектакльдә Г. Болгарская (1891–1968), Н. Таҗдарова (1888–1947), К. Тинчурин (1887–1938), В. Мортазин-Иманский (1885–1938), Г. Мангушев (1887–1919), М. Иманская (1890–1919), Н. Сакаев (1885–1919) кебек артистлар катнаша һәм уен тамашачылар тарафыннан бик җылы кабул ителә. Озак та үтми матбугатта Ш. Әхмәдиев[2] (1888–1930), Ф. Сәйфи-Казанлы (1888–1937), Х. Искәндәров (1888–1958) һ.б. татар укымышлыларының әсәргә һәм спектакльгә*

---

[1] Хәзерге Горький урамындагы К.Тинчирунин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театры урнашкан бинада.

[2] *Әхмәдиев Ш.* «Тигезсезләр» пьесасы / басмага әзерл. Г.М. Ханнанова // Фәнни Татарстан. 2023. № 3. Б. 149–152.

*карата бәяләмәләре күренә башлый. Шулар арасында танылган журналист һәм театр тәнкыйтьчесе, тәрҗемәче Габдрахман Хәбибулла улы Кәрамның (Рәхмәтуллинның, 1878–1947) рецензиясе игътибарга лаек. Г. Кәрам әсәргә югары бәя бирә һәм: «Фатих Әмирханның бу пьесасында аның бердәнбер булган «Яшьләр»е кебек җиңел, матур диалоглары садәлеге илә бәрабәр әдәби өслүбтә (стильдә. – Г.Х.) язылмыштыр ... Пьеса үзенең мәгънәлелеге, теленең матурлыгы, сәхнә җәһәтеннән төзелешенең мөкәммәлияте (камиллеге. – Г.Х.) белән бик зур муаффәкыять (уңыш. – Г.Х.) казанды», дип яза. Фатих әфәнденең театрга караган әсәрләре аз булып, бу өлкәдә аның әллә ни тәҗрибәсе булмаса да, ул гаҗәеп бер сурәттә тамашачыларга уңай кәеф биреп, шул халәтне уенның башыннан ахырына кадәр саклап килә алды, бу бик аз драматургларга гына хас күренеш һәм пьесалар өчен мөһим сыйфат дип билгеләп үтә мәкалә авторы.*

*Артистларның уеннарын Г. Кәрам, театр белгече буларак, тышкы кыяфәтләренә, үз-үзләрен сәхнәдә тоту рәвешенә генә карап түгел, ә әдәби геройның рухын, характерын тамашачыга җиткерә белүдәге профессиональ осталыгына, тәҗрибәсенә дә әһәмият, игътибар биреп бәяли. Шул рәвешле, әлеге рецензия әдәбият галимнәренә генә түгел, ә театр белгечләре өчен дә кызыклы һәм мәгълүматлы.*

*Әлеге язма гарәп графикасыннан гамәлдәге язуга күчерелеп, сүзлек һәм аңлатмалар белән тулыландырылып тәкъдим ителә.*

## «Тигезсезләр»

*(театр вә музыка)*

9 февральдә, дүшәмбе көн, «Новый клуб» сәхнәсендә Сәйяр труппасы тарафыннан фәүкыльгадә[1] бер муаффәкыять илә[2] мөхәррирләремездән Фатих Әмирханның яңа әсәрләреннән «Тигезсезләр» исемле өч пәрдәлек пьесасы уйналды.

Бу яңа уенны күрергә шәһәремезнең бөтен кибаре ислам[3] гаиләсе, зыялылары, яшьләре вә укучылары килгән иде. Бәхеткә каршы, бу күпләп килгән халыкның хисабы бушка чыкмады.

Һәркем уеннан мәмнүн булып[4], уенның биргән гүзәл тәэсире аркасында, күтәренке рух белән күңелләрдә әллә нинди өмидләр тудырып, театрдан таралдылар. Филвакыйг[5] сәхнәмездә сәләмә киемнәрдән, ямьсез җиһазлардан, аның өстенә бәлки меңәр мәртәбә тәкрар ителгән[6] тозсыз, мантыйксыз фәлсәфәләрдән гыйбарәт булган

[1] Фәүкыльгадә – гадәттән тыш.
[2] Муаффәкыять илә – уңыш белән.
[3] Кибаре ислам – бөек ислам.
[4] Мәмнүн булып – разый булып.
[5] Филвакыйг – чыннан да.
[6] Тәкрар ителгән – кабатланган.

уеннарны күреп туеп беткән халкымызга бу назик[1] уен үзенең матур мәнзарәләре[2], таза вә нәфис мөхавәрәләре[3] илә гүзәл бер сюрприз» булды. Бөтен кичә буенча бөтен мөхавәрәләр, мөхакәмәләр[4] бу яңа уен тирәсендә тулашты[5] вә бу мөхакәмәләр, уен ахырында, кирәк мөхәррире, кирәк уйнаучылар исеменә иге-чиге булмаган алкышлар илә нәтиҗәләнде.

Фатих Әмирханның бу пьесасы да аның бердәнбер булган «Яшьләр»е кеби йиңел, матур, диалоглары садәлеге илә бәрабәр әдәби өслүбтә[6] язылмыштыр.

Фатих әфәнде театрга даир[7] язган әсәрләренең азлыгына нисбәтән, ул кадәр тәҗрибә сахибе[8] булмаса да, ләкин ул гаҗәеп бер сурәттә тамашачыларга яхшы настроение[9] бирә белә вә тамашачыларның дикъкатен ирексез үзенә ияртеп, уенның башында биргән настроениесен ахырына кадәр саклап алып килә ала. Менә бу – бик аз драматургларга мөяссәр[10] була торган бер фазыйләт[11] вә пьесалар өчен мөһим бер плюстыр.

Килик пьесага. Аның программасында «Вакыйга Казанда, иң соңгы елларда» дип язылса да, ләкин анда «вакыйга» дип әйтерлек бер вакыйга юк. Бу – туп-тугры безнең яңа тормышымызның (итлак җаиз исә[12]) матур кисәкләреннән, оста каләм илә тасвир кылынган матур-матур ләүхәләредер[13].

«Тигезсезләр»нең хөласасы[14] шуннан гыйбарәт:

«Сафа Насыйбуллин – фикерле, мөтәрәккый[15] бер Казан сәүдәгәре. Аның яхшы йөрәкле хатыны, ике углы, ике кызы бар. Зур углы Гомәр – яхшы ук мәгълүматлы бер егет. Ул атасының сәүдәсенә канәгатьләнмичә, үзенә яңа бер эш – оптик[16] ача.

Зур кызы Сәлимә вакытында гимназиядә укымаган булса да, ләкин хосусый сурәттә имтиханга хәзерләнә, музыка дәресләре дә ала. Ул бик эшлекле, тырыш, булган кыз. Ул буш вакытларда агасының магазинына барып та булыша.

---

[1] Назик – нәфис.

[2] Мәнзараләре – күренешләре.

[3] Мөхавәрәләре – әңгәмәләре.

[4] Мөхакәмәләр – хөкем чыгарулар.

[5] Тулашты – әйләнде.

[6] Өслүбтә – стильдә.

[7] Театрга даир – театрга караган.

[8] Сахибе – иясе.

[9] *Бу сүз кириллицада бирелгән.*

[10] Мөяссәр – җиңел үтәлешле.

[11] Фазыйләт – яхшы сыйфатлылык.

[12] Итлак җаиз исә – атап йөртү яраклы булса.

[13] Ләүхәләредер – күренешләредер.

[14] Хөласасы – биредә: кыскача эчтәлеге.

[15] Мөтәрәккый – алга киткән.

[16] Оптик – оптика.

Икенче кызы Рокыя гимназиядә укый. Ул 18 яшендә булса да, ләкин гакыл вә табигатьчә[1] әле балалыктан чыгып бетмәгән, иркәрәк кенә, үзе яратмаган эшләрдән кача торган матур бер кыз.

Аталары үлгәч, Гомәр үзенең тырышлыгы аркасында оптикны да, мануфактур сәүдәсен дә яхшы алып барып, бик тәрәккый иттерә. Бик матур европача көн күрәләр. Рокыя рус тәхсиле күреп[2], гимназияне бетергән бер кыз булса да, ләкин ул татар әдәбиятын бик сөя, хосусән[3] мөхәррир Сөләйманның әсәрләрен бик яратып укый. Әсәрләрен генә түгел, хәтта аның үзен дә сөя вә бу гыйшкын аңар ачыктан бәян итә. Ләкин Сөләйман – фәләкнең[4] шактый тәбдилләрен[5] күргән, чигәләренә чал кергән, 35 яшьләрдән үткән бер кеше. Ул Рокыяны никадәр сөйсә дә, аның каршына дәрхаль[6] яшьләрдәге нисбәт[7] килеп баса. Сөләйман бу тигезсез гыйшыктан киләчәктә һәр икесе өчен күңелсез нәтиҗәләр туачагын сөйли: «Син минем кызым булырлык бит, Рокыя!» – ди. «Юк, Рокыя, син ялгышасың, син сөймисең дә, сөяргә тиеш тә түгел ... чәченә чал кергән кешеләр – сөелер өчен кичеккәнрәк кешеләр инде алар ... Синең яшь, ялкынлы тойгыларың барыбер кайчан да булса үз каршыларында шундый куәтле яшьлекне күрергә теләрләр ...», – ди.

Күрше дачада Габдулла исемле касыймлы бер Мәскәү студенты тора. Габдулла башта Сәлимә артыннан ухаживать иткән күк булса да, Рокыяны күргәч, Сәлимәгә әһәмият бирми башлый, билгакес[8], Рокыяны сөя башлый. Ләкин беренче күрешүдә үк Габдулла аның фикеренә хилаф[9] бер игътикадта[10] булганлыктан, татарның язмышы вә аның әдәбияты хакында булган бер мөназәгадан соң[11], ул Габдулланы дошман күрә башлый. Бу мөназәгадан соң, Габдулла аннан никадәр гафу үтенсә дә, никадәр хәрарәтле[12] гыйшык хатлары язса да – һәммәсе файдасыз. Хәтта ул аны Абдулка – Иванушка дип кенә йөри башлый. Хәлбуки[13] Сәлимә Габдулланы чын күңеленнән сөя вә бу куәтле гыйшкын аңар белгертмәсә дә, ләкин аның Рокыяга гашыйк икәнен күреп, бик мөгаззәб була[14]. Бу кайгысын Гөлчәһрә ханымга гына сөйли. Габдулла, Рокыяның Сөләйманны сөйгәнен күреп, ни кылырга да белми. Сәлимәнең исә бердәнбер идеалы – Габдуллага

[1] Табигатьчә – биредә: табигате белән.
[2] Рус тәхсиле күреп – рус белеме алып.
[3] Хосусән – бигрәк тә.
[4] Фәләкнең – язмышның.
[5] Тәбдилләрен – үзгәрүләрен.
[6] Дәрхаль – шунда ук.
[7] Нисбәт – чагыштыру.
[8] Билгакес – киресенчә.
[9] Хилаф – каршы.
[10] Игътикадта – ышануда.
[11] Мөнәзагадан соң – бәхәстән соң.
[12] Хәрарәтле – хисле.
[13] Хәлбуки – шулай булуга карамастан.
[14] Мөгаззәб була – газаплана.

булган гыйшкы йимерелә. Шуннан соң ул агасының кат-кат исрар вә тәклифләреннән соң[1], үзе сөймәгән, Гайсә исемле агасының сәүдә шәриге[2] бер егеткә хатынлыкка барырга ризалык бирә.

Сөләйман белән Рокыя сөйләшеп, көлешеп, агачлар арасына кереп киткәндә, Габдулла мәэюс[3] бер хәлдә үз бүлмәсенә кайтканда, Сәлимә ике кулы илә йөзен каплап: «Йә Алла, ник болай тигезсез иттең бәндәләреңне!» дип җылап, бакчада утырган эскәмиясенә таянып кала.

Күрәмсез: пьеса шактый гына мәгънәле, уйнаучылар өчен дә зәмин[4] иркен, материал да бар. Шуның өстенә Фатих әфәнденең сайлаган матур вә яңа типларын да гыйлавә[5] итсәк, бу пьеса – хакыйкатән[6], сәхнәмез өчен зур табыштыр. Пьесада дикъкатьне җәлеп итә торган биш тип бар: Сәлимә, Рокыя, Сөләйман, Габдулла, Гомәр.

Сәлимә – җитди, эшлекле, үз ирекле бер кыз. Ул һичбер тугрыда, һичбер кешегә ихтыяҗ хис итми, чыннан бирелгән тәлкыйннәргә[7] колак асмый. Ул, йорт карау өстенә, тырышып русча укый, музыка дәресләре дә ала, хәтта магазинга барып, агасына булышлык итәргә дә өлгерә.

Ләкин бу куәтле ихтыярлы (с сильной волей[8]) кыз ахырында җиңелә: укуын да ташларга мәҗбүр була, иң соңында гыйшкында да мәгълүб була[9]. Бу тип – бик ачык, аңлаешлы, табигый бер тип.

Сәлимәне Болгарская[10] бик дөрест аңлап, һәрвакыттагы кеби тигез, матур итеп уйнады. Бары беренче пәрдәдә генә Рокыяга каршы артык ачулырак, тавышы катырак иде. Монда ачу өстән генә, үпкә белән катышрак булырга тиеш. Әмма Рокыя ... менә бу бер мөгаммә (загадка).

Аны һәммәсе химая кыла[11], ул ирексез, башкаларының сыянәтенә[12] мохтаҗ. Ул бераз ялкау да, бераз җилбәзәк тә, садәдил дә[13], матур да, көнче дә ... ниһаять ул милләтче дә, фанатичка да. Гомәр аның хакында: «Рокыя болай табигате белән дә әллә ничек кенә бит ул», – ди. Атасының сүзләре: «Анасына ошаган, ялкау!» Анасы: «Йә,

---

[1] Исрар вә тәклифләреннән соң – үгетләүләр һәм кыстаулардан соң.

[2] Шәриге – иптәше.

[3] Мәэюс – өметсез.

[4] Зәмин – җирлек.

[5] Гыйлавә – өстәмә.

[6] Хакыйкатән – чыннан да.

[7] Тәлкыйннәргә – аңлатуларга.

[8] *Бу сүзләр кириллицада бирелгән.*

[9] Мәгълүб була – җиңелә.

[10] Болгарская – Гөлсем Болгарская (Өммегөлсем Муса кызы Мостафина, 1891–1968), драма актрисасы, ТАССРның халык (1923), РСФСРның атказанган артисты (1925).

[11] Химая кыла – саклый, канат астына ала.

[12] Сыянәтенә – яклавына.

[13] Садәдил дә – эчкерсез дә.

килешсезләнмә Рокыя, шикелсезләнеп[1] йөргәнче ... вә илх[2]«, – ди. Сәлимә: «Рокыя юристка булса, әй, нишләп ялганлап торыйм соң дип, һәммә нәрсәнең дөрестен генә сөйләп бирер иде дә, алган эшен утырып чыгар иде», – ди. Сөләйман: «Син намазны матур иттереп укый торгансыңдыр, синең күзләрең Аллага сәҗдә итә торганнардыр... синең белән фәрештәләр дә намаз укыша торганнардыр», – ди. Ул Габдулланың татар мәктәпләре, әдәбияты хакындагы начар карашы өчен аның белән кычкырыша, аны дошман күрә, ниһаять ул – «дөньяда үзең бигүк теләмәгән эшне эшләп тук торуга караганда, бигүк тук булмаса да, үзең теләгән эш белән генә шөгыльләнергә кирәк», дип уйлый торган бер кыз...

Күрәсез, мөхәррир әфәнде Рокыя өстенә бик күп фазыйләтләр[3], бик күп мәсьүлиятләр[4] йөкләткән.

Моны аңлап уйнар өчен бик назик рухлы, бер минутта мең төрле халәте рухиягә[5] керә белә торган бер артистка кирәк. Шул хәлләрне рухы белән дә, кыяфәте белән дә, теле белән дә аңлата белергә кирәк. Тамашачы[га] уйнаучыда шул хәлләрне күреп, белеп, сизеп торырга кирәк. Бу шартлар табылмаганда, рольнең әһәмияте бетә, кадере югала.

Менә шул фәүкыльгадә[6] зур, читен рольне яңа вә яшь артисткаларымыздан Таҗдарова[7] уйнады. Ләкин, нә кадәр авыр булса да, игътираф итми[8] хәл юк: Таҗдарова уйнады түгел, бәлки тәҗрибә генә ясап карады.

Шуннан артыгын Таҗдаровадан таләп тә итеп булмый. Чөнки әле ул яңа, тәҗрибәсез...

Аның иң зур кимчелеге – гадәттән тыш тынлыгы. Бу тынлык аның һәрбер хәрәкәтендә сизелеп тора. Мөхәррирнең тасвиры буенча, ул бер урында тормый торган, шау-шулы, ни кылганын, ни әйткәнен хисаплап торуны яратмый торган бер кыз булырга кирәк. Таҗдарова исә аның киресенчә, бик тынык, һәммә хәрәкәтен, сүзен уйлап эшли торган бер кыз булып чыкты. Анда йиңеллек, үзенә җәлеп кыла торган, үзен ирексез сөйдерә торган бер хәл юк иде.

Аның актык пәрдәдә Сөләйман илә мөхавәрәсе[9] (бу пьесаның бик матур йире) рухсыз, салкын чыкты. Сөләйманның бер мөҗадәләи

---

[1] Шикелсезләнеп – шәкелсезләнеп.

[2] Вә илх – һәм башкалар.

[3] Фазыйләтләр – яхшы эшләр.

[4] Мәсьүлиятләр – җаваплылыклар.

[5] Халәте рухиягә – рухи халәткә.

[6] Фәүкыльгадә – гадәттән тыш.

[7] Таҗдарова – Нәгыймә Таҗдарова (Нәгыймә Әхмәдулла кызы Әхмәдуллина, 1888–1947), драма актрисасы, ТАССРның халык (1939), РСФСРның атказанган (1940) артисты.

[8] Игътираф итми – кимчелекләрне танымый.

[9] Мөхавәрәсе – әңгәмәсе.

рухия[1] эчендә йөрәгеннән чыккан тәэсирле сүзләрне сөйләгәндә ул бик салкын кан илә, читкә карап, башка нәрсә уйлап, суфлер артыннан гына ияреп барды. Бу дәкыйкадә[2] үзеңнең сәхнәдә икәнеңне онытып, вакытлы булса да Рокыяның хиссияте белән яшәргә, аның күңелендәге серләрне укый белергә кирәк.

Башта ук дидем: Таждаровадан артыгын сорарга хакымыз юк. Максат – бары тәнбиһ[3] кенә, дәрд вә һәвәс[4] булганда, ул косурлар[5] киләчәктә тәкәммел итсәләр[6] кирәк.

Пьесада матур вә хәяти типларның берсе – мөхәррир Сөләймандыр. Бу бик благородный бер тип. Аның һәрнәрсә хакында фикере төпле, игътираз[7] кабул итмәслек дәрәҗәдә катгый, ул һәркемнең рухына керә белә, һәркемне эченнән күрә. Ул үзен сөйдерә дә, тәгъзыйм дә иттерә[8].

Хәтта кача торган Салиха абыстай да: «Ул үзе генә булса, аннан кайсыбер киңәшләр сорар идем», – ди. Бәхетсез Гөлчәһрә ханым да: «Сөләйман абзый, никадәр минем аны сезгә үз авызым белән сөйлисем килә. Хәзергә хәтле минем аны ирләрдән бер кешегә дә сөйләгәнем юк», – ди.

Аның татарның киләчәгенә карашы да бик матур, бик өмидле, аны «шовинист» дип атасак, бераз авыррак булыр. Алай да ул – шактый ышанган бер милләтче. Ул студент Габдулланы бер күрүдә үк яратмый. Габдулланың хәрәкәт вә сүзләреннән аның хәтеренә Фонвизинның Иванушкасы килеп төшә. Рокыяга карап: «Иванушкалар вә Абдулкалар теләсәләр ничек уйласыннар, әмма мең еллык тарихы булган, башкаларныкыннан бер дә калышмаслык кабилияте булган, тырышып сакланып килингән дине вә гадәтләре булган, үзенең язуы, әдәбияты, җыры, көе булган, гасырлар буенча мәктәп вә мәдрәсәләре булган бер милләтнең бернәрсәсе дә бер вакытта чүпкә чыкмый, чыга алмый, аны чүпкә чыгару Иванушка –Абдулкалар кулыннан килә торган эш түгел» дигән сүзләре бик зур алкышларга, бик каты кул чабуларга сәбәп булды.

Бу матур рольне Үзбәк – Тинчурин[9] уйнады. Һәм дә тугрысын әйтергә кирәк, бик муаффәкыятьле уйнады, хәтта уйнады гына да түгел, аны иҗат итте. Сөләйман роле Тинчурин өчен татарча пьесаларда төп рольләрдән саналырга лаектыр. Аның һәрбер хәрәкәте бик табигый, хәяты – тавышы вә сүзләре урыны-урыны белә бик тәэсирле, бик чын

---

[1] Мөҗадәләи рухия – рухи көрәш.
[2] Дәкыйкадә – минутта.
[3] Тәнбиһ – искәртү.
[4] Һәвәс – теләк.
[5] Косурлар – кимчелекләр.
[6] Тәкәммел итсәләр – камилләшсәләр.
[7] Игътираз – каршы төшү.
[8] Тәгъзыйм дә иттерә – хөрмәт тә иттерә.
[9] Тинчурин – Кәрим Гали улы Тинчурин (1887 – 1938), драматург, актёр, режиссёр, педагог, ТАССРның атказанган артисты (1926).

күңелдән иде. Әгәр сөйләшкәндә бераз да ашыкмаса, бу роль Тинчурин тарафыннан бик мөкәммәл[1] бер тип булып чыгачактыр.

Аны халык бик яратты, ләкин кыяфәте вә гримы утыз биш яшьләр өчен шактый карт иде.

Муаффәкыятьле типларның берсе – Габдулладыр.

Бу хәзер дә татар студентлыгы галәмендә отрицательный бер тип булырга тиеш.

Бу типны Әмирхан бик урынлы иттереп чыгарган. Без пьесаларымызда бу көнгә кадәр студентларымызны яхшы яктан гына күрә идек. Үзе татар булып та татарлыктан качкан, рус әдәбияты, рус мәдәнияте белән мактанып йөргән мондый студентчыклар бездә хәзер дә бетәргә тиеш. Сөләйман әйтмешли: «Бездә дә шундый Иванушка – Абдулкалар була икән, аларга кәеф китүдән бигрәк, алардан көләргә, хәтта аларны шундый көлке булганлыклары өчен кызганырга кирәк».

Бик зур булмаган бу рольне Үтәй[2] әфәнде начар уйнамады. Аның тәләффызы да[3] Касыйм мишәрләренекенә охшар.

Бишенче тип булган Гомәр дә шулай ук бик матур яктан күрсәтелә беленгән. Ул – сәбатлы[4], җитди, мәгълүматлы, практичный бер яшь сәүдәгәр. Аның өстәвенә, яхшы ук милләтче. Бу – яшьләремезгә намүнә[5] булырлык бер типтыр.

Мортазин-Иманский[6] аны ачык кына, дөрест кенә итеп уйнады. Сафа Насыйбуллин вә Закир ролендә Сакаев[7] бик матур уйнады. Бигрәк тә Закир ролен бик шат уйнап, халыкны бик көлдерде. Аның һәрбер сүзенең башында: «Шулай бервакыт без бер компания белән...» дип башлавы ирексез көләсене китерә иде. Ләкин «каһәр суккыры» дигән ямьсез сүзне күбрәк кыстырып йибәрүе бераз тозсызракка әйләнеп китәдер.

Галиев ролен Мангушев[8] оста вә җитез уйнавы белән халыкның хушына китте. Мангушевка яшь җилбәзәк рольләре карт татар рольләренә караганда күп мәртәбә артык килешәдер. Ул русча сүзләрне дә яхшы ук дөрест вә матур итеп әйтә белә, үзен сәхнәдә килешле тота.

---

[1] Мөкәммәл – камил, тулы.

[2] Үтәй – һәвәскәр артист.

[3] Тәләффызы да – сөйләве дә.

[4] Сәбатлы – нык, чыдам.

[5] Намүнә – үрнәк.

[6] Мортазин-Иманский – Вәлиулла Гайназар улы Мортазин-Иманский (1885– 1938), драма актеры, режиссёр, БАССРның халык артисты (1922), РСФСРның атказанган артисты (1935).

[7] Сакаев – Нури (Нуретдин) Нәбиулла улы Сакаев (1885–1927), драма актёры, режиссёр, Хезмәт Герое (1926).

[8] Мангушев – Габдрахман Габделкәрим улы Мангушев (1887–1919), актёр, журналист, драматург.

Гөлчәһрә ханым ролендә Иманскаяның[1] уйнавы бу юлы миңа бик охшады. Бу – кечкенә генә эпизодический[2] бер рольдер. Ләкин пьесада аның үткән «романы» бик аңлашылмый кала, аның күз яшьләренең сәбәбе ачык мәгълүм булмый.

Маһруй (Гөлнар[3]), Салиха (Болгарская[4]) вә Маша (Морадова[5]) ларның рольләре уен буенча бик кечкенә. Аларга артык урын бирелмәгән. Шулкадәр бар: Салиханың гримы, өсте-башы тиешеннән артык картларча иде.

Фатих әфәнде театрга даир[6] язган әсәрләренең азлыгына нисбәтән ул кадәр тәҗрибә сахибе[7] булмаса да, ләкин ул гаҗәеп бер сурәттә тамашачыларга яхшы настроение[8] бирә белә вә тамашачыларның дикъкатен ирексез үзенә ияртеп, уенның башында биргән настроениесен ахырына кадәр саклап алып килә ала. Менә бу – бик аз драматургларга мөяссәр[9] була торган бер фазыйләт[10] вә пьесалар өчен мөһим бер плюстыр.

*Г. Кәрам*
*(«Аң». 1915. № 4)*

*Басмага әзерләде:*
***Ханнанова Гөлчирә Мәхмүт кызы,***
*ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының текстология бүлеге фәнни хезмәткәре*

---

[1] Иманская – Мәрфуга Иманская (Мәрфуга Мортазина, 1890–1928), актриса.

[2] Бу сүз кириллицада бирелгән.

[3] Гөлнар – һәвәскәр артистка.

[4] Чыганакта – Болгарский.

[5] Морадова – бу очракта Гафур Коләхмәтовның сеңлесе, Ф. Агиевның хатыны Суфия Юныс кызы Коләхмәтова (1890–1972) күздә тотыла,

[6] Театрга даир – театрга караган.

[7] Сахибе – иясе.

[8] *Бу сүз кириллицада бирелгән.*

[9] Мөяссәр – җиңел үтәлешле.

[10] Фазыйләт – яхшы сыйфатлылык.

## «РУХИ МИРАС: ЭЗЛӘНҮЛӘР ҺӘМ ТАБЫШЛАР» СЕРИЯСЕНДӘ СӘЯХӘТНАМӘЛӘР

*(13, 14, 18 нче чыгарылышларга бәяләмә)*

Татар тарихи чыганаклары арасында сәяхәтнамәләр аерым урын алып тора. Алар рәсми, коры мәгълүмати чыганакларда булмаган картинаны тудырырга мөмкинлек бирә. Татарларда борынгы заманнардан ук сәяхәт итү һәм шул сәфәрне теркәп бару, яисә ахырдан язма рәвештә бәян итү традициясе тарихи чыганак базасын булдыруда үзенчәлекле бер алым саналган. Сәяхәтнамәләр – халык электән яратып укый торган жанр, бүген дә алар үзләренең җанлы тарихы белән укучының игътибарын җәлеп итә. Гарәп язуындагы сәяхәтнамәләрне гамәлдәге язуга күчереп, эшкәртеп, аңлатмалар белән баетып тәкъдим итү аларны киңкырлы җәмәгатьчелек куллана алу мөмкинлеге тудыра. Сәяхәтнамәләрдә халыкларның яшәү рәвеше, җәмгыять үсеше күренә. Башка мохиткә чит кеше күзлегеннән карау, сәяхәтченең бәясе, тәэсирләре дә кызыклы. Бу язмалардагы мәгълүматны башка җирлек белән чагыштыру да дөньяга төрле яктан карарга ярдәм итә. Тагын шунысы да бар: шул заман кешесенең фәлсәфи фикере, позициясе, эстетик, публицистик максатлары хәзерге укучы өчен дә кызыклы.

Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты галимнәре тарафыннан тормышка ашырыла торган проект кысаларында күпсанлы кульъязма рухи мирас халыкка кайтарыла, фәнни әйләнешкә кертелә. Аларның чираттагы күркәм хезмәтләренең нәтиҗәсе буларак сәяхәтнамәләргә багышланган өч саллы җыентык аерым игътибарга лаек (Рухи мирас: эзләнүләр һәм табышлар. Сәяхәтнамәләр = Духовное наследие: поиски и открытия. Путешествия / төз.: А.Х Алиева, Г.М. Ханнанова; текст., иск. һәм аңл. әзерл.: А.Х. Алиева, Г.М. Ханнанова; кереш сүз авт. А.Х. Алиева. – Казан: ТӘһСИ, 2021. – 13 нче чыг. – 300 б.; Рухи мирас: эзләнүләр һәм табышлар. Сәяхәтнамәләр = Духовное наследие: поиски и открытия. Путешествия / төз.: А.Х. Алиева, Г.М. Ханнанова; текст., иск. һәм аңл. әзерл.: А.Х. Алиева, Г.М. Ханнанова; кереш сүз авт. А.Х. Алиева. – Казан: ТӘһСИ, 2022. – 14 нче чыг. – 300 б.; Рухи мирас: эзләнүләр һәм табышлар. Сәяхәтнамәләр = Духовное наследие: поиски и открытия. Путешествия / төз. А.Х. Алиева; текст., иск. һәм аңл. әзерл., кереш сүз авт. А.Х. Алиева. – Казан: ТӘһСИ, 2023. – 18 нче чыг. – 256 б.).

Тәкъдим ителгән хезмәттәге сәяхәтнамәләрне фәнни эшкәрткән галимнәр А.Х. Алиева, Г.М. Ханнанованың хезмәтен югары бәяләргә, һөнәри осталыкларын аерым билгеләп үтәргә кирәк. Һәр текстның көчле фәнни аппараты булдырылган, киң катлау укучы аңлый алмаган сүзләргә аңлатмалар, терминнарга шәрехләүләр бирелгән. Мондый чыганаклар белән эшләүчеләр аның текст белән эшләүгә

караганда да күп вакыт, көч һәм белем таләп иткәнен бик яхшы чамалыйлар.

Әлеге җыентыкка татарлар чагыштырмача еш сәяхәт иткән юнәлешләргә, төбәкләргә багышланган сәяхәтнамәләр сайлап алынган. Алар – Иран, Кавказ, Төркия тарафлары. Чыганаклар шулай ук татарларның Ерак Көнчыгыш һәм Европага сәяхәткә чыгулары хакында да сөйли. Бу язмаларда Төркиягә карата аерым мөнәсәбәттә булу күренә, инкыйлабка кадәрге чорда татар өчен Төркия – төрки дөньяның үзәге, ә Истанбул башкаласы булган. Сан ягыннан караганда да, Төркия белән бәйле сәяхәтнамәләр зур күпчелекне тәшкил итә. Шул сәбәпле авторлар 2022 елда нәшер ителгән 14 нче чыгарылышны тулысынча диярлек Төркия сәфәрләре хакындагы язмаларга багышлаганнар.

Сәяхәтнамәләрнең авторлары – төрле өлкә кешеләре, аларның сәяхәт максатлары да, уй-ниятләре дә төрле. Авторларның кем булуына карап, тасвирлау, укучыларны җәлеп итү алымнары да аерылып тора. Журналист буларак вакыйгалар турында хәбәр итеп тору максаты белән җибәрелгән авторларның язмалары детальле, тәфсилле булуы белән үзенчәлекле. Мондый сәяхәтнамәләр 1912–1913 елларда Балкан сугышы хәбәрләре нигезендә туа. Гади турист буларак баручыларның, чит илләрдә белем алучыларның игътибар ракурсы бераз башкарак. Бу ике караш картинаны тулыландыра гына, шуңа да фикер булдыру өчен чагыштырулы анализ, бу язмаларны бергәлектә карау уңай нәтиҗәгә генә китерә. Моннан тыш авторлар ике җәмгыятьне чагыштыру күзлеге аша да күзәтәләр. Мисал өчен, тәҗрибәле педагог Нургали Сибгатулла улы Надиев (1882–1940) 1909 елда «Сәяхәт хатирәләре»ндә Төркия һәм Русия җәмәгатьчелегенә параллель үткәрә: «Биредә... адым саен булган каһвәханәләрдә эшсез халык бер чашка каһвә артында газета укып, сәясәттән гәпләшеп яки матур кальян савытларыннан чыккан озын көпшәле трубкаларын суырып, хыялга китеп, көн вә төннәрен үткәрәләр. Эшче халык та кичләрен шул каһвәханәләрдә үткәрә. Бездә эшче халыкның кичләре разгул (әчкечелек) урыннарында исереклек белән үтә. Биредә ял өчен бирелгән кичәнең бер өлеше гакыл сәламәтлеге, җан тынычлыгы белән садә генә үтә...», – дип яза. Шул ук вакытта бер үк җәмгыятьнең төрле төсмерләре булуын да таный. Аның инде бу сәяхәтнамәсе – гади тасвирлау гына түгел, ә аналитика элементлары белән үрелгән мөһим язма.

Турист булып килгән сәяхләр тарихи биналарга, мәчетләргә, музейларга игътибар бирәләр. «Кояш» газетасында «М.Х.» тәхәллүсе белән басылган автор Истанбулның матурлыгына соклана: «Истанбулны дөньяга килгән һәр төрек угылына күрү лязем. Монда килгән һәр татар угылының максаты – үзенә гыйльми, фәнни җәһәттәнме, бер файда казанмак лязем», – дип яза ул. Инкыйлабка кадәр булган сәяхәтнамәләрдә дә, башка төр язмаларда да татар халкының Төркиягә булган мөнәсәбәте үтә җылы. Табиб-автор шул чорда

төрекләрдәге медицина хакында да үз күзәтүләрен теркәп калдырган. «Йолдыз» газетасы хәбәрчесе Г. Әбүзәрев «Истанбул мәктүпләре»ндә Төркиянең хөкүмәте, сәясәте турында газета укучыларга мәгълүмат бирә. «Гм.» имзалы автор «Кояш» газетасында Төркиянең вазгыятен тасвирлый. Татар укучысы сәяхәтчеләр, журналистлар язмалары аша чит илләрнең архитектурасы, иҗтимагый-сәяси тормышы белән танышып бару мөмкинлеге ала. Мәрьям Паташеваның «Истанбул хатирәләре» бу илгә хатын-кыз карашы, хатын-кызның чит җирләрне ничек кабул итүе ягыннан аеруча кызыклы.

Татар кешесен Төркиядән кала, мөселман буларак, Бәйрут, Сурия һ.б. шәһәрләр, илләр үзенә тарткан. 1909 елда Борһан Шәрәф (1883–1942) «Вакыт» газетасы хәбәрчесе буларак Иранга бара. Аның шул сәфәре турыдагы «Иран мәктүпләре» дигән җитди бер язмасы да җыентыкта урын алган, ул хәзерге укучы өчен дә информатив бер чыганак булып тора.

Сакмарый тәхәллүсе белән язган, китапны төзүчеләр ачыклавы буенча, Габдулла Газизов дигән кеше, 18 бүлектән гыйбарәт күләмле «Шам хатирәләре», «Сурия әхвале», «Шамнан Багальбәккә» дигән язмаларын «Шура»да ике ел дәвамында бастырып барган. Бу язма – әлеге төбәкләр турында тулы, кызыклы, бай мәгълүматлы әсәр. Анда халыкның яшәү рәвеше генә күрсәтелеп калмый, зур проблемалар да күтәрелә.

Кавказ тарафына багышланган сәяхәтнамәләрдән, Х. М. авторлыгындагы «Кавказ сәяхәтеннән», Искәндәр әл-Хәмзәвинең «Кавказиядә сәяхәт» язмалары кызыклы.

Татар сәяхләре сәфәр географиясенең киңәя баруын икенче, өченче чыгарылыш җыентыклар эчтәлегеннән дә күреп була. Алар инде – Европа һәм Азия илләренә барганнан соң туган язмалар. Педагог Фатыйх Сәйфи-Уфалының (1883–1923) 1914 елда язылган «Экскурсия мәктүбләре» язмасында Европа тарафына булган озын маршрут сурәтләнә. Автор Мәскәү, Петербург аша Финляндиягә бара. Хәтта ки, татар кешесенең элекке Көнбатыш Кытайдагы Синьцзян вилаятенең көньяк өлешенә – Алтыншәһәргә (Кашгария) баруы хакындагы язмалар бар. Аның авторы – Назархуҗа Габдессамад углы, язмасы «Юл хатиратымнан» дип исемләнгән. 1911 елда ук татар имамы Салихҗан Урманов Владивостоктан Японииягә чыга. Укымышлы имам юлда булган бөтен нәрсә белән кызыксынып, ул җирләрнең тарихын гына түгел, ә чит, ерак кыйтгада мөселманнарның хәл-әхвәлен, хәлләрен дә сөйли.

Җыентыкка кертелгән сәяхәтнамә авторларының мәдәни бәйләнешләр белән чит илләргә чыгуы аерым игътибарга лаек, алар инде үз язмаларында вакыйгаларга мәдәният югарылыгы ноктасыннан карыйлар, коры сурәтләү генә түгел, ә анализ, бәя бирү, хәтта үрнәк алу кебек моментлар да бар. Шундыйлардан, мисал өчен, Гомәр Галиевнең (1900–1954) «Чит илләрдә» дигән юлъязмасы.

Сәяхәтнамә җыентыкларына күләм ягыннан төрле язмалар җыелган, аларның һәрберсе – кечкенәсе дә, күләмлесе дә – тарихи

чыганак буларак бер үк дәрәҗәдәге көчкә ия һәм аерым игътибарга лаек. Сәяхәтнамә – күргән җирләр тасвирланган әсәр генә түгел, анда бирелгән материал, авторларның мәгълүматны кабул итүе, анализы, сәяхәт географиясе шул чор татар җәмгыятенең халәтен, фикер дәрәҗәсен, аның башка җәмгыятькә, дөнья мәдәниятенә ачык булуын, аны кабул итү рәвешен дә күрсәтә.

Рухи мирасны барлау, аны фәнни әйләнешкә кертүдә Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты галимнәренең фидакяр хезмәте хөрмәткә лаек, бу эшнең дәвамлы, бәрәкәтле булуына зур өмет баглыйбыз. Мөмкин кадәр күбрәк татар кулъязма чыганакларының тиз арада киң катлау укучыларга барып җитүе мөһим. Һәр җыентыкта филология фәннәр кандидаты галимә Әнисә Алиеваның тәфсилле аналитик кереш мәкаләләре бу төр чыганакларны югары фәнни дәрәҗәдә анализлый, укучыны аларны кабул итәргә әзерли, кызыксыну уята. Гомумән алганда, бу җыентыкларда Институт галимнәренең – проект җитәкчеләренең, бу эшне башкарган барлык белгечләрнең чыганакчылык фәненә керткән бәһасез хезмәтен күрәбез.

***Сәлахова Эльмира Кадим кызы,***
*тарих фәннәре кандидаты,*
*ТР ФА Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институтының*
*өлкән фәнни хезмәткәре*

# «БАШ ХӘРЕФТӘНМЕ, ЮЛ ХӘРЕФЕННӘНМЕ?» орфографик сүзлегенә (Казан, ТӘһСИ, 2022) РЕЦЕНЗИЯ

Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының лексикография бүлеге соңгы берничә дистә елда күпсанлы лингвистик һәм тармак сүзлекләре әзерләп чыгарды. «Баш хәрефтәнме, юл хәрефеннәнме?»[1] орфографик сүзлегенең дөнья күрүе дә – бик шатлыклы, күптән көтелгән вакыйга, чөнки ялгызлык исемнәрнең кириллицага нигезләнгән орфографияләрдә баш хәрефтән язылуын һәр мәктәп баласы яхшы белсә дә, берничә сүздән торган ялгызлык исемнәр, дәүләт бүләкләре, диндә изге дип саналган төшенчә атамалары, бәйрәм, тарихи вакыйга, оешма исемнәре язылышында вариантлылык киң таралган. Матбугат битләрендә берничә сүздән торган топонимнарның *Кама Аланы* һәм *Кама аланы*, *Яшел Үзән* һәм *Яшел үзән*, *Кызыл Тау* һәм *Кызылтау* кебек төрлечә бирелеше белән еш очрашырга туры килә. Бу аңлашыла да, чөнки, беренчедән, әлегә кадәр татар телендә баш хәрефләр куллану кагыйдәләренә багышланган махсус белешмәлек юк иде дияргә була. Гомумән, орфографиягә караган хезмәтләрдә, 1941 елда ук расланган «Татар теленең алфавиты һәм орфографиясе» кагыйдәләр җыентыгында да баш хәрефләр кулланылышының нигезләре генә яктыртыла. Икенчедән, җәмгыять тормышында узган гасырның 90 нчы елларында башланган үзгәрешләр нәтиҗәсендә күп кенә төшенчәләргә идеологик ориентирларның үзгәрүе дин белән бәйле атамалар, дәүләт һәм иҗтимагый оешмалар, бәйрәм, тарихи вакыйга атамаларының язылышына тәэсир итте.

Рус орфографиясе буенча белгечләр дә 1956 елда расланган һәм бүгенгәчә үз көчендә калган «Рус орфографиясе һәм пунктуациясе кагыйдәләре»нең баш хәрефтән язуга караган өлешләренең искерүен билгели. Моның шулай икәнен Д.Э. Розентальнең 1980 еллардан башлап берничә тапкыр дөнья күргән «Прописная или строчная?» сүзлек-белешмәлеген, В.В. Лопатин, И.В. Нечаева, Л.К. Чельцова тарафыннан шундый ук исемдә 1999, 2007 елларда чыгарылган орфографик сүзлекләрне чагыштырып карау да күрсәтә.

Шуңа да «Баш хәрефтәнме, юл хәрефеннәнме?» орфографик сүзлеге татар лексикографиясе тарихында әһәмиятле һәм бик вакытлы вакыйга буларак бәяләнергә хаклы.

Хезмәт «Кереш» һәм Р.Т. Сәфәров тарафыннан Россия Фәннәр академиясенең В.В. Виноградов исемендәге Рус теле институтында әзерләнеп, Академиянең Тарих-филология фәннәре бүлеге каршындагы Орфография комиссиясе тарафыннан хупланган орфография ка-

[1] Баш хәрефтәнме, юл хәрефеннәнме?: Орфографик сүзлек / О.Н. Галимова, И.И. Сабитова, Э.И. Сафина, Ф.И. Таһирова, Р.Т. Сәфәров; фәнни ред. Р.Т. Сәфәров. Казан: ТӘһСИ, 2022. 240 б.

гыйдәләренең яңа редакциясенә нигезләнеп язылган «Баш хәрефтән язылу кагыйдәләре» белән башлана. Анда баш хәрефтән язуның гомуми кагыйдәләре; кеше һәм мифологик затларның исемнәре, хайван кушаматлары; географик һәм административ-территориаль исемнәр; астрономия исемнәре; тарихи чорлар һәм вакыйгалар, бәйрәмчараларның исемнәре; дин белән бәйле атамалар; хакимият органнары, оешма, партия исемнәре; документ, сәнгать әсәрләре атамалары; вазифа, дәрәҗә исемнәре; товар билгеләре һәм сортлар, дәүләт бүләкләре исемнәрен язу кагыйдәләре, аерым стилистик мәгънәгә ия күмәклек исемнәрен баш хәрефтән язу очраклары аңлатыла, кыскартылмалар исемлеге бирелә.

Коръән сүрәләренең исемнәрен, диндә үтә әһәмиятле булып саналган төшенчәләрне, кайбер тезмә атамаларны, рус телендә ялгызлык исемнәрдән ясалып, юл хәрефеннән языла торган сыйфат һәм рәвешләрне татарча баш хәрефтән язу, куштырнаклар куллануга багышланган бүлекчәләр аеруча игътибарга лаек. Чөнки бу өлкәләрдә ныклы кагыйдәләр булмау төрле буталчыклык, аңлашылмаучылыкка китерә иде. Биредә авторның телебезнең эчке хасиятен, үзенчәлекләрен яхшы тоемлап эш итүе сизелеп тора.

Сүзлектә телебездә баш хәрефтән языла торган барлык сүзләрне туплап бирү максаты куелмый. Бу – төрле типтагы ономастик сүзлекләр бурычы. Хезмәттә баш хәрефтән яки юл хәрефеннән язылуы кыенлык тудыру ихтималы булган сүзләр урын алган. Мондыйларга беренче чиратта берничә компоненттан гыйбарәт атамалар (*Кабан Арты, Кабан арты мәчете, Сейшель утраулары (геог.) – Сейшель Утраулары (дәүләт)),* төрле мәгънәдә ялгызлык һәм күмәклек исем буларак кулланылучы омофоннар (*ирек* – бәйсезлек, *Ирек* – кеше, авыл исеме), кайбер аббревиатуралар (*ААҖ*) керә.

Орфографик яктан баш яки юл хәрефе белән генә аерылып торган атамалар төрле сүзлек мәкаләләрендә, ләкин төркемгә берләштерелеп, номерлап бирелә, мәсәлән:

**Ак бүре**[1] (*мифол.*)
**Ак Бүре**[2] (*персонаж*)
**Акбүре**[3] (*авыл*)

**Кама буе**[1] (*Кама елгасы яры полосасы*)
**Кама Буе**[2] (*территория*)

Бер типтагы төрле учреждение исемнәре, нигездә, бер сүзлек мәкаләсенә туплап бирелгән:

*Театр* (учреждение), мәс.: Г. Камал исем. Татар дәүләт академия театры, К. Тинчурин исем. Татар дәүләт драма һәм комедия театры, Зур драма театры (*С.-Петербургта*). Кайберләре исә аерым сүзлек мәкаләсе буларак та урын алган: «Әкият» татар дәүләт курчак театры (35 б.), Казан рус драма театры (110 б.), Казан дәүләт татар яшь тамашачылар театры (112 б.). Дөрес, Буа, Түбән Кама һ.б. дәүләт театрларына ни сәбәптәндер сүзлектә урын табылмаган.

Күп кенә аббревиатураларның дөрес укылышы искәртелү бик урынлы: *АҖ* [аҗэ] (акционерлар җәмгыяте), *АКШ* [акш] *һәм* [акыш] (Америка Кушма Штатлары), *МТС* [эмтээс]...

Кайбер тарихи сүзләр һәм архаизмнарның теркәлүе дә үзен аклый.

Хезмәттә әле күптән түгел генә кулланылышка кергән «Рәис – (дәүләт башлыгы) – Татарстан Республикасы Рәисе» (171 б.), «Аяз Гыйләҗев исемендәге Чаллы татар дәүләт драма театры» (55 б.) кебек яңа атамалар да урын алган. Тимерләң, *яки* Аксак Тимер, *яки* Тимер, *яки* Тимур (тарихи шәхес) (199 б.) кебек берничә вариантта кулланышта булган лексемаларның һәрберсен аерым сүзлек мәкаләсе итеп бирү дә хуплауга лаек, чөнки алар төрле чыганакларда төрлечә бирелә, ә мондый атамаларның берсен норма рәвешендә тәкъдим итү лингвистик сүзлек бурычына керми.

«Баш хәрефтәнме, юл хәрефеннәнме?», орфографик сүзлекләрне исәпләмәгәндә, татарча беренче җитди ортологик, ягъни телнең аерым өлкәдәге нормаларын камилләштереп биргән сүзлек дип бәяләнергә хаклы. Тик аннотациядә «укучылар, студентлар һәм укытучыларга, әдәбиятчылар һәм нәшрият хезмәткәрләренә тәкъдим ителә» дип күрсәтелгән бу сүзлек тармак нәшриятында нибары 600 данә тираж белән дөнья күргән. Димәк, ул китап кибетләре киштәләренә барып җитмәячәк һәм хәтта укытучылар, матбугат хезмәткәрләре кулына да кермәячәк. Шуңа да бу кыйммәтле хезмәтне зур тираж белән Татарстан китап нәшриятында кабаттан бастыру таләп ителә. Бу яңа тулыландырылган басманы әзерләгәндә искә алу өчен, кайбер тәкъдим-киңәшләребезне дә күрсәтеп үтәбез.

1. Мондый төр сүзлекләрдә еш кулланылган гипероним (родовое название) төшенчәсен *ыру атамасы* (17 б. һ.б.) дип калькалаштыру, безнеңчә, уңышлы түгел, бәлки *төркем, төр атамасы* дип бирергәдер.

2. Татарлар күпләп яшәгән төбәкләрдә, аеруча Башкортстан (республиканың үзендә башкортлар хәзер Башкортостан дип *о* интерфексы белән язалар) территориясендәге язылышы сорау тудыра алган кайбер атамаларны сүзлеккә кертү урынлы булыр иде. Мәсәлән, язылышы русчасыннан да, башкортчасыннан да аерыла торган торак пункт, алар белән бәйле кайбер тарихи объектлар һәм оешма исемнәрен күрсәтергә була:

Аскын мәгарәсе
Бәләбәй педагогика көллияте
Балакатай сусаклагычы
Бөре медицина көллияте
Бөре минераль чыганаклары
Борай күтәрелеше (1918)
Бөрҗән кояш электростанциясе
Җылаер платосы (*геогр.*) һ.б.

3. Ике компоненттан торган дәүләт яки шәһәр гражданнарын белдергән сүзләр кушылып һәм юл хәрефеннән языла: алтынурдалы, ярчаллылы, түбәнкамалы һ.б. Балык Бистәсендә яшәүчеләрне ничек атау дөрес була? Бу турыда керештә үк (24 б., п. 9) җентекләбрәк язарга кирәктер.

4. Тагын бер зур мәсьәлә – дини әдәбиятта, революциягә кадәрге текстларда еш очраган атамаларның, исемнәрнең бирелеше. Мәсәлән, Бохараи Шәриф, Хәрәм Шәриф (Иерусалимда) кебек сүзләр, Коръәне Кәримдә, хәдисләрдә очрый торган, хаталы язылуы ихтимал булган сүзләр (мәсәлән, сәдум, сәмум, сәмуд һ.б.). Гомумән, үзебезнең тарихка бәйле сүзләрне күбрәк кертәсе иде. Бу аларның баш хәрефтән язылу-язылмавын гына түгел, гомумән татарча ничек язылышын да теркәр иде. (Тарихчылар, мәсәлән, «кимак кабиләләре» дип яза, юкса дөресе «кимәк» булырга тиештер.) Бәлки, дингә бәйле атамаларның язылышын Диния нәзарәте, тарихи терминнарны – Тарих һәм Археология институтлары, топонимнарны Энциклопедия һәм төбәкне өйрәнү институты галимнәре белән киңәшеп кодификацияләргәдер.

5. Бер типтагы ике компонентлы *Кызылсу, Кызылтау, Кызылъяр* торак пунктлары исемнәре кушылып, ә *Кызыл Күл, Кызыл чишмә, Кызыл Ялан* – аерым һәм зур хәрефтән, ә *Кызыл-Кыя* сызыкча аша язылуы да (136 б.) аңлату сорый. (Бу күренеш үзе үк лексикография бүлегенә киләчәктә рус телендәге «Слитно или раздельно?» тибындагы сүзлек төзү эшенә керешү кирәклеге турында сөйли).

6. Теоретик бүлектә (37 б.) төрле ысул белән ясалган машина маркалары исемнәрен язу кагыйдәләре җентекләп аңлатылса да, сүзлек өлешендә берникадәр төрлелек бар, мәсәлән: «ауди» (автомобиль), ВАЗ (автомобиль), «жигули» (машина), «Лада» (автомобиль), уаз (автомобиль) һ.б.

7. Дюма-отец, Дюма-сын дигәнне *атасы Дюма, улы Дюма* дип түгел (14 б.) *өлкән Дюма, кече Дюма* дип бирү уңышлырактыр.

8. Яр Чаллы дәүләт педагогика университеты, Казан (Идел Буе) федераль университетының Алабуга һәм Яр Чаллы институтлары, башка кайбер югары һәм махсус урта уку йортлары да әлегә сүзлектә чагылыш тапмаган.

Санап үтелгән җитешсезлекләр – авторлар коллективы тарафыннан беренче тапкыр башкарыла торган хезмәтләр өчен типик күренеш. Алар, алда искәртелгәнчә, кимчелек дип түгел, ә сүзлекнең яңа тулыландырылган басмасын әзерләгәндә искә алу өчен киңәш буларак китерелде. Җитәрлек тираж белән кабат бастырылган бу сүзлекнең һәр татар зыялысының өстәл китабына әвереләчәгенә шик юк.

***Закиров Рәиф Әмирьян улы,***
*филология фәннәре кандидаты,*
*Яр Чаллы дәүләт педагогика университеты доценты*

***Мөхиярова Рәзинә Хәйбрахман кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, доцент,*
*Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы*

**2024 елның 3 апрелендә** Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтында Россия Фәннәр академиясе Себер бүлеге Гуманитар тикшеренүләр һәм Төньякның азсанлы халыклары проблемалары институтының Интеллектуаль тарих һәм мәдәният үзәге галимнәре – тарих фәннәре докторы, үзәк җитәкчесе Екатерина Назаровна Романова һәм тарих фәннәре кандидаты, әйдәп баручы фәнни хезмәткәр Ванда Борисовна Игнатьева белән эшлекле очрашу узды. Якутиядән килгән кунаклар Институт галимнәренең тел, әдәбият һәм сәнгать өлкәсендәге тикшеренүләре, соңгы елларда институтта әзерләнеп нәшер ителгән фундаменталь фәнни хезмәтләр, сүзлекләр, каталоглар белән таныштылар. Очрашу вакытында сүз Институтта гамәлгә ашырыла торган проектлар һәм киләчәктә хезмәттәшлек итү юллары турында барды.

**2024 елның 3–4 апрелендә** Төмән дәүләт университеты филиалы – Тубыл педагогия институтында Гаилә елына багышланган «Заманча белем бирү киңлегендә фән һәм практиканы интеграцияләү: традицияләр һәм инновацияләр» темасына «Зәнкиев укулары» VIII Халыкара фәнни-гамәли конференция узды. Конференция кунакларын Тубыл педагогия институты директоры Надежда Еговцева, шәһәр хакимияте башлыгы урынбасары Владимир Кожедуб, милләтләр эшләре буенча өлкә комитеты рәисе урынбасары Роман Малыгин, шәһәр иҗтимагый палатасы рәисе Станислав Козлов, Бохара дәүләт университетыннан Аброр Жураев (видеодан), өлкә татар милли-мәдәни автономиясе рәисе урынбасары Рамил Әминов һ.б. сәламләде. Чарада галимнәр, туган тел укытучылары, аспирантлар, киң җәмәгатьчелек катнашты.

**2024 елның 12 апрелендә** Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты директоры, филология фәннәре докторы Ким Миңнуллин филология фәннәре докторы, профессор, Россия тюркология комитеты әгъзасы Илшат Сәхиятулла улы Насиповның 60 яшьлек юбилеена багышланган фәнни чараларда катнашты. Юбилей уңаеннан М. Акмулла исемендәге Башкорт дәүләт педагогия университетында (Уфа) уздырылган «Полилингваль һәм полимәдәни мәгариф киңлегендә тел һәм әдәби үзара бәйләнешләр мәсьәләләре» Бөтенроссия фәнни-методик семинарында чыгыш ясап, Ким Миңнуллин юбилярны Татарстан галимнәре исеменнән тәбрик итте һәм Татарстан Фәннәр академиясенең Көмеш медален тапшырды.

**2024 елның 16 апрелендә** Татарстан Республикасы Фәннәр академиясендә танылган төрекмән шагыйре Мәхтүмколый Фирагыйның тууына 300 ел тулуга багышланган түгәрәк өстәл узды. Чараны Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе һәм Төрекмәнстанның Россия Федерациясендәге Генераль консуллыгы оештырды. Түгәрәк өстәлне ачып, Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты директоры, филология фәннәре докторы Ким Мөгаллим улы Миңнуллин Мәхтүмколый Фирагый кулъязмалары Казан федераль университетының Сирәк китаплар һәм кулъязмалар бүлегендә дә саклануын билгеләп үтте. Алга таба Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе Президенты Рифкать Нургали улы Миңнеханов сәламләү сүзе белән

чыгыш ясап, төрекмән һәм татар халыкларының күпгасырлык мәдәни элемтәләре турында сөйләде, төрле елларда уздырылган уртак чараларга аерым тукталды, киләчәктә дә фәнни хезмәттәшлек итү зарурлыгын ассызыклады. Сәламләү сүзе белән Төрекмәнстанның ЮНЕСКО эшләре буенча Милли комиссиясе җаваплы сәркатибе, Гадәттән тыш һәм Тулы вәкаләтле илчесе Чинар Таджиевна Рөстәмова, Төрекмәнстанның Казан шәһәрендәге Баш консулы Гуйч Арчаевич Гараев һәм Татарстан Республикасы Язучылар берлеге рәисе Ркаил Рафаил улы Зәйдуллин чыгыш ясады. Түгәрәк өстәлдә шулай ук Төрекмәнстан Фәннәр академиясе Мәхтүмколый исемендәге Тел, әдәбият һәм милли кулъязмалар институтының кулъязмалар бүлеге мөдире Гельдимырат Мөхәммәдов, Мәхтүмколый исемендәге Төрекмән дәүләт университеты доценты Аманнепес Шихнепесов, Татарстан Республикасы фәнни оешмалары һәм югары уку йортлары, Язучылар берлеге, Татарстан халыклары ассамблеясы, массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләре катнашты.

**2024 елның 15–16 апрелендә** Габдулла Тукайның Казандагы әдәби музеенда Бөтенроссия (халыкара катнашу белән) «Тарих һәм мәдәният контекстында әдәби музейлар» темасына «Тукай укулары – 2024» фәнни конференциясе үтте. Әлеге чарада Татарстан, Мәскәү, Санкт-Петербург, Екатеринбург, Сыктывкар, Чабаксар, Самара һ.б. шәһәрләрнең музей хезмәткәрләре, тарих һәм әдәбият галимнәре, филологлар, тарихчылар катнашты. Конференция барышында Г. Тукай һәм аның замандашларының мирасын барлау, төрки дөнья контекстында шагыйрь иҗатын күзәтү, музей экспозициясе әсбаплары ярдәмендә әдәби әсәрләрне сурәтләү чараларын ачыклау, музей һәм гаиләнең үзара тәэсир итешү юлларын булдыру мәсьәләләре тикшерелде.

**2024 елның 18 апрелендә** Казан федераль университетының Алабуга институтында «Төрки дөнья хәзерге чынбарлыкта: тел, әдәбият, тарих һәм мәдәният проблемалары» XII Халыкара тюркологик конференциясе үткәрелде. Конференция программасына 150 дән артык доклад кертелгән иде, катнашучыларның географиясе гаять киң булып, Россия, Үзбәкстан, Азәрбайҗан, Казакъстан, Кыргызстан, Төрекмәнстан, Төркия галимнәрен үз эченә алды. Чарада төрки халыкларның телен, әдәбиятын, тарихын һәм мәдәниятен өйрәнүнең фәнни проблемалары һәм практикасы, төрки илләрнең иҗтимагый-сәяси үсеше турында сүз барды.

**2024 елның 19 апрелендә** танылган рәссам Әмир Мәҗитов музеенда «Бибимәмдүдәгә гөлләр» дип исемләнгән күргәзмә ачылды (кураторы – Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Сәнгать белеме үзәге мөдире, сәнгать фәннәре докторы Рауза Солтанова). Г. Тукайның әнисе Мәмдүдә Зиннәтулла кызына (1864–1890) багышланган күргәзмәдә Балтач районы Сасна Пүчинкәсе авылында «Тукай эзләре буенча» мәдәни һәм фәнни проекты кысаларында оештырылган арт-пленэр вакытында Татарстан профессиональ рәссамнары тарафыннан төрле жанрда (тематик картина, пейзаж, портрет, натюрморт) иҗат ителгән 30 рәсем һәм графика әсәре тәкъдим ителде.

**2024 елның 24–25 апрелендә** Казан шәһәрендә «Идел һәм Урал

буе милли әдәбиятлары: тикшеренү парадигмалары һәм практикалар» дип исемләнгән, күренекле Россия галиме, милли дөнья образларын өйрәнүгә караган күпсанлы фундаменталь хезмәтләр авторы Георгий Дмитриевич Гачевның тууына 95 ел тулуга багышланган Гомумроссия фәнни-практик семинары узды. Чараны оештыручы – Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты (ТӘһСИ). Партнёрлар – П. Лумумба исемендәге Россия халыклар дуслыгы университетының Рус теле институты, Х.М. Бербеков исемендәге Кабардин-Балкар дәүләт университеты. Семинар әлеге датага кагылышлы һәм милли әдәбиятларны өйрәнү мәсьәләләрен берләштергән бер төркем чараларны ачып җибәрде. Фәнни-практик семинар эшендә Мәскәү, Татарстан, Башкортстан, Марий Эл, Мордовия, Удмуртия, Чувашия, Дагстан, Кабардин-Балкар, Калмыкия, Коми, Кырым Республикасы, Екатеринбургтан галимнәр катнашты. Институт тарафыннан семинарга «Идел һәм Урал буе әдәбиятлары поэтикасы» дигән күмәк монография әзерләнеп нәшер ителде.

**2024 елның 26 апрелендә** бөек татар шагыйре Габдулла Тукайның тууына 138 ел тулу уңаеннан республикакүләм зур чаралар узды, Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреатлары игълан ителде. 2024 елда Габдулла Тукай бүләгенә балалар өчен шигърият, проза һәм драматургиягә күпьеллык өлеш керткәне, яшь укучыларга рухи-әхлакый тәрбия биргәне, татар әдәбияты һәм фольклорыннан балалар өчен иң яхшы әсәрләрне тәрҗемә иткәне һәм популярлаштырганы, Татарстанның яшь талантларына иҗади булышлык күрсәткәне өчен Борис Гиршевич Вайнер, татар мәдәниятенең күренекле тарихи шәхесләренә багышлаган скульптур портретлар һәм фигуралар сериясен тудырган өчен Кадим Җәмил улы Җәмитов, Татарстанның татар хор мәдәниятен үстергән, таныткан һәм саклаган, «Татар хор музыкасы антологиясе» өчен Миләүшә Әмир кызы Мөдәррисова (Тәминдарова), «Узганны кабатлау» китабы өчен Ләис Мәүлит улы Харрасов (Ләис Зөлкарнәй) лаек булды. Лауреатларны Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов Казан Кремлендә узган тантанада бүләкләде.

**2024 елның 5–19 маенда** сәнгать фәннәре докторы, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Сәнгать белеме үзәге мөдире Солтанова Рауза Рифкать кызы Себер татарлары йортларының төбәк, милли үзенчәлекләрен өйрәнү максатыннан, Омск, Томск, Төмән өлкәләрендә булды. Ул Омск, Томск, Төмән өлкәләрендә татарлар яши торган авылларда йорт үзенчәлекләрен өйрәнүдән тыш, музейларда, Татар мәдәнияте үзәкләрендә сакланган экспонатлар белән танышты, Себер музейларында (Омск тарихи-туган якны өйрәнү музее, «Сибирская старина» өлкә дәүләт тарихи-мәдәни музей-тыюлыгы, Омск дәүләт университетының Археология һәм этнография музее, Томск туган якны өйрәнү музее, И.Я. Словцов исемендәге Төмән музей комплексы, Тубыл тарихи-архитектура музей-тыюлыгы) булып, андагы архив материалларын өйрәнде. Себергә сәфәр Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитеты ярдәме белән «Татар халкының милли үзенчәлеген саклау» Татарстан Республикасы дәүләт программасын тормышка ашыру кысаларында оештырылган иде.

**2024 елның 8 маенда** Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе Исламны өйрәнү үзәге һәм Татарстан Республикасы Мөселманнары Диния нәзарәте тарафыннан «Бөек Ватан сугышында катнашкан һәм сугыш ветераннары булган татарлар – ислам динен тергезүчеләр» Бөтенроссия фәнни-гамәли конференциясе үткәрелде. Конференциянең максаты Бөек Ватан сугышында катнашучыларның рухи мәдәният кыйммәтләрен, дини-әхлакый тәрбия, мәгърифәт һәм яшьләрне социальләштерүдәге ролен ачыклауга юнәлтелгән иде. Чара кысасында Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты «Бөек Ватан сугышы татар әдәбияты һәм публицистикасы көзгесендә» дип аталган түгәрәк өстәл утырышы уздырды.

**2024 елның 13–14 маенда** Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты директоры урынбасары, филология фәннәре докторы Олег Ришат улы Хисамов «Мәгълүмати технологияләр һәм Россия халыклары телләре» («Информационные технологии и языки народов России») дип исемләнгән I стратегик сессия эшендә катнашты. Җирле халыклар телләренең халыкара унъеллыгын үткәрү кысаларында Мәскәүдә Яндекс штаб-фатиры мәйданчыгында оештырылган әлеге чарада тел сәясәте өлкәсеннән 200 дән артык эксперт, цифрлы технологияләр белгечләре, фән һәм мәгариф вәкилләре катнашты. Олег Хисамов «Цифровые решения поддержки языков народов России: базовые языковые технологии» дип исемләнгән панель сессиясе кысаларында Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе галимнәренең әлеге өлкәдәге фәнни-гамәли проектлары белән таныштырды.

**2024 елның 13–24 маенда** Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты галимнәре – Язма мирас үзәге мөдире Илһам Гомәрев, үзәкнең әйдәп баручы фәнни хезмәткәре Азат Ахунов, фәнни хезмәткәр Венер Усманов Татарстан Республикасы Теләче районы авылларында эпиграфик экспедициядә эшләделәр. Фәнни-тикшеренү эшчәнлеге «Татар халкының милли үзенчәлеген саклау» дәүләт программасын гамәлгә ашыру кысаларында башкарылды.

**2024 елның 14 маенда** Татарстан Республикасы Фәннәр академиясендә региональ фәннәр академияләре ассоциациясенең киңәйтелгән утырышы узды.Чарада Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары Ләйлә Фазлыева, Татарстан Республикасы Рәисе ярдәмчесе Альберт Гыйльметдинов, Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе президенты Рифкать Миңнеханов, Башкортстан Республикасы Фәннәр академиясе президенты Камил Рамазанов, Чечен Республикасы Фәннәр академиясе президенты Джамбулат Умаров, Саха (Якутия) Республикасы Фәннәр академиясе президенты Леонид Владимиров катнашты.

Чарада 2023 елның декабрендә Якутскида имзаланган төбәк фәннәр академияләре ассоциациясе турында килешү кысаларында үзара хезмәттәшлек мәсьәләләре каралды, уртак фәнни проектларны гамәлгә ашыруга бәйле перспектив эш планнары тәкъдим ителде. Докладлар белән ТР Фәннәр академиясе бүлекчәләре, институтлары һәм үзәкләре җитәкчеләре чыгыш ясады.

**2024 елның 15 маенда** Казан федераль университетының Филология һәм мәдәниятара багланышлар институты базасында Абай

исемендәге Казакъ теле һәм мәдәнияте фәнни-мәгариф үзәге ачылды. Әлеге тантанада Казакъстан делегациясе – Л.Н. Гумилёв исемендәге Евразия милли университеты проректоры Ардак Бакытулы Бейсенбай, транспорт-энергетика факультеты деканы Омиржан Шералыулы Кокаев, административ департамент директоры Ануар Сапаргалиулы Майканов, «Абай академиясе» фәнни-тикшеренү институты җитәкчесе Аубакир Жандос Магазбекулы катнашты.

Эшлекле визит кысаларында Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе белән Л.Н. Гумилёв исемендәге Евразия милли университеты арасында хезмәттәшлек итү турында килешү төзелде. Делегация вәкилләре Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма мирас үзәге эшчәнлеге белән дә танышты.

**2024 елның 17–19 маенда** Бөтендөнья татар конгрессы Казан шәһәрендә «Милли тормыш һәм дин» XIV Бөтенроссия татар дин әһелләре форумын үткәрде. Форум катнашучылары дин өлкәсенә кагылышлы мөһим сораулар һәм мәсьәләләр буенча фикер алышу өчен җыелды. Анда Россия Федерациясенең 77 регионыннан, шул исәптән Татарстан Республикасыннан барлыгы 1000 дин әһеле һәм кунаклар килде. Делегатлар өчен эчтәлекле программа әзерләнгән иде.

**2024 елның 17 маенда** Казанда «Россия – Ислам дөньясы: KazanForum 2024» халыкара икътисади форумы узды. «Казан Экспо» күргәзмә үзәгендә оештырылган быелгы форумның төп темаларыннан берсе «Ышаныч һәм хезмәттәшлек» дип исемләнгән иде. Программа кысаларында чит илләр һәм Россия төбәкләре экспертлары катнашында 125 тематик сессия оештырылды. Аларда халыкара хезмәттәшлек, туризм, бизнес, ислам финанслары һәм инвестицияләре, спорт, хәләл индустриясе, рухи мирас мәсьәләләре күтәрелде. Форумны оештыручыларның берсе буларак, чарада Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе дә катнашты.

**2024 елның 18 маенда** «Татар халкы мирасында дини тәгълимат, гыйльми фикер һәм оешу үрнәкләренең заманча вазгыятьтә тормышка ашырылуы» темасына IX Бөтенроссия фәнни-гамәли конференциясе – «Шиһабетдин Мәрҗани исемендәге укулар» узды. Чара Казан шәһәрендә «Милли тормыш һәм дин» XIV Бөтенроссия татар дин әһелләре форумы кысаларында үтте. Конференциядә катнашучылар дини доктриналарның, фәнни концепцияләренең һәм Россия татар-мөселманнары оешмаларының бүгенге шартларда актуальлеге хакында фикер алышты. Пленар утырышта Россия мөселманнары Диния нәзарәте рәисе Равил Гайнетдин, Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары, Бөтендөнья татар конгрессы Милли Шурасы рәисе Васил Шәйхразыев, Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе президенты Рифкать Миңнеханов чыгыш ясады. Чарада шулай ук Россия Фәннәр академиясе, Татарстан Фәннәр академиясе, Казан федераль университеты, Казан ислам университеты экспертлары Ш. Мәрҗани мирасына багышланган фәнни докладлар белән катнашты.

**2024 елның 18 маенда** Болгарда Истәлек билгесе һәм җамигъ мәчет арасындагы мәйданда Идел буе Болгар дәүләтендә исламны рәсми

кабул итү көненә багышланган «Изге Болгар җыены» чараларын ачу тантанасы узды. Биредә Татарстан Республикасы Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиев, Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары, Бөтендөнья татар конгрессы Милли Шурасы рәисе Васил Шәйхразыев, Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитеты җитәкчесе Данис Шакиров, Бөтенроссия татар дин әһелләре форумы вәкилләре һәм башкалар катнашты. Чарада катнашучыларны Татарстан Республикасы Рәисе Рөстәм Миңнеханов сәламләде. «Изге Болгар җыены» Болгарда 1989 елдан бирле 922 елда Идел буе болгарларының дәүләт дине буларак ислам динен кабул итү көне һәм Болгар ханы Алмышның галим Ибн Фадлан җитәкчелегендәге Багдад хәлифәсе делегациясе белән очрашуы истәлегенә оештырыла.

**2024 елның 21–24 маенда** Казанда Мөхәммәдьяр исемендәге Халыкара төрки әдәбиятлар фестивале узды. Анда Азәрбайҗан, Казакъстан, Кыргызстан, Үзбәкстан илләреннән; Мәскәүдән, Башкортстан, Саха (Якутия), Чувашия, Дагстан, Кабардин-Балкар, Карачай-Черкес республикаларыннан әдипләр, наширләр катнашты. Фестиваль кунаклары Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты Язма мирас үзәге эшчәнлеге белән дә таныштылар. Экскурсия барышында Мирасханәдә саклаучы сирәк кульязмалар һәм басма материаллар, галимнәрнең фәнни хезмәтләре белән Институт директоры, филология фәннәре докторы Ким Миңнуллин, Язма мирас үзәге мөдире, филология фәннәре кандидаты Илһам Гомәров, фәнни хезмәткәр Нурия Гәрәева таныштырды.

Мирасханә базасында «Төрки халыклар әдәбияты: тарихы һәм бүгенгесе» дип исемләнгән панель дискуссия дә оештырылды. Чараны ТӘһСИ галимнәре – филология фәннәре докторы, профессор Дания Заһидуллина һәм филология фәннәре кандидаты, чагыштырма тел белеме лабораториясе мөдире Марсель Ибраһимов алып барды.

**2024 елның 27 маеннан 7 июненә кадәр** Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты тарафыннан Мордовия Республикасы территориясендә татарлар күпләп яшәгән Дубенки, Кочкуров, Рузай, Инсар, Кадошкин, Тәрби, Ковылкин, Зубово-Поляна районнарына комплекслы фәнни экспедиция оештырылды. Экспедиция составында халык иҗаты (экспедиция җитәкчесе, филология фәннәре кандидаты, халык иҗаты бүлеге мөдире Ильмир Ямалтдинов; филология фәннәре кандидаты Рузия Сафиуллина), лингвистика (филология фәннәре кандидаты, лексикология һәм диалектология бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре Әлфия Булатова), этномузыкология (Сәнгать белеме үзәге өлкән фәнни хезмәткәре Гөлназ Гыйлемҗанова), халык һөнәрчелеге һәм кәсепләре (сәнгать фәннәре кандидаты, Сәнгать белеме үзәге өлкән фәнни хезмәткәре Людмила Шкляева), археография (филология фәннәре кандидаты, Язма мирас үзәгенең әйдәп баручы фәнни хезмәткәре Ләйлә Гарипова) һәм эпиграфика (Язма мирас үзәге фәнни хезмәткәре Венер Усманов) буенча галимнәр эшләде. Алар Мордовия Республикасында яшәүче татарларның халык авыз иҗатын, археографик мирасын, эпиграфик һәйкәлләрен, традицион музыка мәдәниятен, татар халык сәнгате үрнәкләрен өйрәнү белән шөгыльләнде.

**2024 елның 31 маенда** Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе президиумы утырышында Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты директорының фән буенча урынбасары Олег Ришат улы Хисамовка, халык иҗаты бүлегенең әйдәп баручы фәнни хезмәткәре Ләйлә Хәсән кызы Дәүләтшинага һәм чагыштырма татар белеме лабораториясе әйдәп баручы фәнни хезмәткәре Алексей Андреевич Арзамазовка «Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе профессоры» исеме бирелде. Хезмәттәшләребезне мактаулы исем бирелү белән котлыйбыз, сәламәтлек, бәхет, яңа фәнни ачышлар, һөнәри уңышлар телибез!

**2024 елның 10–11 июнендә** Казанда мәгариф министрларының «Киләчәкне формалаштырганда» II халыкара форумы узды. Чара Россия Мәгариф министрлыгы, Татарстан Республикасы Хөкүмәте һәм «Минем тарих» гуманитар фәннәргә ярдәм фонды тарафыннан оештырылды. Форумда бүгенге көн мәгариф системасының уңышлары, уку йортларында белем һәм тәрбия бирүнең сыйфаты һәм һәркем алырлык булуын бәяләүгә кагылышлы темалар хакында сүз барды. Чара кысаларында БРИКС илләренең мәгариф министрлары очрашуы узды. Форумда Россиядән һәм чит дәүләтләрдән 1000 нән артык вәкил, шул исәптән гомуми һәм югары белем министрлары катнашты.

**2024 елның 13–16 июнендә** Казан федераль университетының Филология һәм мәдәниятара багланышлар институтында «Россия үзенчәлеген һәм халыкара интеграцияне формалаштыру чарасы буларак рус теле һәм әдәбияты» II халыкара форумы үткәрелде. Форумга Россия һәм чит ил галимнәре – филологлар, рус теле һәм әдәбияты укытучылары чакырылган иде. Ачылыш тантанасында Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министры Илсур Һадиуллин, Александр Пушкин исемендәге дәүләт музее директоры Евгений Богатырев, Лев Толстой исемендәге Мәдәният институты Президенты Рубен Дарио Флорес Арсила (Богота шәһәре, Колумбия Республикасы), Гранада университетының грек һәм славян филологиясе кафедрасы профессоры Рафаэль Гусман Тирадо (Малага, Испания), Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе вице-президенты Айнур Тимерханов, Татарстан Республикасы Рус милли-мәдәни берләшмәсе рәисе Ирина Александровская, КФУ Президенты Рияз Минзарипов һ.б. катнашты. Форум Казан университетының 220 еллыгына, шулай ук бөек рус шагыйре Александр Пушкинның тууына 225 ел тулуга багышланган иде.

Научное издание

**НАУЧНЫЙ ТАТАРСТАН**

На татарском языке

Фәнни басма

**ФӘННИ ТАТАРСТАН**

2024. № 2

Бизәлеш авторы – А. Шляпкин
Компьютерда биткә салучы – Н. Абдуллина

Басарга кул куелды: 28.06.2024. Басылды: 15.07.2024.
Офсет кәгазе. Кәгазь форматы 70×108 1/16.
Гарнитура «Times».
Басма табак 12. Тираж 300 данә. Заказ

Журнал ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтында әзерләнде

Редакция адресы:
420111, Казан шәһ., К. Маркс ур., 12
«Фәнни Татарстан» журналы редакциясе
Тел. (843) 590-55-93
E-mail: f_tatarstan@mail.ru

Журнал Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе нәшриятында басылды
(нәшрият адресы – 420111, Казан шәһ., Бауман ур., 20)

Журнал бушлай таратыла